РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ТАТАР ДӘҮЛӘТ ГУМАНИТАР-ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ

Р.С.НУРМӨХӘММӘТОВА

ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕНЕҢ ТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ

УКЫТУ-МЕТОДИК ЯРДӘМЛЕК

КАЗАН 2010

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты татар филологиясе факультеты гомуми һәм чагыштырма тел белеме кафедрасы карары белән басыла

УДК 81'25:811.161.1=512.145 (075.8)
ББК 81.2-7 я 73

Нурмөхәмммәтова Р.С. Тәрҗемә белеменең теоретик нигезләре: укыту-методик ярдәмлек. – Казан, 2010. – 164 б.

Укыту-методик ярдәмлек бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүнең кайбер теоретик мәсьәләләрен яктыртуга багышлана. Китап рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итүчеләрне күздә тотып төзелә. Ул шулай ук ике тел нисбәтен тикшерүчеләргә, чит телле аудиториядә татар телен укытучыларга, профессиональ дәрәҗәдә һәм ирекле рәвештә тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләргә кирәкле кулланма булыр дип уйлыйбыз.

Китап югары уку йортларының татар филологиясе факультетларында белем алучыларга, көллият һәм мәктәп укучыларына, укытучыларга һәм тәрҗемә белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

Фәнни редакторы –

филология фәннәре докторы, профессор **Р.Р.Җамалетдинов**

Рецензентлар:

филология фәннәре кандидаты, доцент А.Х.Әшрәпова (ТДГПУ)

филология фәннәре кандидаты, доцент Э.Н.Динмөхәммәтова (КДУ)

©Р.С.Нурмөхәммәтова
©ТДГПУ, 2010

ЭЧТӘЛЕК

Кереш...4

I бүлек. ГОМУМИ ТӘРҖЕМӘ ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ
1.1. Тәрҗемәнең асылы һәм әһәмияте...6
1.2. Тәрҗемәнең төп принциплары...20
1.3. Дөрес һәм ялгыш тәрҗемә төшенчәләре...............................24
1.4. Тәрҗемә эквивалентлыгы типлары..28
1.5. Тәрҗемәдә семантик тәңгәллекләр.......................................35
1.6. Тәрҗемә трансформацияләре...52
1.7. Тәрҗемә процессының моделен төзү....................................56
1.8. Тәрҗемәченең эш стратегиясе...63

Бүлек буенча өстәмә әдәбият...71

II бүлек. ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕНӘ ГОМУМЛИНГВИСТИК КЕРЕШ
2.1. Лингвистик тикшеренүләр объекты буларак тәрҗемә..........72
2.2. Тәрҗемәнең лингвосемиотик нигезләре................................84
2.3. Тәрҗемә белеменең текстологик нигезләре..........................96
2.4.Тәрҗемә белеменең культурологик һәм социологик аспектлары..104

Бүлек буенча өстәмә әдәбият...114

III бүлек. ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫНЫҢ ТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ
3.1. Тәрҗемәгә өйрәтүне оештыруның гомуми принциплары..115
3.2. Тәрҗемәченең һөнәри компетенциясе.................................122
3.3. Тәрҗемә өйрәтү методикасы фәненең уку-укыту эчтәлеге...134
3.4. Тәрҗемә күнекмәләре...139
3.5. Тәрҗемәгә өйрәтү күнегүләре...143
3.6. Бәйләнешле текст белән эшләү...150
3.7. Телдән тәрҗемәгә өйрәтү...152

Бүлек буенча өстәмә әдәбият...164

КЕРЕШ

Безнең илебездә гасырлар дәвамында төрле милләт кешеләре тыгыз әдәби-мәдәни багланышларда яшиләр, алар арасында һәртөрле фәнни, техник, сәяси һәм эшлекле мәгълүмат алмашы бара. Бу хәл кешелек эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә тәрҗемәчелекнең әһәмияте артуга китерә.

Рус һәм татар телләре дәүләт теле булып кулланылган Татарстан Республикасы шартларында рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итүнең теоретик һәм практик әһәмияте аеруча зур. Төрле дәүләт һәм иҗтимагый учреждениеләрдә, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәләрендә ике тел янәшә кулланылганлыктан, югары квалификацияле тәрҗемәчеләргә дә ихтыяҗ көннән-көн үсә.

Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы белән тәрҗемәче һөнәрләре нигезендә уртак таләпләр ята: татар һәм рус телләренең лексик-грамматик үзенчәлекләрен, аларның стилистик кулланылышын, орфографик нормаларын һәм кагыйдәләрен белмәгән, тәрҗемә әдәбиятка, дәреслекләргә үз мөнәсәбәте булмаган филолог-укытучының Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләрендә хезмәт куюын күз алдына китерү дә кыен. Тәрҗемәченең туган теленнән белемнәре төплерәк һәм тулырак булган саен, тәрҗемә материалның сыйфаты да югарырак була.

Рус телендә бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү мәсьәләләрен яктырткан дәреслекләр шактый. Бу проблеманы эшкәртүгә зур өлеш керткән рус галимнәреннән И.С.Алексеева, Л.С.Бархударов, Л.К.Латышев, В.Н.Комиссаров, А.В.Федоров һ.б.ларның хезмәтләре аеруча игътибарга лаек. Татар тел белемендә әлеге тема соңгы елларга кадәр күз уңыннан читтә кала килде. Дөрес, аерым мәсьәләләр Р.Г.Сибәгатов, Ф.С.Сафиуллина, И.М.Низамов, Р.А.Юсупов кебек күренекле галимнәребезнең хезмәтләрендә элек-электән яктыртылып килә. Бүгенге көндә Татарстан югары уку йортларында, аерым алганда КДУда эшләүче яшь галимнәр бу өлкәгә үзләренең лаеклы өлешләрен кертәләр. Тик шулай да тәрҗемә теориясен үз туган телебездә яктырткан дәреслеккә ихтыяҗ үзен сиздерә әле.

“Тәрҗемә белеменең теоретик нигезләре” дип аталган әлеге укыту-методик ярдәмлек өч бүлектән тора: “Гомуми тәрҗемә теориясе нигезләре” дип исемләнгән беренче бүлек укучыларны тәрҗемәнең асылы һәм әһәмияте, тәрҗемәнең төп принциплары, дөрес һәм ялгыш тәрҗемә төшенчәләре, тәрҗемә эквивалентлыгы типлары, тәрҗемәдә семантик тәңгәллекләр, тәрҗемә трансформацияләре, тәрҗемә процессының моделен төзү, тәрҗемәче эшчәнлегенең стратегиясе кебек теоретик мәсьәләләр белән таныштыруны күздә тота. Икенче бүлек “Тәрҗемә белеменә гомумлингвистик кереш” дип атала, анда тәрҗемәнең лингвосемиотик, текстологик, культурологик һәм социологик нигезләре яктыртыла. “Тәрҗемәгә өйрәтү методикасының теоретик нигезләре” бүлегендә тәрҗемәгә өйрәтүне оештыруның гомуми принциплары, тәрҗемәченең һөнәри компетенциясе, тәрҗемә фәннәренең уку-укыту эчтәлеге, тәрҗемә күнекмәләре, тәрҗемәгә өйрәтү күнегүләре, бәйләнешле текст белән эшләү, телдән тәрҗемәгә өйрәтү проблемаларына багышлана.

Бу китап укытучыларга һәм студентларга, тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләргә тәрҗемәнең теоретик нигезләрен татар телендә үзләштерү өчен ышанычлы кулланма булыр дигән өметтә калабыз.

I бүлек.
ГОМУМИ ТӘРҖЕМӘ ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

1.1. ТӘРҖЕМӘНЕҢ АСЫЛЫ ҺӘМ ӘҺӘМИЯТЕ

Тәрҗемә – кеше эшчәнлегенең иң борынгы төрләреннән берсе. Билгеле, җир йөзендә беренче тәрҗемәче кайчан пәйда булганлыгы турында берәү дә төгәл генә әйтә алмый, археологларның кайчан да булса аның сөякләрен табуы шикле. Тәрҗемәчеләр үзләре дә һөнәрләре иң борынгылардан исәпләнсен дип дәгъва кылмыйлар. Тик шулай да безнең планетабызда төрле телләрдә сөйләшүче кабиләләр барлыкка килгән көннән башлап төрле кабилә вәкилләре белән багланышларда арадашчы булырдай кешеләргә ихтыяҗ туган дип әйтергә тулы нигез бар. Мөгаен, беренче тәрҗемәчеләр хатын-кызлар булгандыр. Борынгы заманнарда чит кабиләдән хатынлыкка кыз урлау гадәте булганлыгы мәгълүм һәм ул хатын, теләсә теләмәсә дә, иренең телен өйрәнергә мәҗбүр булган, ике кабилә аралашканда, кирәге чыкса, тәрҗемәче вазифаларын да үтәгән. Табигый, башта тәрҗемәләр телдән генә башкарылган, соңрак, язу уйлап табылгач, язмача тәрҗемә итүчеләр дә барлыкка килгән.

Күп санлы фактлар тәрҗемәнең берничә мең елдан артык тарихы булу турында сөйли. Безнең эрага кадәр өч мең ел элек язылган чөй язулы шумер текстлары арасында икетелле сүзлекләр табылган, алар тәрҗемәчеләргә ярдәмлек булып хезмәт иткән булырга тиеш. Борынгы Вавилонда һәм Ассириядә дә тәрҗемәчеләр төркеме яшәве билгеле, алар буйсындырылган халыкка идарәчеләрнең хөкемнәрен-боерыкларын җиткерә торган булганнар. Ә борынгы Мисырда хәтта тәрҗемәчеләр хәзерли торган махсус мәктәп тә булган. Гомумән, төрле телләрдә сөйләшүче халыкларны яулап алу нигезендә барлыкка килгән борынгы империяләрнең яшәешен тәрҗемәчеләрдән башка күз алдына да китерү мөмкин түгел.

Шул рәвешчә, тәрҗемәчелек эшчәнлеге күп гасырлык бай тарихка ия дип әйтә алабыз.

Тел - дөньяны өйрәнү, тану, кешеләрнең үзара аралашу, аңлашу чарасы. Ләкин дөньяда халыкларның һәм милләтләрнең

саны күп булган кебек, телләрнең дә саны күп. Төрле телләрдә сөйләшүче халыклар бер-берсе белән күбесенчә тәрҗемә аша аңлашалар. Тәрҗемәчеләр бер телдә әйтелгән яки язылган фикерне икенче бер телдә сөйләшүчеләр өчен аңлаешлы итәләр. Шулай итеп, тәрҗемә халыклар арасында аңлашу һәм аралашу коралы булып хезмәт итә.

Тәрҗемә түбәндәге очракларда башкарыла ала:

1) бер телдән икенче телгә – кардәш, кардәш булмаган, якын кардәш телләргә;

2) әдәби телдән диалектка, диалекттан әдәби телгә, диалекттан икенче бер әдәби телгә (киресенчә була алмый);

3) телнең борынгы формасыннан хәзерге телгә.

Тәрҗемә әдәбият үсә, катлаулана барган саен, аны гыйльми яктыртуга, нигезләүгә мохтаҗлык һәм игътибар арта бара. Аның белән шөгыльләнү тәрҗемә практикасы өчен генә түгел, ә бөтен филология фәне өчен дә әһәмиятле. Ләкин шуны әйтергә кирәк: тәрҗемә теориясе – филологиянең яшь тармакларыннан берсе. Ул, өйрәнү объекты, проблематикасы ачыклана барып, фәнни дисциплина буларак әле күптән түгел генә аерылып чыкты, формалашты.

“Тәрҗемә” төшенчәсенең эчтәлеге

“Тәрҗемә” төшенчәсе аңлаткан эшчәнлек бик зур күләмгә ия. Бер телдән икенче телгә шигырьләр, хикәя, повесть, романнар, публицистика, төрле өлкәләргә караган фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр, дипломатик документлар, рәсми эш кәгазьләре, сәясәтчеләрнең мәкаләләре һәм чыгышлары, газета мәгълүматлары, төрле телләрдә сөйләшүче кешеләрнең әңгәмәләре, кинолар һ.б. тәрҗемә ителә. Тәрҗемәнең гамәли асылы һәркемгә аңлаешлы. Ул – тел-әдәбият өлкәсендәге иҗади эшчәнлек. Ләкин тәрҗемә төшенчәсенә билгеләмә бирүдә бердәмлек юк диярлек. Төрле хезмәтләрдә төрле характердагы билгеләмәләр очратырга мөмкин.

Зур Совет Энциклопедиясе тәрҗемәгә мондый билгеләмә бирә: “Тәрҗемә – ул нинди дә булса текстны (язманы яки җанлы сөйләмне) икенче бер тел чаралары белән әйтеп бирү”. Бу

билгеләмәдә тәрҗемә эшенең төп үзенчәлекләре чагылдырылган: ул – бер телдәге текстны икенче телгә күчерү.

А.В.Федоров хезмәтендә тәрҗемәгә түбәндәге билгеләмә китерелә: "Тәрҗемә итү – бер тел чаралары ярдәмендә әйтеп бирелгәннәрне, эчтәлек белән форманың аерылгысыз бердәмлеген саклап, төгәл һәм тулы итеп, икенче тел чараларына күчереп бирү дигән сүз".

И.И.Ревзин һәм В.Ю.Розенцвейг тәрҗемәнең асылын семиотика фәне күзлегеннән аңлаталар: "Тәрҗемә итү – бер төрле билгеләр системасыннан икенче төрле билгеләр системасына күчерү".

Р.Г.Сибәгатов фикеренчә, тәрҗемәгә билгеләмә биргәндә ике нәрсә күздә тотылырга тиеш: 1) тәрҗемәнең тышкы, формаль ягы – бер тел чараларына алмаш (эквивалент) итеп икенче тел чаралары алыну; 2) тәрҗемәнең эчтәлек ягы – бер-берсен алмаштыра торган чараларның мәгънәви-стилистик, эмоциональ-экспрессивлык үзенчәлекләре белән туры килүе.

Тәрҗемәнең формаль ягы тулысы белән эчтәлеккә буйсынган була. Тәрҗемә өчен кирәкле чара бары тик эчтәлек уртаклыгы нигезендә генә сайлап алына. Ә оригинал белән тәрҗемә арасында формаль уртаклык эзләү үзмаксат була алмый. Эчтәлекләре туры килгән ике чара формаль-грамматик яктан бик ерак торырга мөмкин.

Р.Г.Сибәгатов тәрҗемәгә мондый аңлатма бирә: "Тәрҗемә – чынбарлыкка мөнәсәбәт уртаклыгы нигезендә, бер тел чараларын икенче тел чаралары белән алмаштыру".

Фикерләрнең болай төрле булуы, әлбәттә, очраклы хәл түгел. Бу, барыннан да элек, тәрҗемә эшенең күпьяклы, катлаулы булуыннан килә.

"Тәрҗемә" сүзе барлык кешеләргә дә аңлаешлы һәм таныш сүзләр рәтенә керсә дә, кеше эшчәнлегенең аерым бер төре, бу эшнең нәтиҗәсе буларак, ул төгәллек кертүне һәм термин буларак билгеләмә бирүне таләп итә. Хәзерге фәндә "тәрҗемә" термины түбәндәге мәгънәләрдә кулланыла:

1) чыганак телдә (сөйләмдә) туган тел әсәренең (текст яки сөйләмә) икенче бер тәрҗемә теленә күчерелүеннән гыйбарәт булган психик акт процессы;

2) әлеге процессның нәтиҗәсе, ягъни тәрҗемә телендәге яңа сөйләм әсәре (язмача яки телдән текст).

Әлеге ике мәгънә тыгыз бәйләнештә, беренчесе һәрвакыт икенчесен күздә тота, әмма һәр икесенең дә үзенчәлекләре бар. Тәрҗемәне процесс буларак өйрәнү психолог һәм психолингвистларның игътибарын җәлеп итә. Шулай да бу эш белән күбрәк тел һәм әдәбият белгечләре шөгыльләнә.

Тәрҗемә процессы ике этаптан тора:

1) тәрҗемәче, оригиналны укып, анда чагылдырылган чынбарлык күренешләрен ачыклый;

2) әлеге күренешне тәрҗемә теле чаралары ярдәмендә тасвирлап бирә. Башкача әйткәндә, оригиналдан тәрҗемәгә бару *чынбарлык* аша үтә:

оригинал ↔ чынбарлык ↔ тәрҗемә

Шул ук вакытта *чынбарлык* оригинал белән тәрҗемәне эчтәлекләре ягыннан чагыштыру өчен үзенә бер төрле үлчәү берәмлеге булып тора. Бер үк предметның, эш-хәрәкәтнең, үзлекнең, мөнәсәбәтнең төрле телдә төрле чара белән белдерелүе мөмкин. Ләкин шуңа карамастан, һәрбер тел материаль дөньяны, безнең аңыбыздан тыш яши торган реаль чынбарлыкны чагылдыра, шунлыктан төрле тел берәмлекләрен тиңләштерү өчен шарт барлыкка килә. Шуңа күрә бер тел чараларын икенче тел чаралары белән һәрвакыт алмаштырып була.

Тәрҗемәнең төп берәмлекләре

Бөтен әсәрне, текстны, хәтта бер битне дә тоташ килеш тәрҗемә итеп булмый. Шунлыктан тәрҗемәче, гадәттә, оргинал текстын билгеле бер кисәкләргә, берәмлекләргә бүлгәли дә, аларның мәгънә һәм сәнгать эчтәлеген икенче телгә шулай ук аерым берәмлекләр ярдәмендә күчерә. Әнә шул берәмлекләрне *тәрҗемә берәмлекләре* дип, аларның иң күп кулланылганын исә *тәрҗемәнең төп берәмлеге* дип атыйлар.

Телдәге һәртөрле берәмлек – *фонемадан алып бөтен бер текстка кадәр* – тәрҗемә берәмлеге була ала. Шул ук вакытта тәрҗемә берәмлеге текст эчендә даими рәвештә үзгәреп тора – ул әле сүз, әле сүзтезмә, әле җөмлә була.

Тәрҗемәнең төп, чагыштырмача даими берәмлегенә килгәндә, теориядә бердәм фикер юк. Шулай да тәрҗемәнең төп берәмлеге итеп ***җөмлә***не күрсәтергә була, чөнки ул һәр телдә дә сөйләмнең тәмамланган, бөтен, төп берәмлеген тәшкил итә. Оригинал җөмләсе тәрҗемәдә мөмкин булганча сакланырга тиеш.

Тәрҗемәнең әһәмияте

Телләр бик күп. Аларның барысын да белеп бетерү мөмкин түгел. Әгәр тәрҗемәләр булмаса, без үз илебездәге һәм чит илләрдәге халыкларның әдәбияты һәм сәнгате, фәне-техникасы һәм, гомумән, тормышы белән таныша алмас идек. Үзләре дә, телләре дә беткән борынгы халыкларның рухи иҗат хәзинәләрен тәрҗемәдән башка белү мөмкин түгел. Кешелек белеменең иң беренче баскычларыннан хәзерге югарылыкка үсүен җанлы күренеш итеп ничек күз алдына китерү өчен дә тәрҗемә кирәк. Тәрҗемә кешеләрне шул бөек мирас белән дә, хәзерге заманның искиткеч казанышлары белән дә таныштыра, шулай итеп һәр халыкның рухи дөньясын киңәйтә, башка халыкларны ихтирам итәргә, дус күрергә өйрәтә.

Без тәрҗемә аша һәр көнне илебез һәм дөнья яңалыклары турында мәгълүмат кабул итәбез, фән-техника яңалыклары белән танышабыз, тәҗрибә уртаклашабыз, уку-укыту әсбапларыннан файдаланабыз, ниһаять, халкыбызның әдәбият хәзинәсен баетабыз. Әдәби тәрҗемә аркасында төрле халыкларның рухи байлыклары халыклар өчен уртак хәзинәгә әйләнә. Икътисади бәйләнешләр белән беррәттән, бу мәдәният алмашы халыклар арасында дуслык бәйләнешләренең үсүенә хезмәт итә. Бер халык үзенең рухи байлыклары белән башка халыкларны баета алган кебек, үзе дә шул халыкларның иҗатыннан үз мәдәни хәзинәсен тулыландыра ала.

Ләкин тәрҗемә эшенең әһәмияте моның белән генә чикләнми. Ул тәрҗемә итүче телнең үзен баета, аны яңа төшенчәләр һәм сүзләр белән тулыландыра, аның кулланылыш чикләрен киңәйтә.

“Тәрҗемә теориясе” предметының үзенчәлекләре

Тәрҗемә теориясе, башка фәннәр кебек үк, практиканы өйрәнеп, андагы аерым күренешләрне, фактларны гомумиләштерүдән гыйбарәт. Тәрҗемә фәне практика өчен әзер рецептлар бирә алмый һәм бирергә тиеш тә түгел. Ул, тәрҗемә процессындагы бик күп аерым очракларны хәл итү өчен нигез хезмәтен генә үти, ягъни якынча күрсәтмәләр генә бирә. Тәрҗемәче исә, теория тәкъдим иткән гомуми күрсәтмәләргә таянып, һәр мәсьәләне үзенчә хәл итә.

Тәрҗемәне тәрҗемә теориясеннән аера белергә кирәк. Гамәли яктан гаять әһәмиятле эшчәнлек төре буларак, тәрҗемә үз теоретик нигезләре булуны да таләп итә. Тәрҗемә теориясенең төп бурычы – төп нөсхә белән тәрҗемә арасындагы мөнәсәбәтләрнең закончалыкларын күзәтү, тәрҗемәнең аерым очракларын фәнни күзлектән чыгып гомумиләштерү һәм турыдан-туры тәрҗемә практикасына ярдәм итү. Шул рәвешчә, тәрҗемә теориясенең төп объекты – оригинал белән тәрҗемә нисбәте, аңлату һәм гомумиләштерү таләп иткән конкрет очракларда алар алган формалардагы аермалык.

Тәрҗемә теориясенең үзенчәлеге – тикшеренү предметына объектив мөнәсәбәт, ягъни төп игътибарны тәрҗемәдә булырга тиешле нәрсәләргә түгел, бәлки тәрҗемәнең конкрет мөмкинлекләренә, тәрҗемә өлкәсендә реаль яши торган очракларга юнәлтү. Тәрҗемә теориясе нигезләмәләре тәрҗемә практикасын алдан фаразламый, алар системалаштыру һәм гомумиләштерү характерында була. Болар белән беррәттән, теория тикшерелә торган күренешләр җыелмасына карата кулланыла алырлык, билгеле бер күләмдәге фәнни төшенчәләр һәм категорияләр системасын да күздә тота.

Тәрҗемә теориясенең гамәли һәм фәнни әһәмияте зур. Тәрҗемә эшендә тәрҗемәченең субъектив башбаштаклыгын минимум дәрәҗәсенә җиткерердәй яки бөтенләй бетерердәй фәнни принциплар зарурлыгы аның гамәли әһәмиятен билгели. Һәрбер иҗат һәм тәнкыйди эшчәнлек гомумиләштерүләргә мохтаҗ, алардан башка зур масштабларда нәтиҗәләр ясау мөмкин түгел. Элек яшәгән һәм хәзерге тәрҗемәчеләр юкка гына

үзләренең телгә, әдәбиятка, дөньяга мөнәсәбәтләре белән бәйле карашлар системасына таянмыйлар.

Тәрҗемә теориясенең фәнни кыйммәте аның объектына бәйле төрле кызыксынулар белән бәяләнә. Тәрҗемә, ике телнең тел һәм әдәбиятка караган котылгысыз бәйләнешен күздә тоткан иҗади эш буларак, оригиналны башка тел чараларына күчерүдән гыйбарәт. Тәрҗемә материалларын һәм телләрне чагыштыру нәтиҗәсендә күп кенә проблемалар, мәсьәләләр ачыклана. Алар әлеге телләрне аерым караганда һич кенә дә барлыкка килә алмас иде. Бу мәсьәләләрне анализлау һәр аерым телнең үзенчәлекләрен яхшырак күзалларга ярдәм итә.

Табигатьтәге, җәмгыять тормышы һәм эшчәнлегендәге барлык башка күренешләр кебек үк, тәрҗемә киң кырлы тикшерү-өйрәнү объектын тәшкил итә. Тәрҗемә мәсьәләләре тарихи-мәдәни, әдәбият белеме (матур әдәбият тәрҗемәсе очрагында), тел белеме, психология һ.б. күзлектән тикшерелергә мөмкин.

Тәрҗемәне әдәбият белеме яктылыгында өйрәнгәндә тәрҗемәдә кулланылган тел күренешләрен күзәтергә, тел чараларын анализларга һәм бәяләргә туры килә. Һәм бу табигый да, чөнки төп нөсхәнең эчтәлеге үзеннән-үзе, мөстәкыйль яши алмый. Ул бары тел чараларында чагылыш тапкан форма белән бердәмлектә генә барлыкка килә һәм тәрҗемәдә дә тел чаралары аша гына бирелергә мөмкин. Теге яки бу ил әдәбиятында тәрҗемәнең роле, тәрҗемәдә төп нөсхәне башкача аңлау, үзгәртеп бирү – болар барысы да билгеле бер тел чараларын куллануга карый.

Тәрҗемә һәрвакыт тел белән эш иткәнгә күрә, даими рәвештә тел өстендә эшләүне аңлата, чөнки тәрҗемә, ике тел мөнәсәбәтләренең характеры һәм аларның стилистик чаралары мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгән булу аркасында, лингвистик яктан өйрәнүне таләп итә. Тәрҗемәне өйрәнүгә лингвистик якын килү аның нигезенә – телгә кагыла. Телдән башка тәрҗемәнең бер генә функциясе дә (иҗтимагый-сәяси, мәдәни, танып белү һ.б.) тормышка ашырыла алмас иде. Шуның белән беррәттән, тәрҗемәне лингвистик күзлектән өйрәнү, ягъни аны ике тел мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә тикшерү эшне төгәл итеп, телнең объектив фактларына таянып башкарырга ярдәм итә. Тәрҗемәдә

оригиналның эчтәлеге ничек чагылыш табуы, әдәби әсәрнең образлары ни рәвештә бирелүе яки яңадан тудырылганлыгы турында фикер йөртүләр һәм тишеренүләр, тәрҗемәдә кулланылган тел чараларын анализлауга таянмаса, нигезсез булачак.

Билгеле, тәрҗемә өлкәсендәге барлык фактларны да лингвистик күзлектән аңлату мөмкин түгел. Мәсәлән, тәрҗемәченең оригинал эчтәлегенә мөнәсәбәте, аны ничек шәрехләве, кайвакыт үзгәртеп бирүе (аерым урыннарын төшереп калдыру, өстәү, аерым мәгънәви үзгәртүләр кертү һ.б.) белән бәйле фактларны тел күзлегеннән аңлатып булмый. Болар һич кенә дә лингвистикага карамый, бәлки идеология һәм тәрҗемәченең яки тулы бер әдәби юнәлешнең эстетикасы белән бәйле була. Әмма шулар белән бергәттән, матур әдәбият тәрҗемәсенең тел осталыгы, авторның индивидуаль стилен бирү кебек гаять мөһим мәсьәләләре ныклы тел белеме нигезләрен таләп итә: төп нөсхәнең традиционлык яки новаторлык дәрәҗәсе һәм аның тәрҗемәгә стилистик яктан якынлыгы бары тик чагыштырыла торган ике телнең әдәби нормаларына мөнәсәбәттә генә билгеләнә, бәяләнә ала. Шул рәвешчә, тәрҗемәне лингвистик юл белән өйрәнү, барлык проблемаларның куелышы һәм хәл ителеше өчен җитәрлек булмаса да, аларны җентекләп тикшерүдә бик мөһим.

Тәрҗемә мәсьәләләренә лингвистик якын килү гамәли мәгънәдә дә зур әһәмияткә ия: ике тел төзелешендәге аермаларны тирәнтен аңлау гына теләсә кайсы оригиналны тәрҗемә итүчене мәгънәви хаталардан, тәрҗемә телен “ирексезләү”гә, бозуга китергән буквализмнан азат итәчәк. Матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итүченең эше телләрне практик белүдән һәм тел сиземләве, аннан оригинал образларын ачу һәм яңадан тудыру, автор белән аваздаш, фикердәш булу, ике тел арасындагы охшашлык һәм аермалыкларны теоретик яктан белү һәм аңлаудан гына тора дип уйлау ялгыш булыр иде. Дөрес, болар да әһәмиятле, әмма эш алар белән генә чикләнми. Монда тәрҗемәнең букваль төгәллегеннән читкә тайпылу зарурияте булган күп кенә закончалыкларны да белергә кирәк.

Әгәр филология фәненең аерым тармагы буларак матур әдәбият тәрҗемәсе тел белеменең әдәбият белеме белән, шулай

ук әлеге телләр белән бәйле халыкларның тарихы белән тыгыз хезмәттәшлеген күздә тотса, гомуми тәрҗемә теориясе барыннан да элек күп кенә лингвистик мәсьәләләрне тикшерүне таләп итә.

Тәрҗемә теориясе фәне бу өлкәдә яшәп килүче закончалыкларны өйрәнүне бурыч итеп куя. Чыганак һәм тәрҗемә телләрен өйрәнү нәтиҗәсендә генә алар арасындагы закончалыклы мөнәсәбәтләрне ачыкларга, гомумиләштерүләр ясарга мөмкин. Шушы юл белән генә тәрҗемә теориясен тел һәм стилистик закончалыкларга нигезләнгән объектив фәнни дисциплинага әверелдерергә була. Бу закончалыкларның яшәеше тәрҗемә өлкәсендә гамәли һәм теоретик эшләр башкарырга мөмкинлек бирә. Аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын өчен, тәрҗемә теориясен теге яки бу очракта ничек тәрҗемә итәргә кирәклеге турындагы тар гамәли рецептлар һәм кагыйдәләр җыелмасы белән берләштерүдән сакланырга кирәк. Катгый рәвештә мондый кагыйдәләрнең була алмавын һәм, теория белән практика тыгыз бәйләнгән булуга карамастан, аларның төрле бурычларны хәл итүен ассызыклау мөһим. Тәрҗемә теориясе тәрҗемә тәҗрибәсе фактларын анализлый, аңлата һәм гомумиләштерә, телләр арасында тәңгәллекләр урнаштыра һәм аермалыкларны күрсәтә. Ул тәрҗемә практикасы өчен фәнни нигез булып хезмәт итә ала. Тәрҗемә теориясе ачыклаган гомуми закончалыклар нигезендә аерым очракларга карата нәтиҗәләр чыгарырга, вариантлар табарга була. Билгеле, бу очракта мәсьәләләрне хәл иткәндә теге яки бу шаблоннардан качарга кирәк. Бары чикләнгән очракларда гына (бик гади, мәсәлән, машина тәрҗемәсенә бәйле очракларда) норматив принциплар эшкәртергә мөмкин. Ике тел арасында закончалыклы мөнәсәбәтләр, теге яки бу дәрәҗәдәге якын тәңгәллекләр булу һәрвакыт бер үк тәрҗемә ысулларыннан файдаланырга кирәклеген аңлатмый. Хәлиткеч рольне һәрвакыт контекст, конкрет очрак уйный. Хәтта иң катгый фәнни дәлилләр абруйлы шәхесләр тарафыннан исбатланган булса да, теләсә кайсы ысул буенча норматив күрсәтмә практикада аңлы иҗади мөнәсәбәт таләп итә.

Матур әдәбият тәрҗемәсе, өлешчә фәнни һәм иҗтимагый-сәяси тәрҗемә, сәнгать буларак, стандарт чишелешләрне аеруча “кичерә” алмый. Чын практикада

тәрҗемәченең элеккеге эш тәҗрибәсендә күрелмәгән мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк булган очраклар чыгып тора. Һәр аерым очракта текстның мәгънәсе һәм стилистик бизәкләре бу мәсьәләне ни дәрәҗәдә дөрес чишүгә бәйле була. Шунлыктан тәрҗемә теориясе һәм практикасы бурычларын фәнни тикшерүне чикләү гаять мөһим.

Тәрҗемә теориясенең төрләре һәм башка фәннәр белән бәйләнеше. Тәрҗемә төрләре

Тәрҗемә теориясенең *гомуми* һәм *хосусый* төрләре бар. Гомуми теория барлык телләр тәрҗемәләре өчен уртак. Ул һәртөрле телдән һәртөрле телгә тәрҗемә өчен яраклы гомуми принциплар һәм методлар төзи.

Хосусый тәрҗемә теориясе конкрет бер телдән икенче телгә тәрҗемә мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Мәсәлән, рус теленнән татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә теориясе, инглиз теленнән рус теленә, рус теленнән инглиз теленә тәрҗемә теорияләре һ.б.

Тәрҗемә теориясе, материалның жанр үзенчәлегеннән чыгып, *матур әдәбият тәрҗемәсе, иҗтимагый-сәяси тәрҗемә, фәнни тәрҗемә, газета-журнал материаллары тәрҗемәсе, эш кәгазьләре тәрҗемәсе* һ.б. аерым-аерым да өйрәнә.

Тәрҗемә теориясе фәне бик күп фәннәр белән бәйләнештә тора. Тәрҗемә ике тел белән эш иткәнгә, ике тел арасында тәңгәллекләр табуга корылган булганга, тәрҗемә теориясе фәне, иң элек, *чагыштырма грамматика* фәне белән бәйләнгән.

Тәрҗемә мәсьәләләрен өйрәнгәндә төп ике юнәлеш бар. Берәүләр тәрҗемәнең әдәби-эстетик ягына, художество (сәнгать) чараларының бер телдән икенче телгә ничек күчерелүенә зуррак игътибар бирәләр һәм, табигый, әдәбият белеме категорияләре белән сүз йөртәләр. Димәк, тәрҗемә теориясе *әдәбият белеме* белән дә нык бәйләнгән.

Икенчеләр исә тәрҗемә мәсьәләләрен тел белеме җирлегендә карыйлар, оригинал белән тәрҗемә арасындагы лексик-грамматик һәм күпмедер дәрәҗәдә стилистик

мөнәсәбәтләрне дә ачыклауны максат итеп куялар. Димәк, бу яктан тәрҗемә теориясе *тел белеме* белән тыгыз мөнәсәбәттә тора.

Тәрҗемәнең асылы бер телдә белдерелгән фикерне икенче бер тел чаралары белән әйтеп бирүдән гыйбарәт. Димәк, монда фикерләү белән ике тел арасында үзенчәлекле бәйләнеш, бердәмлек бар. Шуңа күрә тәрҗемә теориясе фикерләү белән оригинал һәм тәрҗемә телләре арасындагы бәйләнешне өйрәнә. Шулай итеп, тәрҗемә теориясе *логика* фәне белән дә тыгыз бәйләнештә тора.

Тәрҗемәгә анализ ясаганда, аның оригиналга туры килү-килмәү мәсьәләсен хәл иткәндә, әсәрдә сурәтләнгән аерым фактларны өйрәнергә, ачыкларга туры килә. Ул фактлар, әсәрнең характерыннан чыгып, аерым халыкларның тарихына, көнкүрешенә, сәяси вакыйгаларга, төгәл фәннәргә карыйлар. Димәк, тәрҗемә теориясе *тарих, этнография, фәлсәфә, физика, математика* һ.б. бик күп фәннәр белән бәйләнешкә керә.

Тәрҗемәнең үзен төрле яктан төркемләргә мөмкин:

- сыйфатына карап, *сүзгә-сүз, букваль, ирекле, төгәл, адекват һ.б. тәрҗемәләр* була (бу турыда “Дөрес һәм ялгыш тәрҗемә төшенчәләре” бүлекчәсендә сөйләнәчәк);
- тәрҗемә ителә торган материал нигезендә *матур әдәбият* һәм *мәгълүмати тәрҗемәләр* аерыла (“Тәрҗемәче эшчәнлегенең стратегиясе” бүлекчәсендә төп аермалар күрсәтеләчәк);
- тәрҗемәне башкару рәвеше буенча *язма* һәм *телдән тәрҗемәләр* билгеләнә.

Язмача һәм телдән эшләнә торган тәрҗемәләрне чагыштырып тикшереп карыйк. Телдән тәрҗемә итүче язмача тәрҗемә итүчедән ничек аерыла, аларның эшчәнлегендә кисешү нокталары бармы?

Элегрәк телдән тәрҗемә итүче чит телдә сөйләшүче әйткәннәрне икенче тел вәкилләренә аңлатып бирә, язмача тәрҗемә итүче исә икенче телгә күчерә, икенче язма текст барлыкка китерә дип аералар иде.

Тәрҗемәнең бу ике төре арасындагы төп охшашлык – алар икесе дә яңадан әйтеп бирү процессыннан гыйбарәт. Тик

телдән тәрҗемә сөйләмне сөйләм формасына күчерә, язуга теркәми. Моннан тыш ул “ашыгыч” эшләнә, вакыт аермасы булмый. Бу аерма бер үк телдәге язма һәм сөйләмә текстлар арасындагы аермага охшаган кебек.

Хәзерге вакытта телдән һәм язма сөйләм бик нык якыная һәм аерым очракларда кушылып та китә. Телдән сөйләм кайчак алдан әзерләнгән текстка нигезләнә; ә кинәт барлыкка килгән телдән сөйләм заманча яздыру җайланмалары ярдәмендә язма текстка әверелә.

Шулай да, язмача текст төрлелеге, эчтәлеге ягыннан катлаулырак. Язма тәрҗемә вакытында бу кыенлыклар вакыт хисабына җиңеп чыгыла. Башкача әйткәндә, язмача тәрҗемәгә вакыт күбрәк бирелә. Соңгы елларда төрле сәбәпләр (конкуренция, оперативлык, вакыт кысанлыгы һ.б.) аркасында язмача тәрҗемә дә кыска вакытлар эчендә эшләнә башлады. Әмма барыбер, телдән тәрҗемә белән чагыштырганда, язмача тәрҗемәнең төгәллегенә, эквивалентлыгына таләпләр элеккечә югары кала бирә.

Хәзер бу ике төр тәрҗемәнең берникадәр якынаюы сизелсә дә, аерма киләчәктә дә сакланачак: телдән тәрҗемә сөйләм вакытында аралашканда турыдан-туры яки синхрон рәвештә башкарыла. Телдән тәрҗемә психик ныклык һәм физик чыдамлылык сорый. Аның каравы, телдән тәрҗемә текстлары гадирәк була – бу тәрҗемәченең эшен шактый җиңеләйтә.

Телдән тәрҗемәнең түбәндәге төрләре аерып карала:

1) *ишетеп тәрҗемә итү.* Сөйләүче мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә фразаны әйтә һәм пауза ясый, шул арада тәрҗемәче ишеткәнен икенче телгә тәрҗемә итеп өлгерә.

2) *ике яклы тәрҗемә.* Ике яки берничә кеше үз туган телләрендә сөйләшә. Тәрҗемәче әле бер, әле икенче телгә тәрҗемә итә.

3) *кәгазь буенча тәрҗемә итү.* Тәрҗемә итәр алдыннан тәрҗемәчегә таныш булмаган текст бирелә. Күзләре белән эчтән генә укып, ул текстны тәрҗемә телендә язылган кебек “укый”, тәрҗемә итә.

4) *яза барып эзлекле тәрҗемә итү.* Оратор шактый озак вакыт дәвамында (25-30 мин.) сөйли, тәрҗемәче эчтән генә тәрҗемә итә, язып бара. Сөйләүче чыгышыннан соң шуларга

нигезләнеп тәрҗемә итә. Куелган бурычларга бәйле рәвештә, мондый тәрҗемә тулы яки кыскартылган формада була.

5) *күрмә таяныч* (зрительная опора) *ярдәмендә синхрон тәрҗемә итү.* Тәрҗемәчегә колакчыннар (наушник) бирелә, шуның аша ул ораторның сөйләмен ишетә һәм алдан бирелгән чыгыш текстына таянып, тәрҗемәне 2-3 секунд аерма белән микрофонга сөйләп бара.

6) *турыдан-туры синхрон тәрҗемә.* Алдагысына охшаган, ләкин текст биреп куелмый, ишеткән буенча гына тәрҗемә ителә. Кагыйдә буларак, бу вакытта тәрҗемәче кабинада утыра. Шулай ук бу төр тәрҗемә "пышылдау" ысулы белән дә башкарылырга мөмкин, ягъни тәрҗемәче тәрҗемәне кабул итүче (рецептор) белән янәшә утыра һәм ишеткәнен аңа пышылдап тәрҗемә итеп бара.

Тәрҗемәченең хокуклары һәм бурычлары

Һәр һөнәрнең мәгълүм әхлакый нормалары һәм белгечләрнең үз-үзен тоту законнары бар. Аларны бозарга һәм алардан тайпылырга ярамый. Билгеле, алар һәрвакытта тыюлар рәвешендә булмаска да мөмкин. XX гасырда Россиядә тәрҗемәчеләрнең һөнәри этикасы формалашырга да өлгермәстән, тулысынча диярлек җимерелүгә дучар булды. Моның үз сәбәпләре бар иде һәм, нәтиҗәдә, тәрҗемәчеләр дә, клиентлар да – барысы да тәрҗемәнең ни икәнен белә, ә аның нинди булырга тиешлеге турында үзенчә уйларга ирекле иде. Кайчандыр бу әхлак нормаларына сыймаган ситуация кемнәр өчендер кулай булды, ә хәзерге вакытта ул тәрҗемәченең һөнәри имиджына бик нык аяк чала. Шуның белән бергә, дөнья практикасында тәрҗемәченең һөнәри кодексы турында күзаллаулар күптән формалашкан һәм аны белү һәрбер тәрҗемәче өчен дә мөһим.

Тәрҗемәченең хокуклары һәм бурычлары:

1. Тәрҗемәче – бер телдә туган сөйләмә яки язма текстны икенче бер телгә күчереп чагылдыручы ***транслятор*** ул.

2. Тәрҗемәче өчен оригинал тексты ***кагылгысыз***. Димәк, әгәр дә заказ бирүче тарафыннан сайлап алу, өстәү,

төшереп калдыру кебек өстәмә бурычлар куелмаган булса, тәрҗемә иткәндә тәрҗемәче үз теләге белән текстны үзгәртә, кыскарта яисә киңәйтә алмый.

3. Тәрҗемә вакытында тәрҗемәче һәрвакыт үзе генә белгән һөнәри юллар белән чыганак текстның максималь дәрәҗәдә ***инвариантын*** тудырырга омтыла.

4. Кайбер очракларда (телдән эзлекле тәрҗемә барышында яки синхрон тәрҗемә иткәндә) тәрҗемәче ***дипломат*** вәкаләтенә ия затка да әйләнә (мәсәлән, халыкара контактлар вакытында эре сәясәтчеләрнең фикерләрен тәрҗемә иткәндә). Әгәр дә тәрҗемәче әлеге вәкаләтләргә чын-чынлап ия булса, ул, дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда ярдәмче зат вазыйфасын үтәп, бу мөнәсәбәтләрнең кискенләшүенә киртә кую максаты белән, чыганак текстның төгәллегенә хилафлык та китерә ала, әмма бу очракта аның теге яки бу якның мәнфәгатьләрен яклавы мәҗбүри түгел.

5. Калган очракларда тәрҗемәче якларның мөнәсәбәтләренә катнаша алмый, аның шулай ук тәрҗемә ителә торган текстка карата үз фикерләрен белдерү хокукы да юк.

6. Тәрҗемәче тәрҗемә ителә торган материал эчтәлегенә карата конфединциальлек сакларга бурычлы һәм кирәкә-кирәкмәгәнгә аны башкаларга җиткерергә дә тиеш түгел.

7. Тәрҗемәче аңа гына билгеле булган юллар белән оригинал һәм тәрҗемә теле, тәрҗемә техникасы һәм текстның тематикасы өлкәсендә тәрҗемәне югары дәрәҗәдәге компетентлык белән тәэмин итәргә тиеш.

8. Тәрҗемә компетентлыгының югары дәрәҗәсенә ирешү өчен, тәрҗемәче тиешле шартларны, шул исәптән үз хезмәтенә туры килердәй шартларны да таләп итәргә хаклы (телдән тәрҗемә вакытында – трансляцияли торган аппаратураның ышанычлылыгын, кирәк булганда ораторның сөйләм тизлеген киметүне; синхрон тәрҗемә вакытында – ораторларның чыгышын алдан бирүне, эшләгәндә ял итәр өчен паузалар һ.б.; язмача тәрҗемәдә – кирәкле белешмә әдәбият һәм сүзлекләр, темага караган әдәбият белән тәэмин итүне һ.б.).

9. Тәрҗемәче тәрҗемәнең сыйфаты өчен җавап бирә; ә матур әдәбият һәм публицистик тәрҗемә очракларында ул закон

тарафыннан якланган авторлык хокукларына да ия, тәрҗемә әсәре басылганда тәрҗемәченең исеме күрсәтелү мәҗбүри.

1.2. ТӘРҖЕМӘНЕҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ

Тәрҗемәнең төп ике принцибы бар дип санала:

- тәрҗемә оригиналны мөмкин кадәр тулы гәүдәләндерергә тиеш;
- тәрҗемә иҗади булырга тиеш.

Ләкин бу ике принцип – күпмедер дәрәҗәдә каршылыклы күренешләр. Шуңа күрә тәрҗемә тарихында әле бер, әле икенче як белән мавыгу хәлләре булып торган. Шулай да бездә оригинал үзенчәлекләре шактый тулы сакланган иҗади тәрҗемә үрнәкләре дә күп. Шул практикага таянып, теория тәрҗемә төгәллек һәм иҗадилыкның уңышлы кушылмасына ирешергә тиеш дигән таләп куя. Шушы төп таләпне үтәү тәрҗемә принципларын саклауның төп нигезен тәшкил итә.

Тәрҗемә турындагы күп кенә хезмәтләрдә матур әдәбият тәрҗемәсенә бер төрле, башка тәрҗемәләргә икенче төрле принциплар күрсәтелә. Дөрес, төрле жанр тәрҗемәләренең үзенчәлекләре бар. Әмма югарыда исәпкә алынган принциплар барлык тәрҗемәләр өчен дә уртак дигән фикер яши.

Тәрҗемәнең төп принциплары барлык телләр арасындагы тәрҗемәләр өчен дә һәм тәрҗемә ителә торган материалның һәр төре өчен дә бер үк: алар оригналның эчтәлек һәм форма бердәмлеге икенче телгә мөмкин кадәр тулы итеп күчерелергә тиеш дигән таләптән чыгып төзеләләр.

Тәрҗемәнең төп принципларыннан беренчесе һәм иң әһәмиятлесе – ***оригиналның мәгънәсен, эчтәлеген, идеясен тулы бирү.*** Эчтәлек формага караганда әһәмиятлерәк, беренче дәрәҗәдә булганга, оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен бирү – тәрҗемәнең төп бурычы. Башка таләпләр шушы төп бурычны үтәү җирлегендә килеп чыга.

Мәгънәне, эчтәлекне тулы бирү принцибы *тәрҗемә төгәл булырга тиеш* дигән таләп белән аерылгысыз бәйләнгән. Тәрҗемә төгәл булмаса, анда оригиналның мәгънәсе тулы бирелә алмый һәм, киресенчә, төп нөсхәнең мәгънәсе тулы бирелмәсә, тәрҗемәнең төгәл булуы мөмкин түгел.

Төгәллек проблемасы тәрҗемә белән шөгыльләнүче кешеләрнең элек-электән игътибар үзәгендә булган һәм еш кына бәхәсләр чыганагына әверелгән. Ни генә булмасын, оригиналның бер генә өлеше дә үзгәрмәскә, авторның яхшы яклары да, начарлары да төгәл бирелергә, төшереп калдырулар да, үзгәртүләр дә булырга тиеш түгел, әсәрдә кимчелекләр булса, аларны да дөрес күрсәтергә кирәк.

Тәрҗемәдә кайчак төгәллеккә ялгыш тиңләштерелә торган, ләкин аның белән уртаклыгы булмаган *буквализм* яки *хәрефкә-хәреф тәрҗемә* төшенчәсе бар.

Тәрҗемә теориясе хәрефкә-хәреф тәрҗемә булмаска тиеш дип өйрәтә. Чөнки, болай эшләгәндә, оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен, сәнгать үзенчәлекләрен, авторның стилен тулы биреп булмый, шуның өстенә, тәрҗемә теле нормалары да бозыла, һәм тәрҗемә укучыга авыр аңлашыла.

Буквализмны *төгәллек* белән бутарга ярамый. Букваль яки хәрефкә-хәреф тәрҗемәдә оригинал теле элементларын калькалаштыру төп нөсхәнең эчтәлеген һәм форма бердәмлеген ачуга, тулы итеп бирүгә хезмәт итми, киресенчә, аны ялгыш, буталчык итеп күрсәтә. Димәк, төгәллек дигән төшенчә тулы кыйммәтле, дөрес тәрҗемәне күз алдында тотса (төгәл тәрҗемә составына, аның бер өлеше буларак, акланылган сүзгә-сүз тәрҗемә дә керергә мөмкин), буквализм төшенчәсе ялгыш, начар тәрҗемәне, тискәре күренешне белдерә.

Эчтәлек формадан башка була алмый: алар аерылгысыз бәйләнештә. Тәрҗемәдә әсәрнең мәгънәсен, эчтәлеген, фикерен бирү турында гына уйлап, аның формасын да икенче телгә күчерү хакында онытырга мөмкин түгел. Шуңа күрә дә ***оригиналның форма элементларын икенче телдә гәүдәләндерү*** тәрҗемә принципларының әһәмиятлеләреннән санала.

Форманы бирү үзмаксат түгел, аны икенче телгә күчерү оригиналның эчтәлеген тулы гәүдәләндерү бурычы белән бәйләнгән.

Тәрҗемәдә әсәрнең формасын бирү форманы тәшкил иткән күп төрле тел чараларын (образлылык элементларын, сурәтләү чараларын, җөмлә төзелешен, сүз тәртибен,

интонацияне һ.б.) икенче телгә күчерүне, дөресрәге икенче телдә аларга тиң чаралар табуны күздә тота.

Форманы тулы гәүдәләндерү турындагы фикерләр ***тәрҗемә оригиналга стиль ягыннан туры килергә тиеш*** дигән принципка кайтып кала. Чыннан да, төп нөсхәнең үзенчәлекләре: сурәтләү чаралары, образлылык элементлары, интонациясе һ.б. икенче телдә тулы кыйммәтле итеп бирелә икән, бу – тәрҗемә оригиналга стиле буенча тиң дигән сүз. Башкача әйткәндә, тәрҗемәче авторга хас язу алымнарына (тропларга, гади сөйләм сүзләренә, диалекталь сүзләргә һ.б.) туры килерлек чаралар таба, шулай итеп, тәрҗемә телендә оригиналныкына тиң стиль тудыра.

Оригиналга мәгънәсе, эчтәлеге, формасы һәм стиль үзенчәлекләре буенча тиң тәрҗемә шул ук вакытта аңа эстетик яктан да туры килә. Чөнки әсәрнең эчтәлек һәм форма берлеге укучыда билгеле бер эмоцияләр, хис-кичерешләр тудыра, аңа тәэсир итә. Шул вакытта тәрҗемә эстетик яктан да оригиналга тиң була, һәм ул шулай булырга тиеш тә. Тәрҗемәнең ***эстетик яктан төп нөсхәгә тиң булырга тиеш***леге тәрҗемәнең тагын бер төп принцибын тәшкил итә.

Алдагы принцип ***иҗадилыкны*** күздә тота. Чын, дөрес, оригиналга тиң тәрҗемәгә иҗади эшләгәндә генә ирешергә мөмкин. Машина тәрҗемәсеннән тыш һәртөрле тәрҗемә – иҗади процесс. Бу төзелешләре буенча төрле телләрнең төрлечә, үзенчәлекле булуы белән, шунлыктан алар арасында һәр очракка да яраклы даими эквивалентлар табарга мөмкин булмау белән аңлатыла. Билгеле бер тел чаралары белән белдерелгән мәгънәне, фикерне, сәнгатьлелекне икенче бер тел чаралары ярдәмендә чиксез күп вариантларда биреп була. Тәрҗемәченең бурычы – шул күп төрле вариантларның берсен, эчтәлеге, формасы буенча оригиналга мөмкин кадәр якынрагын эзләп табу, сайлап алу. Сайлап алынган вариантның никадәр уңышлы булуы тәрҗемәченең осталыгына, тырышлыгына һ.б. бәйле. Әнә шул эзләү, сайлау иҗадилыкны тәшкил итә дә инде. Иҗадилык тәрҗемә ителә торган материалның төрле жанрында төрле дәрәҗәдә чагыла. Матур әдәбият, бигрәк тә поэзиядә иҗадилык көчлерәк күзәтелә. Фәнни әдәбият, эш кәгазьләре тәрҗемәләрендә иҗадилык чагыштырмача түбәнрәк була.

Тәрҗемә теориясе һәм практикасы өчен тәрҗемәченең иҗадилыкны *үзиреклелек, башбаштаклык* белән бутамавы, алар арасында чик үткәрә белүе бик әһәмиятле.

Тәрҗемәченең иҗаты бары тик тел өлкәсенә генә карый. Оригиналның эчтәлегенә, мәгънәсе, сәнгатьлелегенә, стиль үзенчәлекләренә килгәндә исә тәрҗемәченең иҗаты турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Тәрҗемәченең бурычы – төп нөсхәнең эчтәлеген, авторның фикерләрен, стилен икенче телгә мөмкин кадәр тулы, төгәл итеп күчерү. Тәрҗемәнең асылы шуннан гыйбарәт. Кайбер тәрҗемәчеләр, иҗадилык дигән төшенчәне ялгыш аңлап яки аңлы рәвештә, оригиналны үзләренә ошаганча үзгәртәләр: әсәрнең мәгънәсе бозыла, автор кулы, стиле югала, нәтиҗәдә тәрҗемәче авторга хыянәт итә.

Үзирекле тәрҗемә итүнең сәбәпләре берничә:

- чит әдәбият әсәрен туган телләрендә укучыларга якынайту ниятеннән, аны җиңелрәк үзләштерсеннәр, тулырак аңласыннар дигән теләк белән “төзәтеп” тәрҗемә итү;
- тәрҗемәченең оригиналны ошатмыйча, теге яки бу урыннарын килештермичә, үзе теләгәнчә төзәтүе, аерым урыннарын кыскартуы яки бөтенләй төшереп калдыруы;
- тәрҗемә эшенең кыенлыгы: кайчак бер телдә әйтелгән нәрсәне икенче телдә белдерү үз дигәнчә, яңача әйтүдән дә кыен була;
- тәрҗемәченең оригинал телен яхшы белмәве.

Ләкин нинди генә сәбәп булмасын, үзиреклелек чын, дөрес тәрҗемә принциплары белән сыеша алмый.

Нәтиҗә ясап, тәрҗемәнең ***төп принципларын*** билгелик:

- тәрҗемә оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен, идеясен максималь тулы, төгәл бирергә тиеш;
- тәрҗемәдә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, милли үзенчәлеге мөмкин кадәр тулы гәүдәләнергә тиеш;
- тәрҗемә оригиналга эстетик яктан да туры килергә тиеш;
- тәрҗемә иҗади процесс, әмма тәрҗемәченең үзиреклелегенә, башбаштаклыгына юл куелмаска тиеш;
- буквализм – чын, дөрес тәрҗемәгә комачаулый торган тискәре күренеш;

- тәрҗемә теле дөрес, әдәби, җанлы, бай, эмоциональ булырга тиеш.

Оригиналны икенче телдә дөрес, тулы гәүдәләндерүнең төп *ике шарты* бар:

- беренчедән, тәрҗемәче үзе эш итә торган ике телне дә бөтен тулылыгы, нечкәлекләре белән белергә тиеш;
- икенчедән, тәрҗемәченең оригиналда сурәтләнгән халыкның тормышын, тарихын һәм гомумән оригиналда сүз барган нәрсәләрне шактый әйбәт белүе таләп ителә.

Шушы ике шарт үтәлгәндә тәрҗемәнең уңышлы булачагына шик юк.

1.3. ДӨРЕС ҺӘМ ЯЛГЫШ ТӘРҖЕМӘ ТӨШЕНЧӘЛӘРЕ

Дөрес һәм ялгыш тәрҗемә терминнары уңай һәм тискәре мәгънәдәге тәрҗемә төрләрен гомумиләштереп атау өчен, шартлы рәвештә кулланыла. Дөрес тәрҗемә дигәннән, *төгәл, адекват* яки *тулы кыйммәтле тәрҗемәләр*не, дөрес булмаган тәрҗемә дигәндә *буквалы* яки *хәрефкә-хәреф, формаль тәрҗемәләр*не аңларга кирәк. *Сүзгә-сүз тәрҗемә* һәм *калькалаштыру* төшенчәләре, урынына карап, уңай мәгънәдә дә, тискәре мәгънәдә дә кулланылырга мөмкин.

Төгәл тәрҗемә. Тәрҗемә мәсьәләләре белән шөгыльләнүчеләрнең күбесе төгәл тәрҗемә дигәндә тәрҗемәнең оригиналга эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да максималь якын булуын аңлыйлар. “Төгәл тәрҗемә” төшенчәсе кайбер теоретиклар тарафыннан хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү, чит тел элементларын кирәмәгәнгә күчерү мәгънәсендә дә кулланылган. Уңай мәгънәдәге төгәл тәрҗемә төшенчәсе тәрҗемә теле элементларының оригинал теле элементларына һичшиксез туры килүен аңлатмый. Төгәл тәрҗемәдә, мәгънә дөреслеге булганда, форма тәңгәллеге булмаска да мөмкин. Шунлыктан кайбер теоретиклар “төгәл тәрҗемә” дигәндә, форма элементлары оригиналныкына туры килмәгәндә алмаштырулар куллана торган, ләкин оригинал мәгънәсе дөрес бирелгән тәрҗемәне күздә тоталар. Ләкин, гадәттә, андый тәрҗемәне *адекват* яки *тулы кыйммәтле тәрҗемә* дип атыйлар.

“Төгәл тәрҗемә” дип оригиналга эчтәлеге буенча да, форма, тел элементлары буенча да туры килә торган аерым моментларга әйтү дөрес. Мондый төгәллекнең буквализм, формализм белән уртаклыгы юк: монда оригиналның тел формаларын гәүдәләндерү эчтәлекне һәм тәрҗемә теле нормаларын бозуга китерми, киресенчә мәгънәне тулырак бирүгә ярдәм итә.

Адекват (тулы кыйммәтле) тәрҗемә. Адекватлык термины туры килү, тәңгәл булуны аңлата. Адекват тәрҗемә принцибы оригиналның эчтәлеген һәм сәнгать үзенчәлеген тулы итеп гәүдәләндерүне күздә тота. Бу яктан адекват тәрҗемә кайчак төгәл тәрҗемәгә бик якын килә. Әмма адекватлык туры һәм читләтелгән тәңгәллекләрдән, ягъни алмаштырулардан да тора, төгәл тәрҗемә белән аның аерым элементлары гына туры килергә мөмкин. *Туры тәңгәллекләр* – аерым кисәкләрнең мәгънә суммасы оригиналдагы бөтеннең мәгънәсенә туры килә торган сүзтезмә, сурәтләү чаралары, синтаксик төзелмәләр, фигуралар, ритм, интонация һ.б. Ләкин адекватлык составында төгәл тәрҗемә элементларының булмавы да мөмкин. Адекват тәрҗемәнең төгәл тәрҗемәдән өстенлеге шунда: ул төп нөсхәдәге сүз, сүзтезмә, җөмлә, сурәтләү чараларын оригинал элементларына форма үзенчәлекләре белән туры килмәгән, ләкин контекстта белдергән мәгънәләре буенча һәм функция-стиль ягыннан туры килә торган тел элементлары һәм образлы-сурәтләү чаралары белән алмаштыру хокукына ия. Адекват тәрҗемә төшенчәсен адекват алмаштыру төшенчәсеннән аера белергә кирәк. *Адекват тәрҗемә* – күптөрле тәңгәллекләр һәм алмаштырулар җыелмасы. Ә *адекват алмаштыру* аерым бер тәрҗемә акты белән бәйләнгән һәм ул билгеле бер күләмдәге текст составында гына теге яки бу элементны алмаштырудан гыйбарәт. Андый алмаштыру аерым тел берәмлекләренә дә, сәнгать чараларына да карый (сүз, мәкаль, әйтем, фразеологизм һ.б.).

Реалистик тәрҗемә. Реалистик тәрҗемә төшенчәсе тулы кыйммәтле тәрҗемә төшенчәсенә каршы куела һәм ул, нигездә, тәрҗемә иҗатын оригинал иҗатка тиңләштерүне күздә тота. Ул тәрҗемәдә шактый дәрәҗәдә үзиреклелеккә юл куя, чөнки ул тәрҗемәчегә зур ирек бирүгә корылган. Реалистик тәрҗемә

матур әдәбият тәрҗемәсен генә күздә тотып эшләнгән. Реалистик тәрҗемә төшенчәсе кайбер хезмәтләрдә тулы кыйммәтле, дөрес тәрҗемә мәгънәләрендә дә, адекват тәрҗемә терминының синонимы буларак та кулланыла.

Тәрҗемәгә багышланган кайбер хезмәтләрдә *натуралистик, романтик тәрҗемә* һ.б. төшенчәләр дә очрый. Ләкин алар дөрес яки ялгыш тәрҗемәнең әһәмиятле якларын чагылдырмыйлар һәм тәрҗемә теориясендә сизелерлек урын алып тормыйлар.

Сүзгә-сүз тәрҗемә – төп нөсхәнең һәр сүзе икенче телгә гомуми мәгънәсендәге аерым сүз белән бирелә торган тәрҗемә. Бу төшенчә уңай мәгънәдә дә, тискәре мәгънәдә дә йөри.

Уңай мәгънәдәге сүзгә-сүз тәрҗемә – тәрҗемә теленә зыян китермичә, оригиналның эчтәлек һәм форма элементларын максималь төгәл гәүдәләндерүгә юнәлдерелә торган һәм, димәк, аңлы рәвештә эшләнә торган, үз-үзен аклый торган тәрҗемә.

Сүзгә-сүз тәрҗемә – тәрҗемә чылбырында әһәмиятле буын. Сүзгә-сүз күчерү таләбе еш кына төп нөсхәнең эчтәлеген һәм үзенчәлеген мөмкин кадәр тулы бирү ихтыяҗыннан туа. Сүзгә-сүз тәрҗемә таләбе күп очракта аклана, ул төрле телләр һәм төрле материаллар тәрҗемәләрендә кулланыла. Оригиналның тел һәм сәнгать чараларын сүзгә-сүз тәрҗемә итү кайчак төп нөсхәнең милли үзенчәлекләрен һәм автор стилен бирүдә әһәмиятле һәм бердәнбер чара булып тора. Бу бигрәк тә сурәтләү чараларын (сүз-образлар, фразеологик әйтелмәләр, мәкаль-әйтемнәр) гәүдәләндерүдә күренә. Сүзгә-сүз тәрҗемә – тәрҗемә телен баету, үстерү чарасы да.

Тискәре мәгънәдәге сүзгә-сүз тәрҗемә – оригиналдагы аерым сүзләргә туры тәңгәллекләр булып килгән сүзләрнең мәгънә суммасы төп нөсхәдәге мәгънә һәм образлы-эмоциональ эчтәлеккә туры килми һәм, тәрҗемә теле нормалары сакланмый торган тәрҗемә. Мондый тәрҗемә теле образлылыгын, матурлыгын югалта, әсәрнең укучыга тәэсир итү көче кими. Андый сүзгә-сүз тәрҗемәне *буквализм* дип тә атыйлар.

Калькалаштыру сүзгә-сүз тәрҗемәдән бик аз аерыла һәм еш кына аның синонимы булып йөри. Калькалаштыру да, асылда, оригиналның аерым элементларын тәрҗемә теленең аерым элементлары белән бирүдән гыйбарәт. Калькалаштыруны

ялгыш яки дөрес тәрҗемә дип кенә карап булмый. Аны һәр очракта нинди нәтиҗә бирүеннән чыгып бәяләргә кирәк. Бер очракта калькалаштыру оригиналның теге яки бу элементын бирүдә әһәмиятле чара булырга, икенче очракта – мәгънәне һәм тел нормаларын бозуга китерергә мөмкин. Калькалаштыру рус фразеологизмнарын тәрҗемә иткәндә еш кулланыла. Ул бер телдә икенче тел үрнәгендә синтаксик формалар төзүне дә белдерә. Ләкин русчадан татарчага тәрҗемә иткәндә уңышсыз калькалар да очрый.

Буквализм *(хәрефкә-хәреф тәрҗемә)* төшенчәсенә тискәре мәгънә генә салынган, ул һәрвакыт ялгыш тәрҗемәне генә белдерә. Буквализм – оригиналның мәгънәсенә, эчтәлегенә, тәрҗемә теленең дөреслегенә, сәнгатьлелегенә зыян китерү бәрабәренә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләрен катгый рәвештә гәүдәләндерү. Буквализм нигезендә төгәллек, сүзгә-сүз күчерү, калькалаштыру төшенчәләрен ялгыш аңлау ята.

Буквализм – үзирекле тәрҗемәнең антонимы. Үзирекле тәрҗемәдә оригиналның мәгънәсе һәм үзенчәлеге тәрҗемәченең төп нөсхәдән артык ерак китүе аркасында бозылса, хәрефкә-хәреф тәрҗемәдә – артык якын килүе, дөресрәге, оригиналга сукырларча иярүе аркасында югала.

Буквализмның сәбәпләре төрле. Ул тәрҗемәченең үзе эш итә торган телләрне, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең закончалыкларын, тәрҗемә принципларын, методларын, оригиналның эчтәлеген тиешенчә белмәү, эш тәҗрибәсе аз булу, осталыгы җитмәү һ.б. аркасында килеп чыга.

Формализм буквализм төшенчәсенә якын тора. Формализм – оригинал эчтәлегенә һәм тәрҗемә теленә зыян китерү бәрабәренә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләрен гәүдәләндерү. Ләкин тәрҗемәдәге формализм, буквализмнан аермалы буларак, билгеле бер теоретик нигезләмәгә туры килә. Ягъни, формализм төшенчәсе форманы эчтәлектән аеру мәгънәсен белдерсә дә, киңрәк төшенчә һәм, ул, тәрҗемәче, форманың билгеле бер элементларын функцияләреннән тыш бирергә теләп, бөтеннең эчтәлегенә һәм форманың башка элементларына игътибар итми торган барлык очракларда да кулланыла.

1.4. ТӘРҖЕМӘ ЭКВИВАЛЕНТЛЫГЫ ТИПЛАРЫ

Тәрҗемә эквивалентлыгы – оригинал һәм тәрҗемә эчтәлекләренең охшашлыгы, мәгънәви якынлыгы.

Тәрҗемәченең төп бурычларыннан берсе – оригиналның эчтәлеген максималь тулы итеп бирү. Кагыйдә буларак, оригинал белән тәрҗемә эчтәлекләренең фактик охшашлыгы аеруча әһәмиятле санала.

Потенциаль ирешергә мөмкин булган эквивалентлык белән тәрҗемә эквивалентлыгын аера белергә кирәк. *Ирешергә мөмкин булган эквивалентлык* дигәндә ике телдәге текстларның эчтәлегендә әлеге текстлар барлыкка китерелгән телләрнең аермалыклары мөмкинлек биргән дәрәҗәдә урнаштырылган максималь гомумилек күздә тотыла. *Тәрҗемә эквивалентлыгы* исә оригинал һәм тәрҗемә текстларының тәрҗемә процессында тәрҗемәче тарафыннан ирешелгән реаль мәгънәви якынлыгын аңлата. Оригинал эчтәлегенең тәрҗемәдә максималь мөмкин булган (лингвистик) саклану дәрәҗәсе тәрҗемә эквивалентлыгының чиген билгели. Тик һәр аерым тәрҗемәдә оригиналга мәгънәви якынлык төрлечә була һәм ул төрле ысуллар белән максималь дәрәҗәгә якынайтыла.

Чыганак һәм тәрҗемә телләре системасындагы аермалыклар һәм бу телләрдәге текст оешу үзенчәлекләре тәрҗемәдә оригинал эчтәлеген тулысынча саклау мөмкинлеген төрле дәрәҗәдә чикләргә мөмкин. Шунлыктан тәрҗемә эквивалентлыгы оригиналга салынган төрле мәгънә элементларының саклануына (шулай ук югалуына) нигезләнә. Тәрҗемәдә эквивалентлыкны тәэмин итү өчен оригинал эчтәлегенең кайсы өлеше бирелүгә бәйле рәвештә, эквивалентлыкның ***төрле дәрәҗәләре*** (типлары) аерыла, тәрҗемәче аларның кайсысы белән генә эш итсә дә, тәрҗемә телара багланышларга хезмәт итә ала.

Теләсә кайсы текст билгеле бер аралашу функциясен башкара: нинди дә булса фактларны хәбәр итә, хис-кичерешләрне белдерә, аралашучылар арасында контакт урнаштыра яисә текстны кабул итүчедән (рецептордан) нинди дер реакция яки эш-гамәл таләп итә һ.б. Аралашу

процессындагы мондый максатларның булуы тапшырыла торган хәбәрләрнең гомуми характерын һәм аларның телдә ни рәвешле бирелешен билгели. Мәсәлән: *Өстәлдә китап ята. Мин язны шундый яратам! Зинһар өчен, бүген безгә кил әле. Син мин әйткәнне ишеттеңме?* Бу хәбәрләмәләрнең һәркайсында аерым сүзләрнең, структураларның үзенчәлегеннән һәм тулаем хәбәрләмәнең конкрет эчтәлегеннән тыш, гомумиләштерелгән функциональ эчтәлекне дә тоярга мөмкин: фактны констатацияләү, экспрессия, өндәү, контакт эзләү һ.б. Текст эзлекле рәвештә яки берьюлы берничә аралашу функциясе дә үтәргә мөмкин. Текст эчтәлегенең аралашу актындагы гомуми сөйләм функциясенә ишарә итә торган өлеше аның *аралашу максаты*н билгели. Аралашу максаты “ирекле” (“күздә тотылган”, “күчерелмә”) мәгънәдән гыйбарәт. Әлеге мәгънә текстта яшерелгән була, мәгънәви бөтен буларак тулаем хәбәрләмәдән килеп чыга. Телнең аерым берәмлекләре бу эчтәлекне белдергәндә үз мәгънәләре аша турыдан-туры түгел, ә башка берәмлекләр белән мәгънәви бөтен төзегән хәлдә катнаша. Рецептор хәбәрләмәне кабул иткән вакытта тел берәмлекләренең мәгънәсен һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен аңлап кына калмаска, бәлки бөтен эчтәлек буенча тиешле нәтиҗәләр ясарга, аннан өстәмә мәгълүмат та алырга тиеш. Ә өстәмә мәгънә оригиналда әйтелгәнне генә түгел, сөйләүче (язучы) моны нәрсә өчен әйтә, моның белән ни әйтергә теләвен дә хәбәр итә.

В.Н.Комиссаров “Тәрҗемә теориясе (лингвистик аспектлар)” хезмәтендә тәрҗемә эквивалентлыгының биш дәрәҗәсен билгели:

1) коммуникация максаты дәрәҗәсендәге эквивалентлык;
2) ситуацияне тасвирлау дәрәҗәсендәге эквивалентлык;
3) хәбәрләмә дәрәҗәсендәге эквивалентлык;
4) хәбәр дәрәҗәсендәге эквивалентлык;
5) тел тамгалары дәрәҗәсендәге эквивалентлык.

Беренче тип тәрҗемә эквивалентлыгы оригинал эчтәлегенең аралашу максатын тәшкил иткән өлешен саклаудан гыйбарәт. Эквивалентлыкның бу дәрәҗәсендәге тәрҗемәләр эчтәлекне детальле күчерү мөмкин булмаганда, шулай ук детальле тәрҗемә рецепторны ялгыш нәтиҗәгә китерү, башка

ассоциацияләр уяту һәм шул рәвешчә аралашу максаты дөрес күчерелүгә комачаулау ихтималы булганда барлыкка килә. Мәсәлән, рус телендәге “поставить крест” фразеологизмын татарча “беткәнгә санау” дип тәрҗемә итү уңышлы.

Эквивалентлыкның **икенче тибы**нда оригинал һәм тәрҗемә эчтәлегенең гомуми өлеше бер үк аралашу максатын белдереп кенә калмый, шулай ук телдән тыш охшаш ситуацияне дә чагылдыра. *Ситуация* – әйтелмәдә сурәтләнгән объектлар һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр җыелмасы. Теләсә кайсы текст нәрсә турында да булса мәгълүмат алып килә, нинди дә булса реаль яки уйлап чыгарылган ситуациягә мөнәсәбәттә була. Бернәрсә турында да булмаган бәйләнешле сөйләм текстын күз алдына да китереп булмый, чөнки фикер фикер предметыннан тыш була алмый.

Аралашу максаты гына сакланган беренче тип эквивалентлык белән чагыштырганда, икенче типта оригинал эчтәлеген тулырак бирү мөмкинлеге төп нөсхәнең бөтен мәгънәви элементларын да күчерүне күздә тотмый. Оригинал белән мөнәсәбәттә караганда, бу очракта да сизелерлек структур-семантик аермалыклар күзәтелә. Эш шунда ки, аерым алган ситуация – катлаулы күренеш, ул бер әйтелмәдә генә төрле яклап, барлык үзенчәлекләре һәм сыйфатлары белән тасвирлана алмый. Һәр аерым хәбәрләмә аны теге яки бу сыйфатларын калкуландырып, шуларга ишарә итеп сурәтли. Бер үк ситуация төрле комбинацияләрдә чагылыш табарга мөмкин һәм шул рәвешчә бер телдә сөйләшүчеләр тарафыннан бер үк нәрсәне аңлата торган синонимик хәбәрләмәләр җыелмасы барлыкка килә, әмма алардагы тел чаралары бөтенләй туры килмәве дә ихтимал.

Эквивалентлыкның икенче тибына оригинал һәм тәрҗемәдә бер үк ситуацияне идентификацияләү, ә сурәтләү ысулын үзгәртү хас.

Ситуацияне идентификацияләү – хәбәрләмәнең эчтәлегендәге теге яки бу реаль ситуацияне мөмкин булган тасвирлау ысулларының берсе ярдәмендә чагылдыру.

Ситуацияне тасвирлау ысулы – хәбәрләмәнең эчтәлегендә ситуацияне идентификацияләү өчен кулланылган һәм эчтәлекле категорияләр рәвешендә гомумиләштерелгән

ситуация билгеләрен чагылдыру. Бу очракта тел һәм чынбарлык арасындагы мөнәсәбәтләрнең универсаль характеры төрле тел текстларын мәгънәви тәңгәлләштерү нигезе булып хезмәт итә.

Бер телдә сөйләшүчеләр төрле ысуллар белән сурәтләнгән бердәй ситуацияләрне тиңләштерә алган кебек, тәрҗемәчеләр дә төрле телдәге сөйләм әсәрләрен шул ук нигездә бер үк мәгънәдә кабул итә, компонентлары арасында охшашлыклар булмаса да, тәрҗемәдә аларны тигезли.

Бу тип эквивалентлыкта оригинал һәм тәрҗемә арасындагы мәгънәви якынлык кулланылган тел берәмлекләренең мәгънә гомумилегенә нигезләнми. Мондый тәрҗемәләрдә оригиналның күп кенә сүзләре һәм синтаксик структуралары турыдан-туры чагылыш тапмый, әмма беренче тип белән чагыштырганда, эчтәлекләрендәге гомумилек зуррак була.

Тәрҗемә әсәрләрдә икенче тип эквивалентлык күп очрый, чөнки һәр телдә билгеле бер ситуацияне тасвирлау өчен икенче телдә кулланылмый торган уңышлырак ысуллар яши.

Тәрҗемәдә ситуация дәрәҗәсендә эквивалентлык урнаштыру зарурлыгы күп очракта теге яки бу тел коллективының билгеле бер очракларда бер төрле генә тасвирлау ысулы куллану белән бәйле. Мәсәлән, “По газонам не ходить” хәбәрләмәсенең мәгънәсен татарча “Газоннан йөрмәскә” диюгә караганда, “Газонны таптамаска” дип бирү кулайрак.

Эквивалентлыкның алда тасвирланган ике тибында оригинал һәм тәрҗемә эчтәлегенең гомумилеге текстның төп эчтәлек элементларын саклауда чагылыш таба. Беренче типта аралашу максаты гына саклана, икенче типта аралашу максаты һәм ситуация бирелә. **Өченче тип**та исә хәбәрләмәнең өч өлеше дә (аралашу максаты, ситуация, ситуацияне сурәтләү ысулы) саклана.

“Эчтәлек элементлары” төшенчәсе “хәбәрләмәнең бер өлеше” яисә “хәбәрләмә эчтәлегенең бер өлеше” дигәнне аңлатмый. Эчтәлекнең алда саналган өлешләре хәбәрләмәдә туры сызык буенча бер-бер артлы килми. Алар хәбәрләмәнең тулы составында, берсе икенчесе аша пирамида оештырган кебек чагылыш таба: үзара бәйләнгән объектларның аерылып

торган билгеләре турындагы мәгълүмат ситуация тасвирламасын бирә, ә ул үз чиратында билгеле бер функция үти.

Текст (хәбәрләмә) эчтәлегендә аралашу максаты, ситуация һәм аны тасвирлау ысулы турында мәгълүмат булу сөйләм ярдәмендә аралашуның үзенчәлеген, аның кешенең максатчан эшчәнлеге, әйләнә-тирә чынбарлык һәм кеше фикерләвендә әлеге чынбарлыкны чагылдыру формасы белән аерылгысыз бәйләнешен күрсәтә. Бу бәйләнеш барлык телләрдә аралашучылар өчен универсаль; аның универсальлеге төрле тел текстларын күп очракларда тәңгәлләштерү мөмкинлеген билгели. Гәрчә телләрнең аермалары тәрҗемәдә ситуацияне тасвирлау ысулын сакларга комачауласа һәм хәтта оригиналның аралашу максатын бирү өчен ситуацияне алыштыруны таләп итсә дә, теләсә кайсы тәрҗемәдә оригинал эчтәлегенең бер, ике, өч һ.б. әһәмиятле өлешләрнең тәңгәллеген тәэмин итү мөмкинлеге бар. Ситуацияне бер төрле итеп тасвирлаганда да төрле семантик вариантлар булырга мөмкин: ситуация теге яки бу дәрәҗәдә җентекләп тасвирланырга, билгеләрнең урыны алышынырга, ситуация билгеләрен гомумиләштерү ысулы үзгәрергә һ.б.

Эквивалентлыкның **дүртенче тибы**нда, эчтәлекнең өч компоненты белән беррәттән (алар өченче типта сакланган иде), тәрҗемәдә оригиналдагы синтаксик төзелмә мәгънәләренең шактый өлеше бирелә. Оригиналның структур оешуында тәрҗемә ителәсе текстның гомуми эчтәлегенә кергән билгеле бер мәгълүмат ачыклана. Хәбәрләмәнең синтаксик төзелеше анда билгеле бер типтагы сүзләрнең билгеле бер эзлеклелектә һәм аерым сүзләр белән билгеле бер бәйләнештә куллану мөмкинлеген билгели, шулай ук күпчелек очракта эчтәлекнең аралашу вакытында беренче планга куелган өлешен ачыклый. Шунлыктан оригиналның синтаксик оешуын тәрҗемәдә мөмкин булганча максималь саклау оригинал эчтәлеген тулырак күчерүгә ярдәм итә. Моннан тыш, оригинал һәм тәрҗемәнең синтаксик параллельлеге әлеге текстлардагы аерым элементларны чагыштырырга булыша.

Тәрҗемәдә охшаш синтаксик төзелмәләр куллану оригинал һәм тәрҗемәдәге синтаксик мәгънәләрнең инвариантлыгын тәэмин итә. Мондый параллельлек дәүләткүләм

һәм халыкара акт текстларын тәрҗемә иткәндә аеруча мөһим, чөнки бу очракларда тәрҗемә оригиналның хокукый статусын ала, ягъни ике текст та бер үк көчкә ия була.

Эквивалентлыкның **бишенче тибы**нда оригинал һәм тәрҗемә эчтәлегендә төрле телләрдә язылган текстлар арасында күзәтелергә мөмкин булган якынлыкка максималь дәрәҗәдә ирешелә.

Оригинал һәм тәрҗемә арасындагы мөнәсәбәтләрнең бу тибына түбәндәге билгеләр хас:

1) текстларның структур оешуында параллельлек югары дәрәҗәдә;

2) лексик состав максималь туры килә: тәрҗемәдә оригиналның һәр мөстәкыйль мәгънәле сүзенә тәңгәллекләр табып була;

3) оригинал эчтәлегенең барлык төп өлешләре тәрҗемәдә саклана.

Оригинал эчтәлегенең алдагы дүртенче тибында сакланган дүрт өлешенә аерым сүзләрнең мөмкин булган максималь охшашлыгы да өстәлә.

Хәбәрләмәгә кергән сүзләрнең семантикасы эчтәлекнең мөһим өлешен тәшкил итә. Телнең төп берәмлеге буларак сүз үз мәгънәсендә катлаулы мәгълүмати комплекс туплый. Ул билгеләнгән объектларның төрле билгеләрен (сүзнең предметлы-логик мәгънәсе), сөйләм коллективына кергән кешеләрнең аларга мөнәсәбәтен (сүзнең коннотатив мәгънәсе) һәм сүзнең телдәге башка сүзләр белән семантик мөнәсәбәтләрен (сүзнең лингвистик мәгънәсе) чагылдыра.

Сүзнең семантикасында мәгълүмат бердәй түгел, анда төрле компонетлар аерылып торырга мөмкин. Аерым алып караганда ул компонентларның һәркайсы икенче тел чаралары белән бирелә ала, әмма сүздәге барлык мәгълүматны берьюлы бирү еш кына мөмкин булмый, чөнки тәрҗемәдә сүз семантикасының аерым өлешләрен югалту хисабына гына аның башка өлешләрен саклап була. Бу очракта тәрҗемәнең оригинал белән эквивалентлыгына сүздәге мәгънәнең аралашу өчен аеруча әһәмиятле (доминант) элементларын күчерү ярдәмендә генә ирешелә.

Аерым предметларның төрле билгеләрен сүз мәгънәсендә теркәгән хәлдә, һәр аерым тел үз “дөнья сурәтен (картинасын)” барлыкка китерә. Мәсәлән, әгәр инглизчә чебен түшәмдә “басып тора” (стоит) дип бирелә алса, русча ул “утырып тора” (сидит), ә татарча чебен түшәмгә “куна”. Нәтиҗәдә, төрле телләрнең сүз мәгънәләрендә тулаем туры килгән семалар әлеге билгегә ишарә иткән объектларның характеры һәм саны ягыннан аерылырга мөмкин. Рус һәм татар телләрендә су һәм сөт кенә кайнатылган була алса (“кипяченный”), инглиз телендә йомырка да шул хәлгә китерелә ала, рус һәм татар телләрендә исә йомырканы “пешерергә” генә ярый (сварить).

Эквивалентлыкның бишенче тибы тәрҗемәдә оригиналның стилистик характеристикасын саклауны да күздә тота. Сүз сөйләмнең аерым төрләрендә (китапча, гади сөйләм, поэтик һ.б.) өстәмә мәгълүмат та алып килә. Күпчелек телләрдә сүзләрнең шактые стилистик нейтраль, ягъни төрле стильләрдә очрый. Нейтраль стилистик характеристика сөйләшүчеләр тарафыннан коннотатив мәгънәнең бер компоненты буларак кабул ителә, шул нигездә сүзне билгеле бер хәбәрләмәләрдә куллану урынлы яки урынсыз булуы турында фикер йөртелә. Предметлы-логик эчтәлеге белән туры килгән сүзләрнең стилистик характеристикасы аерылырга мөмкин.

Оригинал һәм тәрҗемәдә сүзләр барлык компонентлары белән дә, стилистик характеристикасы белән дә туры килсә, эквивалентлыкның югары дәрәҗәсе күзәтелә. Бу терминнар тәрҗемәсендә күп очрый.

Әмма еш кына ике телнең төп мәгънәләре белән туры килгән сүзләре тәрҗемәдә мәгънәсенең стилистик компонентын югалта, ягъни оригиналда стилистик мәгънәле сүз тәрҗемәдә стилистик нейтраль була. Мондый очракларда оригинал һәм тәрҗемәдә сүзләр характеристикасының стилистик компоненты юкка чыга. Бу хәлне компенсацияләргә мөмкин: шул ук хәбәрләмә чикләрендә яки янәшәдәге хәбәрләмәдә икенче бер сүздә югалган стилистик бизәк бирелә ала.

Оригинал һәм тәрҗемәдә сүзләрдәге коннотатив мәгънәләрнең эквивалентлыгы мәгънәнең ассоциатив-образлы компонентын күчерүне күздә тота. Кайбер сүзләрнең

семантикасы сөйләшүчеләр аңында яшәгән билгеле бер ассоциацияләргә бәйле өстәмә мәгълүматны да үз эченә ала. Мәсәлән, күп кенә илләрдә яшәүчеләр өчен “*кар*” – явым-төшемнең бер төре генә түгел, бәлки аклык эталоны, аның белән ак төстәге башка предметларны (чәч, шикәр, кер һ.б.) чагыштыру кабул ителгән. “*Акбур*” – шулай ук ак, әмма аның белән йөз төсе генә чагыштырыла ала. Рус телендә “*щепка*” (йомычка) ябык кешене сурәтли, “*иголка*” (энә) аннан нечкәрәк булса да, анда мондый ассоциация юк. Моңа охшаш очракларда тәрҗемәдә образ алмаштырыла.

Сүзнең лингвистик мәгънәсен тәрҗемәдә чагылдыру денотатив һәм коннотатив мәгънәләрне бирүдән аерыла. Иң элек, оригинал һәм тәрҗемә сүзләренең эквивалентлыгы аларның лингвистик мәгънәләре саклану-сакланмауга бәйле түгел. Сүзгә тел системасы тарафыннан салынган әлеге мәгънә аралашучылар игътибар итми торган мәгълүматны үз эченә ала, чөнки ул фикернең үзе түгел, ә фикер белдерү элементы гына. Лингвистик мәгънәләрне тәрҗемәдә белдерү зарурлыгы ул оригиналда беренче планга чыгарылганда гына туа.

Сүздәге лингвистик мәгънә компонентларының берсе – сүз семантикасында аның аерым морфемалары мәгънәсенең чагылышы. Сүз берничә морфемадан торырга мөмкин. Гадәттә алар тулаем бер мәгънә белдерә, сүзнең мәгънәсе аерым морфемаларның мәгънәсенә бәйле булмый. Әмма алар сүзнең семантикасында яши һәм аерым очракларда беренче планга чыгарыла ала (пароход, самолет, писатель, спутник һ.б).

Сүз составына кергән морфемаларның мәгънәсенә нигезләнгән сүз уйнату хәбәрләмәнең төп эчтәлеген тәшкил итсә, тәрҗемәдә эквивалентлыкка ирешү өчен тәрҗемә телендәге берәмлекләрнең морфемик составы кулланыла.

1.5. ТӘРҖЕМӘДӘ СЕМАНТИК ТӘҢГӘЛЛЕКЛӘР

Хәзерге семиотикада тамгаларның (знак, билге), шул исәптән тел тамгаларының, аерым алганда сүзләрнең дә башка предметлар, сүзләр һәм кешеләр белән өч төп мөнәсәбәткә керүен билгелиләр, димәк, *мәгънәләрнең дә өч төп тибы* була дигән сүз.

1. Тамга һәм ул белдергән предмет арасындагы мөнәсәбәт. Мәсәлән, *өстәл* – мебель/җиһазның билгеле бер предметы; *эт* – билгеле бер төр хайван һ.б. Тамга һәрчак предметны гына белдерми, бәлки эш-хәрәкәт, билге, абстракт төшенчәләр һ.б. да тамга белән белдерелергә мөмкин. Тамга белдергән предмет, процесс, билге, чынбарлык күренешләре тамгаларның **референт**лары дип атала. Тамга белән референт арасындагы мөнәсәбәтне **референциаль мөнәсәбәтләр** дип йөртү кабул ителгән (фәнни әдәбиятта аны атау өчен тагын *денотат, төшенчәле* яки *предметлы-логик мәгънә* дигән терминнар да кулланыла).

Кагыйдә буларак, тамганың референты аерым, индивидуаль, бердәнбер предмет, процесс кына түгел, ә охшаш предмет, процесс, күренешләрнең тулы бер классы референт була. Мәсәлән, *өстәл* сүзенең референтын аерым бер конкрет өстәл түгел, ә охшаш сыйфатлары белән берләштерелгән шундый күп кенә предметлар тәшкил итә; *йөрү* сүзе дә конкрет, индивидуаль, бер генә тапкыр булган хәрәкәтне аңлатмый, аңа “йөрү” классына берләштерелгән күп төрле хәрәкәтләр керә. Билгеле, референты аерым бердәнбер предмет булган тамгалар да бар (мәсәлән, *Лондон, Мәскәү*), әмма аларның саны тамгаларның гомуми күләме белән чагыштырганда күп түгел.

Референты предметларның тулы бер күплегеннән гыйбарәт булган тамгалар да сөйләмдә конкрет, бердәнбер предметны белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *Өстәл яныннан кит* дигәндә әлеге сөйләм ситуациясендә катнашкан конкрет бер *өстәл* күздә тотыла. Бу очракта тамганың **денотат**ы дигән термин кулланыла. Референт һәм денотат төшенчәләрен бутарга ярамый: төрле референтларны белдергән тамгалар конкрет бер ситуациядә бердәй денотатка ия булырга мөмкин, чөнки бер үк предмет бер үк вакытта төрле билгеләре белән берничә класска керә ала. Мәсәлән, “Бу егет – минем танышым, КФЭИ студенты” җөмләсендә *егет, танышым, студент* тамгалары төрле референтларны белдерсәләр дә, бу очракта бер үк денотатка карыйлар.

2. Тамга һәм ул тамганы кулланучы кеше арасындагы мөнәсәбәт. Тамгаларны, шул исәптән тел тамгаларын кулланучы кешеләр аларга һич тә битараф түгел – алар

тамгаларга, шуның аша тамгалар белдергән референтларга үзләренең субъектив мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Мәсәлән, рус телендә *голова* һәм *башка, спать* һәм *дрыхнуть*, татар теледәге *күз* һәм *бәбәк, урлау* һәм *чәлү* сүзләре (тамгалары) бер үк референтларны атыйлар, бердәй референциаль мәгънәгә ия, әмма алар бу тамгалар һәм аларны кулланучы кешеләр арасындагы субъектив мөнәсәбәткә карап аерылалар. Бу субъектив (эмоциональ, экспрессив, стилистик һ.б.) мөнәсәбәтләр **прагматик мөнәсәбәтләр** дип атала, шунлыктан икенче тип мәгънәләрне тамгаларның **прагматик мәгънәсе** (коннотатив, эмотив мәгънә, стилистик һәм эмоциональ бизәк һ.б.) дип йөртәләр. Бу очракта тамга белән аерым бер кеше арасындагы мөнәсәбәтләр түгел, ә бөтен бер кешеләр коллективының тамгага мөнәсәбәте күздә тотыла. Бер үк тел коллективы чикләрендә нинди дә булса төркемгә хас һәм индивидуаль тайпылышлар да булырга мөмкин. Тик тел тамгаларының прагматик мәгънәсе, кагыйдә буларак, шул телдә сөйләшүче барлык кешеләр өчен дә бер була.

3. Бер генә тамга да, шул исәптән тел тамгасы да изоляциядә яши алмый, ул билгеле бер тамгалар системасының состав өлешен тәшкил итә. Бу нисбәттән һәр тамга шул тамгалар системасындагы башка тамгалар белән катлаулы һәм күптөрле мөнәсәбәтләргә керә. Мәсәлән, *өстәл* сүзе *җиһаз, урындык, кәнәфи* һ.б.ш. белән билгеле бер мөнәсәбәттә була. *Агач, түгәрәк, тора* кебек сүзләр белән башка төрле мөнәсәбәткә керә; *аш, язу* һ.б. сүзләр янәшәсендә өченче төрле мөнәсәбәтләр пәйда була. Тел тамгасының шул ук системадагы башка тамгалар белән мөнәсәбәте **лингвистик мөнәсәбәтләр** (башка тамга системаларында – система эчендәге мөнәсәбәтләр) дип атала.

Бу өч тип мәгънәгә семиотикада өч бүлек туры килә:

1) тамгаларның референциаль мәгънәләрен өйрәнә торган бүлек – *семиотика*;

2) прагматик мөнәсәбәтләрне өйрәнү белән шөгыльләнә торган бүлек – *прагматика*;

3) лингвистик мәгънәләр *синтаксис*та өйрәнелә.

Бу өч тип мәгънә үзара тыгыз, аерылгысыз бәйләнештә, чөнки алар бер үк тамганың (берәмлекнең) семантик структурасындагы компонентларны тәшкил итәләр.

Барлык тамгаларның да семантик структурасында бу өч тип мәгънә табылмаска мөмкин. Бер яктан, теләсә кайсы тел системасында референциаль мәгънәсе булмаган тамгалар (ягъни бернинди предмет, күренеш, чынбарлык ситуациясен белдермәгән, бары тик лингвистик мәгънәсе генә булган сүзләр) бар. Мәсәлән, ярдәмлекләр һәм формаль-грамматик элементлар. Икенче яктан, барлык тел тамгаларының да лингвистик мәгънәсе булырга тиеш, юкса ул бу системага керә алмас иде. Өченчедән, барлык тамгаларда да прагматик мәгънәләрнең булу-булмавы бәхәсле мәсьәлә. Тел коллективының билгеле бер тамгаларга нейтраль мөнәсәбәтен исәпкә алганда, бу сорау уңай хәл ителергә мөмкин. Ә инде бары тик күзгә бәрелеп торган уңай яки тискәре мөнәсәбәтләр генә исәпкә алынса, җавап та тискәре булачак. Мәсәлән, *улү – җан тәслим кылу – дөмегү* рәтендә икенче, өченче сүзләр прагматик мәгънәле, ә беренчесендә прагматик мәгънә юк, анда бары референциаль һәм лингвистик мәгънәләр генә бар.

Төп нөсхәдә белдерелгән мәгънә типларының барысын да тәрҗемәдә саклау мәҗбүриме? Тәрҗемәче чыганак текстында белдерелгән референциаль мәгънәләрне генә бирергә тиешме, әллә башка тип мәгънәләрне күчерү дә аның бурычына керәме? Тәрҗемә теориясе өчен бу гаять әһәмиятле мәсьәлә.

Тәрҗемәдә референциаль мәгънәләр югарырак дәрәҗәдә саклана. Моның сәбәбе бик гади: тел берәмлекләренең референциаль мәгънәләрендә әлеге телдә сөйләшүче кешеләр коллективының бөтен тәҗрибәсе чагылыш таба. Төрле тел коллективларын чолгап алган чынбарлык күп очракта туры килгәнлектән, төрле телләрдәге тел берәмлекләренең референциаль мәгънәләрендә дә охшашлыклар, аерымлыкларга караганда, күбрәк күзәтелә. Ә инде чыганак тел коллективының тәҗрибәсендә генә булган предмет һәм ситуацияләр очрагына килгәндә (милли реалияләр), теләсә кайсы тел ярдәмендә теләсә нинди предмет, төшенчә, ситуацияләрне сурәтләп биреп була.

Референциаль мәгънәләр белән чагыштырганда, прагматик мәгънәләр тәрҗемәдә әзрәк саклана. Эш шунда:

тасвирланган предмет, төшенчә, ситуацияләр төрле тел коллективлары өчен күп очракта бердәй булсалар да, төрле халыкның аларга мөнәсәбәте үзгә булырга мөмкин.

Тәрҗемәдә лингвистик мәгънәләрнең сакланышы гаять түбән дәрәҗәдә була. Кагыйдә буларак, тәрҗемә иткәндә алар бөтенләй сакланмый. Моны аңлау кыен түгел: тәрҗемәдә бер тел икенчесе белән алмашына, ә һәрбер тел – үзенчәлекле система, анда элементлар үзара шул телгә генә хас мөнәсәбәттә була. Шуңа күрә чыганак тел берәмлекләренә хас лингвистик мәгънәләр тәрҗемәдә югала һәм тәрҗемә теле берәмлекләренә генә хас мәгънәләр белән алышына. Тәрҗемә процессында оригиналда белдерелгән лингвистик мәгънәләрнең тулысынча саклануын таләп итү абсурд, ул тәрҗемәдән бөтенләй баш тартуга тиң.

Алда әйтелгәннәрдән түбәндәге нәтиҗәне ясап була кебек: тәрҗемәдә иң элек референциаль мәгънәләр саклана; прагматик мәгънәләрнең күчерелеше түбәнрәк дәрәҗәдә була; ә лингвистик мәгънәләр бөтенләй юкка чыга. Башкача әйткәндә, тәрҗемәченең иң төп бурычы – референциаль мәгънәләрне бирү; икенче бурычы – прагматик мәгънәләрне күчерү; өченче бурычы – лингвистик мәгънәләрне күчерергә бөтенләй омтылмау, чөнки аларны тәрҗемә итү гомумән мөмкин түгел.

Мәсьәләнең шушы рәвештә куелуы схематик, әлбәттә, чөнки ул тәрҗемә ителә торган текстның характерын исәпкә алмый. Алда билгеләп үтелгән мәгънә типлары төрле жанр текстларында бердәй роль уйнамый. Мәсәлән, фәнни һәм техник текстларда референциаль мәгънәләрнең роле зур булса, матур әдәбият, аеруча поэзия өчен прагматик мәгънәләр әһәмиятле. Аерым очракларда (шул ук шигъри тәрҗемәдә) мөһим мәгълүмат текст эчендәге берәмлекләрнең лингвистик мәгънәләренә дә салына. Димәк, төрле жанр һәм төрле тип текстларга мөнәсәбәттә караганда, сүздәге мәгънәләрне тәрҗемә итү тәртибенең гомуми схемасын билгеләү мөмкин түгел – һәр аерым очракта тәрҗемәче, тексттагы мәгълүматны мөмкин кадәр тулы саклау өчен, кайсы мәгънәләрне күчерүгә өстенлек бирергә, ә кайсыларын “корбан” итәргә кирәклеген үзе хәл итәргә тиеш.

Референциаль мәгънәләрне тәрҗемә итү

Чыганак текстта белдерелгән референциаль мәгънәләрне тәрҗемә иткәндә тәрҗемәче алдында торган иң зур һәм төп проблема – чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге берәмлекләрнең мәгънә күләмнәре туры килмәү. Мәгънәви берәмлекләре (морфема, сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр) референциаль мәгънәләренең күләме ягыннан тулысынча тәңгәл килгән ике ят тел гомумән юк дияргә була. Гәрчә белдерелгән мәгънәләр ("төшенчәләр") күп очракта туры килсә дә, аларны белдерү ысуллары (төркемләү, таркату һәм берләштерү, бер яисә берничә формаль берәмлек чигендә килү) төрле телләрдә теге яки бу дәрәҗәдә аерыла. Моны ике телнең сүзлек составы материалында ачык күзәтергә мөмкин; тик аермалар сүзләр белән генә чикләнми, телдәге башка берәмлекләргә дә (мәсәлән, грамматик морфемаларга) хас.

Тулаем алганда ике телнең лексик берәмлекләре арасында референциаль мәгънәләрдәге барлык тип семантик тәңгәллекләрнең өч төркемен аерып карарга була:

1) тулы тәңгәллек;
2) өлешчә тәңгәллек;
3) тәңгәллек булмау.

Төрле телләрнең лексик берәмлекләрендәге референциаль мәгънәләрнең *тулы тәңгәл* килү очраклары чагыштырмача сирәк. Гадәттә, болар бер мәгънәле сүзләр, ягъни ике телдә дә бары бер генә лексик мәгънәгә ия сүзләр. Мондый берәмлекләрнең саны гомуми лексик фонд белән чагыштырганда зур түгел. Алар түбәндәгеләр:

1) ялгызлык исемнәр һәм географик атамалар;
2) фәнни-техник терминнар;
3) ай һәм атна көннәре исемнәре.

Бу төркемнәргә кергән барлык сүзләр дә референциаль мәгънәләре белән туры килмәскә мөмкин. Тәрҗемәдә тулы тәңгәллекләр кыенлык тудырмый, аларны бер телдән икенче телгә күчерү контекстка бәйле түгел һәм тәрҗемәче бу сүзләрнең тиешле эквивалентларын катгый белергә генә тиеш.

Ике телнең лексик берәмлекләрен чагыштырганда *өлешчә тәңгәллек* очракларының киң таралганлыгы күзгә

ташлана. Бу вакытта чыганак телдәге бер сүзгә тәрҗемә телендә берничә семантик эквивалент туры килә. Теләсә кайсы телнең күпчелек сүзләренә күпмәгънәлелек хас, шул ук вакытта бер телдә сүзләрдәге мәгънәләр системасы икенче телдәге белән туры килми:

1) чыганак тел сүзенең мәгънәсе тәрҗемә теле сүзенекенә караганда киңрәк, ягъни мәгънәләрнең бер өлеше генә туры килә, ә калганнары икенче телдә башка сүзләр белән бирелә;

2) чыганак телдәге бер сүзгә тәрҗемә телендә берничә сүз туры килә. Чыганак тел сүзе денотатларның киң классын атый, ә тәрҗемә телендә алар һәркайсы таррак денотат классына тәңгәл килә. Икенче тел белән чагыштырганда бу *сүзләрнең мәгънәләре аерылмаган* очрак дип билгеләнә ала.

Рус телендә *рука* – бармак очларыннан иңгә кадәр өлешне белдерә. Инглиз телендә ул ике сүз белән атала: *arm* – иң башыннан кул чугына кадәрге өлеш, *hand* – кул чугы. *Заря*ның инглиз телендә *иртәнге* һәм *кичке* дигән төрләре бар, алар аерым сүзләр белән атала. *Творог* – татар телендә *эремчек, туарок* дип йөртелә.

Киресенчә дә була: тәрҗемә телендәге бер сүз чыганак телдә ике сүз белән бирелә. *Чия – вишня, черешня.*

Бу очракларда күпмәгънәлелек турында сүз бармый, алар бер генә мәгънәгә ия, әмма күләме ягыннан ике телдә туры килми (бер телдә киң, икенчесендә тар).

Рус телендә *рука*ның инглиз сүзләре белән чагыштырганда мәгънәсе аз аерымлануы рус телендә кулның бу өлешләрен аңлатып булмый дигән сүз түгел, аларны бирү өчен сүзләр бар: *плечо, предплечье, кисть*. Татар телендәге *чия* белән дә шулай ук хәл, *черешня*ны кирәк булса *төче чия* дип атарга мөмкин.

Кайбер телләр билгеле бер төшенчәләр арасындагы аерманы белдермәскә мөмкинлек бирсә, икенче тел мәҗбүри рәвештә әлеге аерманы күрсәтүне таләп итә.

Мондый күренешләрне тәрҗемә иткәндә төп кыенлык – чыганак телнең мәгънәсе аерылмаган берәмлеген тәрҗемә теленә күчергәндә булган тәңгәллекләрнең кайсын сайлауны хәл итү. Мәсәлән, рус телендәге *рука* сүзен инглиз теленә тәрҗемә

иткәндә *arm, hand* сүзләренең кайсын сайларга? Дөрес сайлау мөмкинлеген бу очракларда контекст хәл итә.

Ике телнең сүзлек составларында күзәтелергә мөмкин булган өченче очрак – *тәңгәллек булмау*, ягъни бер телнең лексик берәмлегенә туры килгән сүзнең икенче тел лексикасында бөтенләй булмавы. Бу очракны **эквивалентсыз лексика** дип атау кабул ителгән. Әлеге атама белән йөртелгән сүзләргә түбәндәге төркемнәр керә:

1. *Ялгызлык исемнәр, географик атамалар, учреждение, оешма, газета, пароход* һ.б.ш. икенче бер тел лексиконында даими тәңгәллекләре булмаган сүзләр. Эквивалентсыз ялгызлык исемнәре белән даими (тулы) тәңгәллекләре булган сүзләр арасында катгый чик үткәрү кыен: баштарак икенче бер телнең сүзлек запасында эквиваленты булмаган теге яки бу географик атама, ялгызлык исеме, вакытлы матбугатта яки матур әдәбиятта очрый торгач, тәңгәллек алырга мөмкин. Шулай да, гомумән, эквивалентсыз лексикага икенче тел вәкилләренә бик үк таныш булмаган ялгызлык исемнәре һәм географик атамалар керә дип әйтергә була.

2. *Реалияләр*, ягъни башка телдә сөйләшүче кешеләр тәҗрибәсендә генә очрый торган предмет, төшенчә, ситуацияләрне атаган сүзләр. Боларга матди һәм рухи мәдәнияткә караган предметларны – милли ризык атамалары (щи, борщ, рассольник, пәрәмәч, бөккән), милли өс һәм аяк киемнәре (сарафан, кокошник, читек, түбәтәй, калфак), халык биюләре (гопак, трепак, бишле, күпер чыгыш), халык авыз иҗаты әсәрләре (частушки, былины, мифы, притча) керә. Әлеге илгә генә хас сәяси учреждение һәм җәмәгать күренешләрен (агитпункт, ударник, дружинник), сәүдә һәм җәмәгать оешмаларын (дом культуры, парк культуры и отдыха) белдергән сүзләрне дә шушы төркемгә кертергә мөмкин.

Теге яки бу сүз һәм сүзтезмәне кайчан эквивалентсыз лексикага кертергә икәнлеген хәл итү җиңел түгел – окказиональ тәрҗемә эквиваленты да тотрыклы тәңгәллеккә күчә ала.

3. Очраклы *лакуна* дип атап булган берәмлекләр. Бу вакытта ниндидер сәбәпләр белән (ул сәбәпләрне кайчак аңлатып та булмый) икенче телдә сүз яки сүзтезмә рәвешендәге эквиваленты табылмаган сүзләр күздә тотыла. Кайвакыт мондый

сүзләрнең эквивалентлары булмауны мәдәни-тарихи һәм иҗтимагый сәбәпләр белән аңлатырга мөмкин. Мәсәлән, *имененник* һәм *погорелец* сүзләре. Татар телендә *именинник* сүзенең эквиваленты була алмый, чөнки ул христианнардагы “именины” дип аталган гореф-гадәткә бәйле. *Погорелец* сүзенең инглиз телендә эквиваленты булмауны түбәндәге сәбәпләр белән аңлатырга була: революциягә кадәр Россия авылларында пожарлар һәм шуның нәтиҗәсендә крестьян гаиләләренең хәерчелеккә төшүе гадәти күренеш булган. Шул ук вакытта Англиядә хәтта авыл җирлегендә дә йортлар таш яки кирпечтән салынганлыктан, янгыннар сирәгрәк күзәтелгән, шуңа күрә аны махсус атау ихтыяҗы булмаган.

Әмма күп очракларда мондый лакуналарга рациональ аңлатма табу кыен, шуңа күрә ул телнең милли үзенчәлегенә кайтарып калдырыла.

Эквивалентсыз лексика термины икенче бер телнең сүзлек составында тәңгәллеге булмаган берәмлекләргә карата гына кулланыла, аны “тәрҗемә ителми торган сүзләр” дип аңларга ярамый. Инде әйтелгәнчә, теләсә кайсы тел теләсә нинди төшенчәне белдерә ала, теге яки бу төшенчәне аңлату өчен сүз яки тотрыклы сүзтезмә булмау аны икенче тел чаралары белән тасвирлау мөмкин түгеллекне аңлатмый. Гәрчә тел системасында ул тамга булмаса да, аның эчтәлеге конкрет сөйләм текстында күп төрле чаралар белән бирелә ала. Тәрҗемә практикасында эквивалентсыз лексиканы бирүнең түбәндәге чаралары мәгълүм:

а) транслитерация һәм транскрипция;

ә) калькалаштыру;

б) тасвирлаулы (аңлатмалы) тәрҗемә;

в) якынайтып (аналог ярдәмендә) тәрҗемә итү, ягъни тәрҗемә телендә чыганак тел берәмлегенә якын мәгънәле сүз табып күчерү, әмма алар чыганак тел берәмлегенең мәгънәсен якынча гына бирәләр;

г) трансформацияле тәрҗемә. Күп кенә очракларда эквивалентсыз лексиканы бирү өчен җөмләнең структурасын үзгәртергә, чыганак тел сүзенең мәгънәсен бөтенләй алмаштырырга, ягъни лексик-грамматик трансформация ясарга туры килә.

Трансформация, калькалаштыру, тасвирлаулы тәрҗемәләр куллану очрагында окказиональ тәрҗемә эквивалентлары барлыкка килә, ягъни тәрҗемә теленең сүзлек составына кермәгән һәм сөйләмдә “потенциаль” лексик берәмлек буларак йөри торган сүз яки сүзтезмә пәйда була. Еш кына алар тотрыклы эквивалентка әйләнә, башкача әйткәндә телнең сүзлек составына керә һәм тора-бара әлеге телнең аңлатмалы сүзлекләренә дә теркәлергә мөмкин. Бу очракта чыганак тел берәмлеге эквивалентсыз лексикага кертелми башлый.

Югарыда билгеле бер референтка (ягъни бердәй предметлар, процесс, күренешләр классына) караган референциаль мәгънәләр турында сүз алып барылды. Әмма сөйләмдә, конкрет очракта тел тамгалары тулы классны (референтны) атамыйча, аерым бер предмет, күренеш, процессны гына (денотат) атарга да мөмкин.

Тәрҗемә тел белән түгел, бәлки сөйләм белән, конкрет сөйләм текстлары (әсәрләре) белән эш итә. Шунлыктан чыганак тел һәм тәрҗемә теле тамгалары арасындагы тәңгәллек еш кына референтлар дәрәҗәсендә түгел, ә денотатлар дәрәҗәсендә урнаштырыла. Димәк, чыганак тел берәмлеге белән аның тәрҗемә телендәге окказиональ эквиваленты референциаль мәгънәләре белән аерылырга, ә алар белдергән денотатлар туры килергә мөмкин. *Делегация вьетнамских профсоюзов, гостившая в Москве, вчера вылетела на Родину.* Татар телендә *родина* сүзенең эквивалентлары шактый (ватан, туган җир, туган ил, туган як), алар референциаль мәгънәләре белән туры килсәләр дә, прагматик мәгънәләре белән аерылалар. Нейтраль мәгънәне саклау өчен *Вьетнам* сүзен кулланырга мөмкин (ул *родина*ның денотаты), тик *Родина* һәм *Вьетнам* сүзләренең референциаль мәгънәләре бердәй түгел.

Конкретлаштыру, генерализацияләү ысуллары да тасвирланган объектларның денотат дәрәҗәсендәге тәңгәллегенә нигезләнә.

Шул рәвешчә, чыганак тел һәм тәрҗемә теле сүзләре яки сүзтезмәләренең референциаль мәгънәләре аерылу тәрҗемә эквивалентлыгы өчен киртә була алмый – алар белдергән денотатларның тәңгәллеге хәлиткеч роль уйный, шул сәбәпле

сөйләмдә тел системасындагы референциаль мәгънәләре бердәй булмаган эквивалентлар куллану мөмкинлеге туа.

Прагматик мәгънәләрне тәрҗемә итү

Прагматик мәгънә – тамга һәм әлеге тамганы кулланучы кешеләр коллективы арасындагы мөнәсәбәт. Тел ярдәмендә аралашканда кешеләр теге яки бу тамгаларга, аларның референтларына, денотатларына төрлечә мөнәсәбәттә булалар, еш кына бу мөнәсәбәт ул тамгага беркетелә һәм аның семантик структурасындагы даими компонентка әйләнә. Бу очракта ул тел тамгасының **прагматик мәгънәсе** дип атала.

Прагматик мәгънәләр турындагы лингвистик теория, референциаль мәгънәләр турындагы теориягә караганда азрак эшкәртелгән. Шулай да прагматик мәгънә типларын төркемләүнең түбәндәге схемасын күрсәтергә мөкин.

1. *Сүзнең стилистик (семантик) характеристикасы.* Төрле жанр һәм сөйләм типларында күзәтелгән сүзләр (стилистик “нейтраль”) белән беррәттән, телдә кулланылышлары аерым жанр һәм сөйләм типлары белән чикләнгән сүзләр дә яши. Аерым сөйләм жанрларында теркәлүе әлеге сүзләрнең даими характеристикасына, шул рәвешчә прагматик мәгънә компонентына да әйләнә. Бу вакытта “сүзнең стилистик характеристикасы” дигән термин кулланыла.

Сөйләмнең төп ике тибын аерып карарга мөмкин: гадәти көнкүреш сөйләме һәм китапча язма сөйләм. Китапча язма сөйләм чикләрендә матур әдәбият, рәсми-фәнни жанр, публицистик жанрлар аерыла.

Бу җанрлар үзләре төркемнәргә бүленә: матур әдәбият эчендә проза, драматургия, поэзия яши; рәсми-фәнни жанрга караган рәсми-эш кәгазьләре, мәгълүмати-газета материаллары, документаль юридик һәм фәнни-техник текстлар була; публицистика – иҗтимагый-сәяси публицистика, газета-журнал публицистикасы һәм оратор сөйләменә аерыла.

Санап үтелгән сөйләм жанрларының аерым берсендә генә кулланыла торган лексик берәмлекләр юк әлбәттә. Моны истә тоткан хәлдә, телнең лексик составындагы сүзләрдә

стилистик характеристикаларның түбәндәге төрләрен аерып карарга мөмкин:

1) *нейтраль сүзләр* – барлык тип сөйләм жанрларында кулланыла торган, ягъни стилистик бизәксез сүзләр. Моңа теләсә кайсы телнең үзәген тәшкил иткән сүзләр керә;

2) *көнкүреш-сөйләм сүзләре* – “рәсми” булмаган ситуациядә телдән сөйләмдә кулланыла торган, кагыйдә буларак язма сөйләмдә очрамаган сүзләр;

3) *китапча сүзләр* – бары тик язма сөйләмдә генә очрыйлар һәм көнкүреш сөйләмендә кулланылмыйлар;

4) *поэтик сүзләр* – поэзия теленә генә хас сүзләр;

5) *терминнар* – рәсми-фәнни жанрда гына кулланыла торган сүзләр. Моңа бөтен фәнни-техник терминология, дәүләт һәм хокук, икътисад, финанс, хәрби эш, иҗтимагый-сәяси һ.б өлкәләрдә еш очрый торган сүзләр һәм махсус атамаларны кертергә кирәк.

2. *Сүзләрнең регистры.* “Регистр” дигәндә теге яки бу тел чараларын, шул исәптән лексик берәмлекләрне сайлап алу таләп ителгән билгеле бер аралашу шартлары һәм ситуацияләр күздә тотыла. Бу ситуацияне, беренче чиратта, аралашучыларның составы билгели: билгеле бер сүзләр (киңрәк алганда – тел берәмлекләре) якын танышлар, туганнар һ.б. белән сөйләшкәндә генә кулланылырга мөмкин; икенче төркем лексик берәмлекләр аз таныш булган кешеләр, эштә яки социаль яктан югарырак дәрәҗәле кешеләр белән аралашканда күбрәк кулланыла. Икенчедән, сөйләм регистры тел коммуникациясе нинди шартларда узу белән бәйле – хәтта якын дуслар һәм туганнар белән дә рәсми урыннарда өйдәгечә сөйләшү кабул ителмәгән. Тулаем алганда, телдә түбәндәге биш регистр булуын билгеләргә мөмкин:1) фамильяр; 2) табигый (непринужденный); 3) нейтраль; 4) формаль; 5) тантаналы.

3. *Сүзләрнең эмоциональ бизәге.* Теләсә кайсы телдә сүз белдергән предмет, күренеш, билге һ.б.га уңай һәм тискәре бәя чагылыш тапкан берәмлекләр була. Бернинди дә бәяләү моменты булмаган сүзләр *эмоциональ нейтраль сүзләр* дип атала. Андый берәмлекләр сүзлек составында күпчелекне тәшкил итә. Шул рәвешчә лексик берәмлекләрне төп өч

төркемгә аерырга мөмкин: *тискәре эмоцияле, нейтраль эмоцияле һәм уңай эмоцияле* сүзләр.

Сүзләрнең стилистик бизәкләре буенча югарыда карап үтелгән бүленеш прагматик мәгънәләр нисбәтендә сүзләр арасындагы барлык мөнәсәбәтләрне дә чагылдыра алмый билгеле. Бу аспектлар арасында тыгыз бәйләнеш яши. Мәсәлән, көнкүреш сөйләменә караган сүзләр шул ук вакытта фамильяр һәм табигый регистрга да керә; китапча сүзләр – формаль регистрга; поэтик сүзләр – тантаналы регистрга мөнәсәбәттә була. Тискәре эмоцияле сүзләр күбрәк фамильяр була, ә уңай эмоциялеләре – тантаналы регистрга һәм поэтик лексикага карый һ.б.

Икенче яктан, еш кына бер үк сүз төрле стилистик бизәкле була һәм төрле регистрга карый. Иркәләү-кечерәйтү кушымчасы булган сүзләр түбәнсетү төсмере алырга мөмкин: *өйчек, адәмчек, урманчык* һ.б. Поэтизмнар терминнар составында да очрый: *ат* – йорт хайваны, *җыр* – музыкаль жанр һ.б.

Тәрҗемә процессында прагматик мәгънәләрнең ролен караганчы, төрле телләрдәге берәмлекләрдә аларның аерылу очраклары, референциаль мәгънәләрнең аерылуы белән чагыштырганда, тагын да гадәтирәк булуын билгеләп үтү мөһим. Ике телнең лексик берәмлекләре референциаль мәгънәләре белән тулысынча туры килеп, прагматик мәгънәләре (стилистик характеристикалары, регистры яки эмоциональ бизәге) аерылу очраклары табигый санала.

Мондый аермалар синонимик рәтләр яки тулы бер төркем сүзләрне чагыштырганда аеруча ачык күренә: *враг – противник – неприятель – недруг.* Бу сүзләрдә (*недруг*тан кала) ике референциаль мәгънә: 1) кемгәдер яки нәрсәгәдер дошманнарча мөнәсәбәттә булган кеше; 2) каршы як гаскәре. *Недруг*та бер генә референциаль мәгънә бар; *противник* сүзенең тагын бер мәгънәсе – “кем белән дә булса спорт ярышында катнашучы”. Татарчага тәрҗемә иткәндә бу сүзләрнең барысы да диярлек *дошман* дип бирелә, спортка бәйле мәгънәдә генә *каршы як, көндәш* дияргә була.

Прагматик мәгънәләргә килгәндә, алар бу сүзләрдә төрлечә: *враг* – нейтраль, шунлыктан ул активрак кулланыла.

Противник – шулай ук нейтраль сүз, әмма ул махсус хәрби термин булып та йөри. *Неприятель* – күбрәк китапча язма сөйләмдә очрый, *недруг* – поэтик сөйләмдә күзәтелә. Татар телендә *дус – дус-иш, әшнә, ахирәт, иптәш, кемәй* синонимик рәте белән дә шул ук хәл.

Тәрҗемәдә сүзләрдәге метафорик мәгънәләрне бирү дә әлеге проблема белән бәйләнгән, чөнки сүзләрдәге метафорик мәгънәләр ике телдә туры килми. Мәсәлән, рус телендә *жук* (*коңгыз)* – намуссыз кеше, *паук* (*үрмәкүч)* – кан эчүче, эксплуататор, *свинья (дуңгыз)* – шапшак кеше мәгънәләрен белдерә икән. Ә татар телендә бу сүзләр мондый күчерелмә мәгънәләрдә кулланылмый диярлек. Тәрҗемәдә исә бу очраклар исәпкә алынырга тиеш (мәсәлән, *сорыкорт, кандала* дип бирергә мөмкин).

Сүзләрнең прагматик мәгънәсенә коннотация дә килеп кушыла. *Коннотация* – әлеге телдә сөйләшүчеләр аңында сүз тудырган өстәмә ассоциацияләр. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендә *черемуха* (*шомырт*) яз, табигать белән бәйләнә, ә инглизләрдә андый ассоциация юк. *Укъяфрак* (остролист), *омела* безнең өчен биологик терминнар гына, ә инглиз телендә аларның эквивалентлары Рождество символы, чөнки бу үсемлекләрнең ботаклары белән бүлмәләрне бизиләр (бездәге чыршы, нарат кебек).

Тәрҗемә ителә торган барлык материаллар да бер үк дәрәҗәдә прагматик факторны исәпкә алуны таләп итми. Прагматик моментларның нинди роль үтәвеннән чыгып, тәрҗемә материалларын дүрт төркемгә бүләргә мөмкин:

1) *фәнни әдәбият* – аларда чыганак тел һәм тәрҗемә теле вәкилләренә бер дәрәҗәдә йөз тотыла. Төрле телләрдә сөйләшүчеләрнең аны аңлау дәрәҗәсе бер үк, чөнки алар шул өлкәдә эшләүче белгечләргә багышлана;

2) *“эчке кулланучы”ны күздә тоткан җирле матбугат материаллары* һ.б. кайбер текстлар. Гәрчә аларның эчтәлеге һәрчак җиңел аңлашылмаса да, алар башка телләргә сирәк тәрҗемә ителәләр һәм тәрҗемәдә прагматик факторны исәпкә алу ихтыяҗы тумый;

3) *матур әдәбият* – беренче чиратта әлеге тел туган телләре исәпләнгән кешеләргә атала, әмма еш кына чит телләргә

тәрҗемә ителә, шуңа күрә тәрҗемәче өчен прагматик планда аерым кыенлыклар тудыра;

4) тышкы сәясәт пропагандасы һәм экспортка чыгарыласы товарларны *рекламалау материаллары* – аларны тәрҗемә иткәндә прагматик фактор хәлиткеч роль уйный.

Гомумән алганда, эквивалентсыз лексиканы (географик атамалар, реалия һ.б.) тәрҗемә иткәндә прагматик аспектны исәпкә алу аеруча мөһим. Мәсәлән, географик атамаларны тәрҗемә иткән вакытта *штат, провинция, елга, күл* кебек сүзләр өстәргә кирәк. *Вашингтон штаты, Байкал күле...* Югыйсә, чит тел укучысына ялгызлык атамасы өстәмә мәгълүмат бирмәскә мөмкин (*Ока* – елга, инглиз телендә сөйләшүчегә *Ока* сүзендә *елга* мәгълүматы юк, шуңа күрә *елга* сүзен өстәргә кирәк).

Кайбер очракларда прагматик факторны исәпкә алу теге яки бу сүзләрне төшереп калдыруда да чагылырга мөмкин (мәсәлән, чит тел укучысына берни аңлатмый торган сүзләрне төшереп калдыру мәгънәгә зыян салмаячак).

Алмаштырулар, генерализацияләү, конкретлаштыру кебек алымнар да прагматик мәгънәләрне бер телдән икенче телгә күчергәндә киң кулланыла.

Лингвистик мәгънәләрне тәрҗемә итү

Тел тамгаларының шул ук тел системасындагы башка тамгалар белән мөнәсәбәте җирлегендә **лингвистик мәгънәләр** барлыкка килә. Тел берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәтләр гаять күп яклы һәм күп төрле. Аларга сүзләрнең аваз охшашлыгы (рифма, аллитерация), сүзләрнең морфемик төзелешендәге охшашлыклар (сүзьясалыш оялары), сүзләрнең семантик охшашлыгы (бер үк синонимик рәткә яки лексик-семантик кырга карау) һәм аерымлыгы (антонимия), җөмлә эчендә бер-берсе белән ярашу (валентлык) һ.б. керә.

Лингвистик мәгънәләр тәрҗемәдә бик түбән дәрәҗәдә генә саклана, кагыйдә буларак алар бер телдән икенче телгә бөтенләй күчерелми, чөнки һәр телнең үз специфик системасы була. Шулай да кайбер очракларда лингвистик мәгънәләрне тәрҗемәдә саклау ихтыяҗы туа. Еш кына лингвистик мәгънәләрне күчерү референциаль мәгънәләрне "корбан" итү

хисабына да башкарылырга мөмкин. Бу ситуациянең киресе гадәти һәм табигыйрак, билгеле.

Тел берәмлекләре хәбәрләмә предметына әйләнгән очракта, ягъни чыганак текстында сүз белдергән теге яки бу чынбарлык предметлары, күренешләре турында фикер йөртелмичә, нәкъ менә тел чаралары турында гына сүз барганда чыганак тел берәмлекләренең лингвистик мәгънәсен тәрҗемәдә чагылдыру мәҗбүригә әйләнә.

Бу хәл, беренчедән, конкрет бер тел фәнни тасвирлау предметына әйләнгәндә күзәтелә: бу очракларда тәрҗемә, нигездә, мөмкин дә, кирәк тә түгел. Әмма тел берәмлекләре фәнни (мәсәлән, грамматик) әдәбиятта гына түгел, ә башка жанрларда, шул исәптән матур әдәбият текстларында да хәбәрләмә предметына әйләнә ала. Бу очракларда тел берәмлекләренең лингвистик мәгънәсен тәрҗемә итү практик һәм теоретик яктан кызыксыну уята.

- *Ты откуда пришла? – спросил я ее.*

- *С верху, из Нижнего, да не пришла, а приехала. По воде то не ходят* (М.Горький, Детство).

Рус телендә хәрәкәт фигыльләре нинди ысул белән башкарылуын ачыклауны таләп итә: *прийти* (җәяү) – *приехать* (коры җир яки су транспорты белән) – *прилететь* (һава юлы белән). Ә татар телендәге *килү* фигыле хәрәкәт ысулын атамый. Тәрҗемәдә сорауны башкача кую мөһим: *прийти – приехать* сүзләрендәге лингвистик каршы куелыш әһәмиятле булганга күрә, оригиналның мәгънәви яктан бозылуы котылгысыз булачак.

Рифмаларны күчерү шулай ук катлаулы мәсьәлә.

Төрле аваз чараларына нигезләнгән сурәтләү чаралары да лингвистик мәгънәләрне күчерү проблемасына карый. *Аллитерация* – янәшә торган сүзләрнең башындагы тартыкларның охшашлыгы. *Сүз уйнату* – мәгънәләре белән ерак булган сүзләрнең тышкы охшашлыгына нигезләнгән чара.

Формаль үзенчәлекләр тел берәмлекләренең референциаль мәгънәләрен буйсындырган һәм алардан өстен булган текстлардагы лингвистик мәгънәләрне тәрҗемә итү гаять мөһим. Боларга каламбур, акрошигырь, тизәйткечләр һ.б. керә.

Референциаль, прагматик, лингвистик мәгънәләрне тәрҗемә иткәндә төп мисал буларак күбесенчә лексик берәмлекләр – сүз һәм сүзтезмәләр карала. Әмма тел тамгаларын сүзлек составындагы берәмлекләр белән генә чикләү дөрес булмас иде. Тел системасының икенче ягы – грамматик төзелеше лексикон кебек үк мөһим. Грамматик төзелешнең төп берәмлекләре – аффикслар, сүз төрләндерү формалары, синтаксик төзелмәләр шулай ук тел тамгаларына керә һәм лексик берәмлекләр кебек үк референциаль, прагматик, лингвистик мәгънәләр белдерәләр.

Тел белемендә лексик һәм грамматик мәгънәләрне аерып билгеләү кабул ителгән. Бу вакытта әлеге ике тип мәгънә бер-берсеннән табигате һәм эчтәлеге белән дә туры килми дигән тәэсир туа. Нигездә, бу алай түгел, лексик һәм грамматик мәгънәләр бер-берсеннән бары тик белдерелү чарасы белән генә аерылып тора. Моннан тәрҗемә теориясе өчен әһәмиятле нәтиҗә ясарга мөмкин: бер телдәге лексик (ягъни сүзлек берәмлеге белән белдерелгән) мәгънә икенче телдә грамматик (ягъни сүздән тыш чаралар белән белдерелгән) мәгънә булырга мөмкин (һәм киресенчә). Шунлыктан ике телнең берсендә теге яки бу грамматик чараның юклыгы тәрҗемәдә чишеп булмаслык кыенлыклар тудырмый.

Шул ук вакытта телләрнең грамматик төзелешендәге аермаларның тәрҗемәче өчен объектив кыенлыклар китереп чыгаруын инкарь итәргә дә ярамый. Сүзлек составындагы кебек үк, ике телнең грамматик системаларында бик сирәк очракта гына тулы тәңгәллек күзәтелә. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендә сизелерлек грамматик охшашлыклар булса да, ул өлешчә генә. Хәтта охшаш категорияләр дә күләме, функцияләре туры килми.

Ике телнең грамматик системаларындагы аермалыкларны күпертергә дә кирәк түгел, чөнки бер телдә грамматик ысул белән белдерелгән мәгълүматны икенче телдә лексик чара белән аңлатып була. Шунлыктан чыганак телдә грамматик чара белән белдерелгәнне тәрҗемә телендә дә грамматик чара белән бирү мәҗбүри итеп куела алмый.

1.6. ТӘРҖЕМӘ ТРАНСФОРМАЦИЯЛӘРЕ

Оригинал берәмлекләреннән шул ук мәгънәдәге тәрҗемә берәмлекләренә күчешне тәэмин итә торган үзгәртүләр **тәрҗемә (телара) трансформацияләре** дип атала. Эчтәлек һәм тәгъбир итү планы булган тел берәмлекләре трансформацияләнгәнгә күрә, әлеге үзгәртүләр формаль-семантик характерга ия, ягъни алар чыганак тел берәмлегенең формасын гына түгел, ә мәгънәләрен дә берникадәр үзгәртүне күздә тоталар.

Чыганак берәмлекләр буларак каралган оригинал элементларының характерына бәйле рәвештә, тәрҗемә трансформацияләре *лексик* һәм *грамматик* дигән төрләргә бүленә. Болардан тыш *лексик-грамматик* трансформацияләр дә була. Ул вакытта лексик берәмлекләрдән грамматик берәмлекләргә (я киресенчә) күчүдән гыйбарәт булган үзгәртүләр комплексы барлыкка килә.

*Лексик трансформация*ләрнең төп типлары:

- тәрҗемә транскрипциясе һәм транслитерация;
- калькалаштыру һәм лексик-семантик алмаштырулар (конкретлаштыру, генерализацияләү, модуляцияләү).

Грамматик трансформация типлары:

- синтаксик тәңгәлләштерү (сүзгә-сүз тәрҗемә);
- җөмләне таркату;
- җөмләләрне берләштерү;
- грамматик (сүз формаларын, сүз төркемнәрен, җөмлә кисәкләрен) алмаштырулар.

*Лексик-грамматик трансформация*ләрнең төп типлары:

- антонимик тәрҗемә;
- экспликация (тасвирлама тәрҗемә);
- компенсация.

Лексик трансформацияләр

Транскрипция һәм *транслитерация* – оригиналның лексик берәмлекләре формасын тәрҗемә теле хәрефләре аша күчерү юлы белән тәрҗемә итү ысулы. *Транскрипция* вакытында чит тел сүзләренең аваз формасы, *транслитерация*дә график

формасы (хәреф составы) бирелә. Хәзерге заман тәрҗемә практикасында транслитерациянең кайбер элементларын саклап, транскрипция юлы белән тәрҗемә итү өстелек ала. Телләрнең фонетик һәм грамматик системалары бер-берсеннән шактый аерылганга күрә, чыганак тел сүзләренең формасын тәрҗемә телендә чагылдыру һәрвакыт күпмедер дәрәҗәдә шартлы һәм якынча: *Станбул – Истанбул, Москва – Мәскәү, газета – гәҗит* һ.б. Һәр аерым пар өчен чыганак сүзнең аваз составын бирү кагыйдәләре эшләнә, искәрмәләр күрсәтелә.

Лексик-семантик алмаштырулар – тәрҗемәдә оригинал берәмлекләренең мәгънәсе белән туры килмәгән, әмма билгеле бер типологик үзгәртүләр ярдәмендә мәгънәләрен аңлатып була торган тәрҗемә берәмлекләрен куллану. Бу алмаштыруларның төп типлары – чыганак тел берәмлегенең мәгънәсен конкретлаштыру, генерализацияләү, модуляцияләү.

Конкретлаштыру – оригиналдагы киң мәгънәле сүз яки сүзтезмәне тәрҗемә телендәге таррак мәгънәле сүз яки сүзтезмә белән алмаштыру. Бу төр трансформацияне куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыганак тел һәм тәрҗемә теле берәмлекләре түбәндәге логик мөнәсәбәтләрдә була: чыганак тел берәмлеге төр (род) төшенчәсен, ә тәрҗемә теле берәмлеге төркем (вид) төшенчәсен аңлата. Мондый алмаштыруларның сәбәбе тәрҗемә телендә андый киң мәгънәле сүзнең булмавы белән дә аңлатылырга мөмкин. Шулай ук тәрҗемә телендәге киң мәгънәле сүзнең чыганак телдәге кебек актив булмавы да ихтимал.

Генерализацияләү – оригиналдагы тар мәгънәле сүзне тәрҗемә телендәге киң мәгънәле сүз белән алмаштыру, ягъни конкретлаштыруның киресе. Бу ысул стилистик сәбәпләр белән дә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендә кешенең буен һәм авырлыгын төгәл күрсәтү кабул ителмәгән, ә инглиз телендә бу табигый күренеш.

Модуляцияләү (мәгънәви үстерелеш) – оригиналдагы сүз яки сүзтезмәне мәгънәсе логик аңлашылган тәрҗемә теле берәмлеге белән алмаштыру. Мәсәлән, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре белән бәйле мөнәсәбәтләрне биргәндә: *Я их не виню потому, что я их понимаю* (инг. сүзгә-сүз) – *Я их понимаю*

(русчага тәрҗемәсе). *Он умер, стало быть, он сейчас мертв* (инг. сүзгә-сүз). – *Он умер* (русчага тәрҗемәсе).

Грамматик трансформацияләр

Синтаксик тәңгәлләштерү (сүзгә-сүз тәрҗемә) – чыганак телнең синтаксик әйләнмәсе тәрҗемә телендәге аналогик структурага үзгәртелү. Мондый “нуль” трансформация ике телдә параллель синтаксик әйләнмәләр булганда кулланыла. Бу очракта ике телдә тел берәмлекләренең саны һәм аларның урнашу тәртибе тулысынча туры килә. Кагыйдә буларак, синтаксик тәңгәлләштерү вакытында кайбер структур компонентлар үзгәрергә мөмкин: артикль, бәйлекләр, ярдәмлек сүзләр төшеп кала, кайбер берәмлекләрнең морфологик формалары үзгәрә, бер үк сүз кабатлана, тәрҗемә телендә уңышлырак сүз кулланыла, берәр сүз өстәлә һ.б. Бу үзгәртүләр җөмләнең төп төзелешенә кагылмый, җөмләдә шул ук җөмлә кисәкләре җыелмасы һәм аларның урнашу тәртибе саклана. Инглиз-рус тәрҗемәләрендә бу ысул еш очрый. Тәрҗемәдә җөмләнең төзелешен үзгәртү сүзгә-сүз тәрҗемә итеп тәңгәллек урнаштырып булмаганда гына кулланыла.

Җөмләне таркату – оригиналдагы синтаксик структураны тәрҗемә теленең ике яки аннан да күбрәк хәбәрлекле структурасына үзгәртү. Бу ысулны куллану нәтиҗәсендә чыганакның гади яки кушма җөмләсе тәрҗемә телендә берничә мөстәкыйль җөмлә белән бирелә.

Җөмләләрне берләштерү – чыганак телдәге берничә гади җөмләне тәрҗемә телендә бер кушма җөмләгә әйләндерү, ягъни алдагы ысулның киресе.

Грамматик алмаштырулар – оригиналның грамматик берәмлеген тәрҗемә теледәге башка грамматик мәгънәгә ия булган берәмлеккә әйләндерү. Бу алмаштырулар сүз формалары, сүз төркемнәре, җөмлә кисәкләре, билгеле бер тип җөмләләр дәрәҗәсендә күзәтелә ала. Тәрҗемә вакытында чыганак тел формасы тәрҗемә теле формасы белән алмаштырылырга тиешлеге аңлашыла. Әмма тәрҗемә ысулы буларак грамматик алмаштыру чыганак телдәге грамматик формага аналогик формадан баш тарту, тәрҗемә телендә аларны грамматик

мәгънәләре башка булган формалар белән алмаштыруны күздә тота. Мәсәлән, инглиз һәм рус телләрендә берлек һәм күплек сан формалары бар, тәрҗемәдә алар шул ук сан формасында бирелергә тиеш (я берлек, я күплек саны гына булган сүзләр искәрмә тәшкил итә). Аерым очракларда сан формасын үзгәртү окказиональ тәңгәллек урнаштыру чарасы буларак кулланылырга мөмкин.

Тәрҗемә вакытында сүз төркемнәрен алмаштыру – грамматик алмаштыруларның киң таралган төрләреннән берсе: исем ↔ фигыль, сыйфат ↔ исем һ.б.

Җөмлә кисәкләрен алмаштыру оригиналның синтаксик төзелешен үзгәртүгә китерә. Сүз төркемнәрен үзгәртү дә шундый ук нәтиҗәләр бирергә мөмкин. Баш кисәкләрне алмаштырганда җөмлә төзелешләрендә аермалыклар аеруча сизелерлек була.

Җөмлә тибын алмаштыру да синтаксик үзгәрешләргә китерә (җөмләләрне таркату һәм берләштерүдәге кебек). Кушма җөмлә ↔ гади җөмлә; баш җөмлә ↔ иярчен җөмлә; тезмә кушма җөмлә ↔ иярченле кушма җөмлә; теркәгечле кушма җөмлә ↔ теркәгечсез кушма җөмлә һ.б.

Лексик-грамматик трансформацияләр

Антонимик тәрҗемә – оригиналдагы раслау формасы тәрҗемәдә инкарь формасы белән һәм киресенчә бирелү. Бу трансформация оригиналның лексик берәмлеген тәрҗемә телендә капма-каршы мәгънәдәге лексик берәмлеккә алмаштыру белән бара.

Экспликация (тасвирлама тәрҗемә) – чыганак телнең лексик берәмлеген тәрҗемә телендә мәгънәсен теге яки бу дәрәҗәдә тулы аңлата торган яки аңа билгеләмә биргән сүзтезмә белән алмаштыру. Бу юл белән тәрҗемә телендә эквиваленты булмаган чыганак тел сүзләрен бирергә мөмкин. Экспликация ысулының кимчелеге – күп сүзлелек һәм күләмлелек. Шунлыктан ул чагыштырмача кыска аңлатма биреп булганда гына уңышлы.

Компенсация – чыганак тел берәмлеген тәрҗемә иткәндә югалган мәгънә элементларының тәрҗемә текстында башка чара

белән бирелүе. Әмма ул чараның нәкъ оригинал текстындагы урында кулланылуы мәҗбүри түгел. Шул рәвешчә, югалган мәгънә торгызыла (компенсацияләнә) һәм оригинал мәгънәсе тулы күчерелә. Бу вакытта еш кына грамматик чаралар лексик чаралар белән һәм киресенчә алмаштырыла.

1.7. ТӘРҖЕМӘ ПРОЦЕССЫНЫҢ МОДЕЛЕН ТӨЗҮ

Тәрҗемә турында сөйләгәндә, гадәттә, я тәрҗемә текстын оештыру процессын (тәрҗемәче эшчәнлеге), яисә бу процессның нәтиҗәсен (тәрҗемә текстын) күздә тоталар. Тәрҗемә теориясе фәне барлыкка килгән чорда күп кенә галимнәр бу фән тәрҗемә процессын да өйрәнергә тиеш дигән фикергә киләләр. Алга таба тәрҗемә телара коммуникациянең киң чикләрендә карала башлагач, тәрҗемәчелек өлкәсенә тәрҗемә процессы да, аның нәтиҗәсе дә, аралашуда катнашучылар да һәм тәрҗемә процессы барышына, аның нәтиҗәсенә тәэсир итә торган барлык факторлар да кертелә. Шул вакыттан алып тәрҗемә механизмын ачу, тәрҗемәченең эш-гамәлләрен, стратегиясен һәм тактикасын тасвирлау теоретик яктан да, гамәли яктан да зур кызыксыну уята.

Тәрҗемәнең тәрҗемәче аңында бара торган фикерләү операцияләре нәтиҗәсе булуы тәрҗемә процессын өйрәнүне кыенлаштыра, чөнки аларны турыдан-туры күзәтү мөмкин түгел. Тикшеренүчеләр шуңа да еш кына тәрҗемәгә кагылышлы өлкәләргә үтеп керү өчен күп кенә чаралар кулланып карыйлар.

Тәрҗемә процессында бер-бер артлы килә торган этапларны аерып чыгарырга мөмкин. Тәрҗемәдә *ике этап*ның булуы шик тудырмый: 1) аңлау этабы һәм 2) тәрҗемә, ягъни икенче телдә текст барлыкка китерү этабы. Кайбер галимнәр өченче этапны – редакцияләү, тәрҗемәне камилләштерү, шомарту этабын аерырга тәкъдим итәләр.

Тәрҗемә процессындагы беренче һәм икенче этаплар психологлар һәм тел белгечләре тарафыннан күптәннән өйрәнелә, тәрҗемә теориясе әлеге фәннәр биргән мәгълүматны файдалана ала. Ни дисәң дә, бу процесс тәрҗемәчеләрдә дә "гадәти" кешеләрдәге кебек булырга мөмкин бит. Чыннан да күп кенә тәрҗемә концепцияләре кешеләрнең текстларны аңлау һәм

барлыкка китерүләре турындагы белемнәргә таяна. Ничек кенә сәер яңгырамасын, оригиналны үз туган телләрендә укучы гадәти кешеләр белән чагыштырганда, тәрҗемәче тәрҗемә ителәсе текстны тирәнрәк аңларга мәҗбүр. Аңлауның бу өстәмә “тирәнлеге”, беренчедән, текст эчтәлеге турында нәтиҗәләр чыгару һәм, икенчедән, тәрҗемә теле таләпләрен исәпкә алу зарурлыгы белән бәйләнгән.

Тәрҗемә процессын аңлау-аңлату өчен *интроспекция методы*н (тәрҗемәчеләрнең үзләреннән нәрсә һәм ничек эшләүләрен сорау) кулланырга тырышу табигый тоела. Әмма тәрҗемә процессы ничек бара дигән сорауга тәрҗемәчеләр биргән җаваплар тулы һәм объектив картина тудырырга ярдәм итми. Тәрҗемәче күп очракта интуициягә таяна һәм еш кына ни өчен шулай эшләвен аңлата да, логик нигезли дә алмый.

Тәрҗемә процессы турындагы теге яки бу дәрәҗәдә объектив мәгълүматны *“кычкырып уйлау” методы* бирергә мөмкин. Бу вакытта тәрҗемәчегә язмача текст бирелә һәм тәрҗемә вакытында башына килгән барлык уйларын кычкырып әйтергә кушыла. Мәсәлән, ул болай сөйләргә мөмкин: “*Җөмләне укыйм. Аның нәрсә аңлатуын төшенә алмыйм, чөнки беренче сүзне аңламыйм. Бу сүзне сүзлектән эзләп табам. Анда аның дүрт мәгънәсе бирелгән. Шуларның икенчесен сайлап алам, чөнки ул контекстка күбрәк туры килә...*” һ.б. Тәрҗемәче әйткәннәр магнитофонга яздырыла, шуннан кәгазьгә күчерелә һәм тәрҗемә белән чагыштырыла. Магнитофон шулай ук хисләрнең төрлечә белдерелүен дә яздырып бара: кайсыдыр урында тәрҗемәче авыр сулап куйган, кайдадыр сөенеп көлгән, бер урында озак кына дәшми утырган һ.б. Эшкәртелгән анализ тәрҗемә процессының өч мөһим аспекты турында мәгълүмат алырга ярдәм итә: 1) оригиналны аңлаган һәм тәрҗемәдә вариантлар сайлаган вакытта төрле тип тәрҗемә кыенлыклары булу күренә; 2) тәрҗемәченең гомуми стратегиясе билгеләнә: эш-гамәлләренең эзлеклелеге, сүзлек белән эшләү методлары, сүзгә-сүз тәрҗемә куллану һ.б.; 3) тәрҗемәдә соңгы вариантны сайлаганда тәрҗемәче файдаланган кайбер принциплар ачыклана. Болар барысы да зур кызыксыну уята, мондый метод тәрҗемә процессын өйрәнгәндә кыйммәтле материал бирә. Тик бу методның кайбер кимчелекләре дә бар. Бер яктан, ул реаль

процессны тулысынча чагылдырмый, чөнки анда кайбер өлешләр интуиция буенча гына башкарылырга, тәрҗемәче аны үзе аңышмаска һәм кычкырып әйтмәскә мөмкин. Икенче яктан, барлыкка килгән картина ниндидер ясалма тәрҗемә (башта телдән эшләнгән кебек тәэсир калдыра торган язмача тәрҗемә) тибын тасвирлый. Моннан тыш һәр тәрҗемәче үзенең ни уйлавын тулы һәм дөрес итеп сөйләмәве дә ихтимал.

Тәрҗемә процессын өйрәнү методлары арасында иң яхшы эшкәртелгәне – *тәрҗемәнең теоретик модельләр*ен төзү һәм оригинал текстының бер өлешеннән тәрҗемә текстының шундый ук өлешенә күчәргә ярдәм итә торган төрле үзгәртү типларын тасвирлау.

Тәрҗемә моделе – тәрҗемә процессын тормышка ашыру процедураларының шартлы тасвирламасы. Ул тел белеме һәм психологиянең гомуми постулатларын тәрҗемәдә кулланырга омтылуга нигезләнә. Модель гипотетик характерда була, чөнки тәрҗемәченең баш миендә бара торган тәрҗемә процессын турыдан-туры күзәтү мөмкин түгел һәм тәрҗемә теге яки бу модель кушканча эшли дигән ышаныч та юк. Әмма болар тәрҗемә модельләренең чиста уйдырма булуын да аңлатмый. Әгәр тәрҗемә нәтиҗәсе билгеле бер модель таләпләренә туры килсә, ул бу модельнең "эшләвен" күрсәтә, гәрчә бу да тәрҗемәченең аңлы рәвештә шул модельне куллануын исбатламый.

Хәзерге вакытта тәрҗемә теориясендә шундый берничә модель эшләнгән. Алар арасында *ситуатив, трансформацион* һәм *семантик модель*ләр киң таралыш алган.

Ситуатив модельнең асылы: теләсә кайсы ситуация теләсә кайсы тел чаралары белән сурәтләп бирелә ала. Хәтта телдә чынбарлыкның кайсыдыр күренешләрен, предмет-төшенчәләрен атый торган сүзләр булмаса да, телдә яңа берәмлек ясау яки аларны телдә моңарчы булмаган элементлар ярдәмендә тасвирлау мөмкинлеге һәрчак була. Бу нигезләмәләр буенча фикер йөрткәндә, тәрҗемә процессы түбәндәгечә бара: оригиналның эчтәлеген аңлаганнан соң, тәрҗемәче анда нинди ситуация тасвирланганын ачыклый, шуннан соң бу ситуацияне тәрҗемә теле чаралары белән сурәтләп бирә. Башкача әйткәндә, тәрҗемә процессы ике этаптан тора: оригинал текстыннан

чынбарлыкка һәм чынбарлыктан тәрҗемә текстына күчү. Аерым очракларда бу модель яхшы эшли. Мәсәлән, эквивалентсыз лексика тәрҗемәсендә; ситуатив эквивалентлык очракларын да бу модель ярдәмендә аңлатып була (аерым ситуацияләр тәрҗемә телендә катгый бер ысул белән генә бирелә: *По газонам не ходить! – Газонны таптамаска!* һ.б.). Шул рәвешчә, ситуатив модель тәрҗемәнең реаль чынбарлык белән бәйле үзенчәлекләрен аңлатырга ярдәм итә. Шул ук вакытта ул тәрҗемә процессының аерым ысулларын гына күздә тота. Беренче тип эквивалентлыкта коммуникация максатына шул ук ситуацияне тәрҗемәдә тасвирлаудан баш тарту аркылы ирешелә. Әгәр оригиналдагы ситуацияне рецептор тиешенчә кабул итмәсә, әлеге ситуацияне тәрҗемә теле чаралары белән тасвирлап бирү телара коммуникациягә ярдәм итми. Ситуатив модель тәрҗемәдә ситуацияне дә, аны сурәтләү ысулларын да һәм тел чараларының төп мәгънәләре сакланган очракларны да аңлатып бирә алмый. Әмма болар ситуатив модельнең ялгыш булуын күрсәтми, бу модельнең аңлату көче чикләнгәнлеген генә белдерә.

Тәрҗемәдә синтаксик структураларның ничек сайлануын **трансформацион модель** ачыкларга ярдәм итә. Бу модель телдә үзара бәйле булган синтаксик төзелмәләр булуга нигезләнә. Мондый трансформацион рәтләрдә төп (ядерный) төзелмәләр аерылып чыгарыла, нәкъ менә шуларда элементлар арасындагы мөнәсәбәтләр ачыграк күренеп тора. Бу рәтләргә ясалма структуралар да (трансформалар) керә, алар исә төп структуралардан билгеле бер трансформация кагыйдәләре буенча ясала. Мәсәлән, *Мальчик читает книгу* төзелмәсенә карата *Чтение книги мальчиком. Читающий книгу мальчик. Книга читается мальчиком* трансформалары ясалма булалар.

Бер үк трансформа (ясалма структура) төрле төп структуралардан килеп чыкса, төрле мәгънәгә ия булырга мөмкин. Мәсәлән, "*Приглашение ректора*" тезмәсе ректорның кемнедер чакыруын да, ректорны кемдер чакыруны да белдерергә мөмкин. Трансформацион модель тәрҗемәне ике телдә дә эзлекле үзгәртүләр рәте буларак карарга тәкъдим итә, чөнки төрле телләрдәге төп структуралар, ясалмаларына караганда, күбрәк туры килә.

Бу модель буенча фикер йөртсәк, тәрҗемә өч этаптан гыйбарәт: беренче этапта оригиналның ясалма структурасы чыганак телдәге төп структурага якынайтыла. Икенче этапта оригиналның төп структурасыннан тәрҗемә теленең шундый ук (аналогик) структурасына күчеш күзәтелә. Өченче этапта тәрҗемә телендә табылган төп структура, тәрҗемә теле нормаларына туры китерелеп, ясалма структурага әйләндерелә.

Оригинал һәм тәрҗемә телләрендәге синтаксик төзелмәләр арасында тәңгәллекләр урнаштыра торган трансформацион модель дә тәрҗемә процессын төрле яклап аңлатып бирә алмый. Аны билгеле бер дәрәҗәдә **семантик модель** тулыландыра. Бу модельнең нигезендә лингвистикадагы компонентлы анализны тәрҗемәгә күчерү омтылышы ята. Компонентлы анализ вакытында тел берәмлекләре тагы да ваграк элементар мәгънәләргә – *сема*ларга таркатыла һәм тел берәмлекләренең мәгънәләре семалар җыелмасы буларак карала. Гадәттә, төрле телләрдә семалар җыелмасы (тел берәмлекләренең мәгънәсе) туры килмәсә дә, аларны тәшкил иткән семалар арасында уртаклык шактый була. Бу күзлектән караганда, тәрҗемә процессы ике этаптан тора. Беренче этапта тәрҗемәче оригинал өлешендәге семалар составын ачыклый, аларның кайсысы коммуникация өчен әһәмиятле булуын һәм тәрҗемәдә бирелергә тиешлеген хәл итә. Икенче этапта тәрҗемә телендә мәгънәсенә оригиналның күбрәк семалары, беренче чиратта, иң әһәмиятлеләре кергән берәмлекләр сайлана. Тәрҗемәнең оригиналга якынлыгы семалар саны белән билгеләнә. Бу вакытта кайбер семалар оригиналның контекстында ачыкланырга һәм тәрҗемәдә экспликация юлы (тәрҗемә телендә чыганак телнең лексик берәмлеге мәгънәсен теге яки бу дәрәҗәдә тулы аңлата торган яки аңа билгеләмә биргән сүзтезмә белән алмаштыру) белән бирелергә яисә тәрҗемә теле нормалары таләбе белән өстәлергә мөмкин. Мәсәлән, *Студент едет* җөмләсен тәрҗемә итәргә кирәк булсын. Компонентлы анализ ярдәмендә 4 сема ачыклана: 1) эшне башкаручы, 2) мужской род, 3) хәрәкәт, 4) хәзерге заман. Татар теле өчен 1, 3, 4 семалар әһәмиятле һәм шуңа да алар тәрҗемәдә сакланырга тиеш. Әмма татар теленә тәрҗемәдә студентның ни рәвешле (нәрсә белән) баруы турында өстәмә

мәгълүмат кирәк, ә ул бу фразада юк, шунлыктан аны текстның башка өлешеннән яки сурәтләнгән ситуациядән эзләп табарга туры килә. Саналган барлык факторларны исәпкә алганнан соң тәрҗемәче *Студент трамвайда утырып бара* дип тәрҗемә итә. Татар җөмләсенә компонентлы анализ ясау нәтиҗәсендә 5 сема табыла: 1) эшне башкаручы, 2) бару рәвеше, 3) транспорт төре, 4) хәрәкәт, 5) хәзерге заман. Шул рәвешчә тәрҗемәдәге эквивалентлык оригиналда чагылыш тапкан өч әһәмиятле һәм оригиналның гомуми мәгънәсеннән килеп чыккан ике өстәмә семаның уртаклыгына нигезләнә. Бер-берсен алыштырган семалар туры килмәскә, өченче тип эквивалентлыкка хас семантик үзгәртеп корулар аша бәйләнгән булырга мөмкин. Семантик модельнең дә тәрҗемә процессын универсаль рәвештә аңлата алмавы күренеп тора. Чөнки кайбер очракларда ситуацияне үзгәртеп коммуникация максатын саклау дәрәҗәсендә дә яки тасвирлау чарасы алыштырылып, ситуациягә ишарәләү юлы белән дә тәрҗемә эквивалентлыгына ирешергә мөмкин. Бу очракларда оригинал һәм тәрҗемәдә семалар охшашлыгы турында сүз дә булу мөмкин түгел, шуңа күрә тәрҗемә семантик модуль буенча башкарыла алмый.

Тәрҗемә процессының моделен төзегәндә психолингвистиканың сөйләм эшчәнлеге төзелеше турындагы нигезләмәләренә таянырга була. Кеше эшчәнлегенең теләсә кайсы төрендәге кебек үк, сөйләм эшчәнлегендә дә берничә этапны аерып карарга була. Башта кешене нинди дә булса эшгамәлгә этәрә торган мотив туа; аннары сөйләм әсәре ярдәмендә мотивны тормышка ашыру өчен омтылган максат барлыкка килә; шуннан соң хәбәрләмәнең эчке программасы (эчке сөйләмдәге төзелеше) формалаша һәм, ниһаять, ул телдән яки язма сөйләм аша белдерелә. Сөйләм барлыкка килүнең психолингвистик тикшеренүләр ачыклаган эчке программасы гадәти (табигый) тел нигезендә түгел, бәлки кешенең индивидуаль предметлы-образлы коды ярдәмендә формалашуы турындагы мәгълүматлар тәрҗемә теориясе өчен аеруча әһәмиятле. Хәбәрләмәнең эчке программасы фикернең асылын җыйнак формада чагылдыра һәм кеше үзе белгән теләсә кайсы тел чаралары ярдәмендә аны җәенкеләндерә ала. Тәрҗемә текстын төзегәндә дә тәрҗемәче сөйләм эшчәнлеге башкара,

шунлыктан тәрҗемә процессы да шул ук этапларны үтә, тик аларда берникадар аерма күзәтелә: тәрҗемәче әйтелмәнең эчке программасын үзе төземи, ул оригиналның җыйнакландырылган эчтәлегеннән гыйбарәт була. Шул рәвешчә тәрҗемә процессын болай күз алдына китерергә мөмкин: беренче этапта тәрҗемәче оригиналның үзе аңлаган эчтәлеген эчке программа рәвешендә "баш мие теленә" күчерә, икенче этапта тәрҗемә телендә әлеге программаны җәенкеләндерә.

Тәрҗемә нәтиҗәсе буларак сөйләм әсәре барлыкка килгәнлектән, сөйләм эшчәнлегенең **психолингвистик моделе** тәрҗемә процессын дөрес тасвирлый дияргә нигез бар. Тик монда берникадәр төгәллек кертергә генә кирәк. Эш шунда ки, хәбәрләмәнең асылы әзер тел берәмлекләреннән тормый һәм сөйләүче, тел чараларын мөстәкыйль рәвештә сайлый-сайлый, эчке программасын җәенкеләндерә. Ә тәрҗемәченең тел чараларын сайлау иреге чикләнгән, чөнки бу оригинал эчтәлеген мөмкин кадәр тулы, төгәл бирү таләбе белән бәйләнгән. Шуңа күрә тәрҗемәче әлеге чараларны дөрес сайларга мөмкинлек бирә торган өстәмә мәгълүматка да ия булырга тиеш.

Алда сурәтләнгән дедуктив модельләр тәрҗемә процессын бер-бер артлы килә торган операцияләр рәвешендә гомуми итеп күз алдына китерәләр. Тәрҗемәне башкача сурәтләү ысулы оригиналдан тәрҗемәгә күчәргә мөмкинлек бирердәй конкрет операцияләрне ачыклау омтылышыннан тора. Оригинал һәм тәрҗемә өзекләре арасындагы мөнәсәбәтләр төп нөсхәне билгеле бер кагыйдәләр буенча үзгәртүдән гыйбарәт дип фаразлана. Мондый үзгәртүләр (трансформацияләр) тәрҗемә ысуллары буларак карала ала, тәрҗемәче аерым кыенлыкларны хәл иткәндә нәкъ менә шулардан файдалана. Тәрҗемә трансформацияләре лексик, грамматик һәм лексик-грамматик характерда булуы турында алда әйтелгән иде инде.

1.8. ТӘРҖЕМӘЧЕНЕҢ ЭШ СТРАТЕГИЯСЕ

Стратегия – алдан уйланылган план белән эшләү осталыгы.

Тәрҗемә белеменең төп төшенчәләрен үзләштерүдән тыш, булачак тәрҗемәчеләр үз эшләренә дөрес якын килергә, тәрҗемәчеләргә хас үзенчәлекле фикер йөртү сәләтенә ия булырга тиеш. Болар тәрҗемәче эшчәнлегенең нигезендә ята һәм аның гомуми стратегиясен билгели.

Тәрҗемә стратегиясен булдыруның төп кыенлыгы шунда, аны ниндидер кагыйдәләрне өйрәнү яки тренировкалар ярдәмендә генә формалаштырып булмый.

Тәрҗемә стратегиясен эшкәртү, формалаштыру тәрҗемә процессын тормышка ашырудагы гомуми принципларны белү һәм куллануны күздә тота. Бу принциплар өч төркемнән тора:

1) элеккеге кайбер постулатлар (исбат ителмичә нигез итеп алынган фикерләр);

2) тәрҗемәче конкрет карарлар кабул иткәндә нигез итеп алырдай эш-гамәлләрнең гомуми юнәлешен сайлау;

3) тәрҗемә процессындагы эш-гамәлләрнең характерын һәм эзлеклелеген сайлау.

Тәрҗемә стратегиясенең элеккеге постулатлары тәрҗемәченең үз эшенә мөнәсәбәтен билгели. Тәрҗемәченең арадашчы ролендә булуын истә тотуы, иҗатының икенчел характерын исәпкә алуы мөһим. Моннан оригинал текстын хөрмәт итү килеп чыга. Тәрҗемәче оригинал авторын гына тәкъдим итә, шуңа күрә ул оригиналны мөмкин кадәр тулы чагылдырырга, аның тулы хокуклы алыштырмасын барлыкка китерергә тиеш. Телара коммуникациядә катнашучыларның өметләрен аклаганда гына тәрҗемәче эшчәнлегенең мәгънәсе булачак. Һөнәри телдә әйткәндә, тәрҗемәче тәрҗемә ителә торган текстны дөрес аңлау һәм аңа тәрҗемә телендә тәңгәллек сайлап алу өчен максимум көч куярга тиеш дигән сүз. Ул текстның теләсә кайсы өлешендә күзгә күренеп торган яки яшерен тәрҗемә проблемалары булуын истә тота һәм уйланылмаган, ашыгыч карарлар кабул итми. Шул ук вакытта тәрҗемәче бу проблемалар арасында типик, еш очрый торган

һәм аз таныш булган, стандарт чишелеш сорый торганнары да, уникаль, окказиональ, моңа кадәр таныш булган тәрҗемә алымнарын үзгәртүне, яңаларын эзләп табуны таләп иткәннәре дә булуын ачык аңлый.

Тәрҗемәченең стратегик принциплары арасында иң әһәмиятлесе – үз эшенә тәнкыйди мөнәсәбәт. Әгәр оригинал каршылыклы, аңлаешсыз һәм бөтенләй мәгънәсез тоелса, моның сәбәбе авторның хатасында түгел, ә тәрҗемәченең белеме җитмәү булырга мөмкин. Барлыкка китереләсе текстына тәрҗемәче сак карарга тиеш: әгәр сайлап алынган тәңгәллек текстка "ят тоелса", текстның калган өлешләре белән каршылыкка керсә, логик эзлеклелекне бозса – калганнарын аңа яраклаштырырга түгел, башка вариант эзләргә кирәк.

Конкрет мәсьәләләрне хәл иткәндә тәрҗемәченең стратегиясе иң беренче чиратта **тәрҗемәнең максаты**н дөрес билгеләүгә бәйле. Тәрҗемәче ни өчен һәм кем өчен тәрҗемә итүен, ул тудырган текст нинди бурыч үтиячәген һәм текстның кем тарафыннан, ничек файдаланылачагын ачык күз алдына китерергә тиеш. Моңа бәйле рәвештә тәрҗемәче тәрҗемә итәргәме, әллә телара арадашчылыкның башка төрен кулланыргамы икәнен хәл итә ала. Тәрҗемә итәргә икән – каралама вариант кирәкме, әллә инде басма өчен әзерләргәме (адекват итеп)? Шулардан чыгып ул чыганак хәбәрне икенче телгә күчерү юлларын да сайлаячак.

Конкрет *тәрҗемә актының максаты* да тәрҗемә стратегиясен билгели. Оригинал текстын күчерүдән тыш, тәрҗемә текстын оештыру нинди дә булса прагматик максатка – коммерция, пропаганда, сәяси һ.б. максатларга да ия булырга мөмкин. Бу максатка ирешү өчен тәрҗемәче тәрҗемә текстына кайбер сизелерлек үзгәрешләр дә кертә, хәтта тәрҗемәне рефератив бәян итү, парафраз яки эчтәлеген сөйләү белән алыштыра ала. Тәрҗемәче мондый прагматик адаптациянең сәбәпләрен һәм формаларын, алар рөхсәт ителгән очракларны белергә тиеш.

Тәрҗемәченең һөнәри эшчәнлеге тәрҗемә белән шөгыльләнүдән генә, ягъни чит телдәге оригиналга туры килә торган тулы хокуклы текст барлыкка китерүдән генә тормый. Тәрҗемәче телара коммуникацияне тәэмин итүче арадашчы

функциясен дә үти, ә мондый арадашчылык тәрҗемә белән генә түгел, башка ысуллар белән дә белдерелә ала. Икенче телдә чит тел текстының эчтәлеген сөйләргә, сайлап бирергә, гомумиләштерергә, аннотацияләргә һәм реферат итеп эшләргә мөмкин. Боларның барысы да тәрҗемә элементларын үз эченә ала, тәрҗемә телендә оригинал эчтәлегенә нигезләнгән яңа текст формалаштыруны күздә тота. Бу ысуллар оригиналны төрле дәрәҗәдә чагылдыра һәм ул барлыкка китерелә торган текстның характеры яки тәрҗемә алдына куелган максатлар белән билгеләнә.

Терминологик күзлектән караганда, алда санап үтелгән ысуллар да тәрҗемә төрләре буларак каралырга мөмкин: гадиләштерелгән тәрҗемә, рефератив тәрҗемә һ.б., әмма алар функцияләре һәм куелган таләпләр ягыннан тәрҗемәдән аерылып тора. Тәрҗемәдән аермалы буларак, алар *адаптацияләнгән транскодлаштыру* яки *адаптив күчерү* дип йөртеләләр. Бу очракта “адаптив” термины оригинал эчтәлеге билгеле бер дәрәҗәдә модификацияләнүне, үзгәртелү яки яңадан эшләнүгә дучар ителүне аңлата.

Тәрҗемәчегә эш практикасында еш кына гадиләштереп тәрҗемә итәргә, тәрҗемә-эчтәлек эшләргә һәм аннотация, реферат төзергә туры килә.

Гадиләштерелгән тәрҗемә тулы кыйммәтле тәрҗемә өчен вакыт җитмәгәндә яки заказ бирүче теләге белән башкарыла. Мондый тәрҗемә вакытында тәрҗемәче оригинал эчтәлеген теге яки бу дәрәҗәдә тулы бирү белән чикләнә, төгәл тәңгәллекләр табарга һәм вариантларны стилистик камилләштерүгә омтылмый. Кайвакыт гадиләштерелгән тәрҗемә каралама вариант буларак кулланыла һәм алга таба эшкәртелеп, бастырып чыгару өчен әзерләнергә мөмкин.

Тәрҗемә-эчтәлек сайланма яки гомумиләштерелгән була ала. Сайланма эчтәлек-тәрҗемә оригиналның аерым өлешләре эчтәлеген чагылдыра. Заказчыны кызыксындырган өземтә тексттан алынасы мәгълүматның характерын күрсәтеп бирелә. Гомумиләштерелгән эчтәлек-тәрҗемә оригинал текстының эчтәлеген бәян итә. Әгәр теге яки бу җөмләнең яисә абзацның мәгънәсен бирү куелган максатны үтәргә ярдәм итсә, боларның икесендә дә тәрҗемә элементлары кулланыла ала.

Аннотация текстның кыскача эчтәлегеннән гыйбарәт. Библиографик һәм реферативаннотацияләр була. Библиографик аннотациядә текстның чыганак мәгълүматлары, эчтәлеккә караган тематик рубрикалар күрсәтелә. Боларны күбрәк китапханә хезмәткәрләре төзи. Тәрҗемәче исә реферативаннотацияләр белән эш итә, аларда чит тел текстының эчтәлеге тезис формасында бирелә. Мондый аннотацияне тәрҗемәче я үзе төзи, яисә оригинал телендәге аннотацияне тәрҗемә итә.

Адаптацияләнгән транскодлаштырулар арасында иң катлаулысы һәм иң еш эшләнә торганы – чит тел текстларының *реферат*ларын төзү. Бу төр документларга аерым таләпләр куела.

Чын тәрҗемәдән аермалы буларак, реферат-тәрҗемәләр оригинал эчтәлеген үзгәртеп эшләүдән һәм максаты үзенчәлекле булудан гыйбарәт. Мондый максат рефератның күләме яки эзләп табасы мәгълүматның характерына карата, яисә икесен дә күздә тотып куелырга мөмкин. Теләсә кайсы очракта да бурыч – оригиналның төп эчтәлеген икенче телдә кыскартылган формада бирү.

Реферат бер яки берничә чыганак буенча төзелә ала. Рефератларның төзелеше стандарт: ул алты бүлектән гыйбарәт.

I бүлектә басмага җентекле характеристика бирелә, автор, текстның атамасы, нәшрият, басылу урыны, вакыты, күләме күрсәтелә.

II бүлектә документның гомуми темасы яки тематик рубрикалар тасвирлана.

III бүлектә текстның төп фикере формалаштырыла (бу өлеш һәрвакыт булмаска да мөмкин, тик ул чакта төп фикер ачыкланып, реферат дәвамында истә тотылырга тиеш).

IV бүлек – рефератның төп өлеше. Анда текстның кыскача һәм гомумиләштерелгән эчтәлеге бирелә.

V бүлек – авторның яки тәрҗемәченең текст эчтәлегеннән чыккан нәтиҗәләре. Бу өлеш тә һәрчак булмаска мөмкин.

VI бүлек шулай ук факультатив, чөнки ул тәрҗемәченең комментарийларыннан, текстның әһәмиятен, яңалыгын билгеләүдән, авторның нәтиҗәләре дәлилләнгән булуын

күрсәтүдән, бу темага караган әдәбиятның булу-булмавын бәяләүдән гыйбарәт.

Тәрҗемәче стратегиясен билгеләүдә икенче этап – тәрҗемә ителәсе **текстның тибы**н билгеләү. Бу тәрҗемә процессының доминантасын, ягъни тәрҗемәче омтылачак нәрсәне ачыклый. Монда берничә фактор истә тотыла.

Беренчедән, матур әдәбият текстлары белән башка төр (мәгълүмати, эшлекле, махсус) текстлар арасындагы аерма. Матур әдәбият текстларын тәрҗемә итү очрагында тәрҗемәченең стратегиясе тәрҗемә телендә тулы кыйммәтле әдәби текст тудыруга омтылу, оригиналның эмоциональ-эстетик тәэсирен күчерү белән билгеләнә. Ә мәгълүмати (информатив) текстлар тәрҗемәсендә чыганак хәбәрне төгәл җиткерү төп бурыч булачак.

Икенчедән, тәрҗемәнең оригинал характеры белән бәйле төп функциясе истә тотылырга тиеш. Монда оригинал һәм тәрҗемәнең формага (матур әдәбият тексты), эчтәлеккә (эшлекле, техник һ.б.) һәм тәэсир итүгә (пропаганда, реклама һ.б.) бәйле үзенчәлекләренә игътибар ителә. Шулай ук чыганак текстның теле һәм гомуми сыйфаты исәпкә алына: оригиналның теле әһәмиятлерәк һәм индивидуальрәк булган саен, аның тел үзенчәлекләрен бирүгә күбрәк игътибар ителергә тиеш; оригинал никадәр яхшырак язылса, ул шулкадәр төгәлрәк күчерелүгә лаек.

Өченчедән, “ачыктан-ачык” һәм “яшерен” тәрҗемәләр була. “Ачыктан-ачык” тәрҗемәләр оригиналны күрсәтеп нәшер ителә һәм чыганак текстның икенче телдәге репрезенты булып йөри; “яшерен” тәрҗемәләрнең чит телдәге оригиналлары күрсәтелми һәм алар тәрҗемә телендәге башка текстлар кебек үк билгеле бер функция башкарырга тиеш. Автор текстлары, чыганак телдә югары дәрәҗәгә ия текстлар “ачыктан-ачык” тәрҗемә ителәләр. Бу типларда тәрҗемәченең бурычы чыганак текстының эчтәлеген һәм структур үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тулы күчерүдән гыйбарәт. Башкача әйткәндә, тәрҗемәче оригиналга тугрылык сакларга тиеш. Юл күрсәткечләр (путеводитель), искәртү-кисәтү язмалары, техник кулланмалар, кулинария рецептлары һ.б.ш. “яшерен” тәрҗемә ителә, ягъни аларда оригиналга якынлык түгел, ә үз максатларын (туристка

чит илдә йөрергә ярдәм итү; техниканы дөрес эшләтү; хуҗабикәгә теләгән ризыгын хәзерләргә булышу һ.б.) уңышлы үтәү мөһимрәк. Бу очракта тәрҗемә текстында төгәл һәм аңлаешлы мәгълүматлар булырга, алар тәрҗемә телендә кабул ителгән формада бирелергә тиеш дигән таләп беренче планга чыга. “Ачыктан-ачык” тәрҗемәләрне *семантик* яки *документаль тәрҗемәләр* дип, икенчеләрен *коммуникатив тәрҗемәләр* дип тә йөртәләр.

Мондый анализ тәрҗемәнең төп доминанталарын – оригинал текстының төп элементларын сайлауга мөмкинлек бирә һәм тәрҗемәче шуларны төгәлрәк күчерергә омтылырга тиеш була. Терминнарның дөреслеге, сәнгатьлелек, образлылыкны күчерү, форманың кайбер элементларын саклау һ.б. төп доминанталарны тәшкил итә ала.

Кайбер очракларда тәрҗемәченең стратегиясе оригинал тексты тибының гомуми характеристикасын бирү юлы белән формалашырга мөмкин, ул исә тәрҗемә ысулын сайлау шартын билгеләргә ярдәм итә.

Оригинал текстының характерын билгеләгәндә тәрҗемәче аның вакыт һәм пространство ягыннан якынлыгына-ераклыгына да игътибар итә. Кагыйдә буларак, ераклык күпмедер дәрәҗәдә аның башка мәдәнияткә каравына да бәйле була, бу исә тәрҗемә процессында хәбәрнең җитди адаптациясен таләп итәргә мөмкин.

Оригинал теленең характеры да тәрҗемәченең стратегиясенә тәэсир итә ала: телнең нормативлыгы яки нормадан читкә тайпылган булуы тәрҗемәнең гомуми стилен билгеләячәк.

Тәрҗемәченең стратегиясе чыганак хәбәр предметы белән танышуны тәэмин итә торган эш-гамәлләрдән тора, алар дөрес тәрҗемә вариантын сайлаганда хәлиткеч роль уйнарга мөмкин. Боларга махсус дәреслекләр, белешмәләр, энциклопедияләр белән танышу, терминнар исемлеген төзү һәм аларның мәгънәләрен билгеләү керә. Тәрҗемә телендәге шундый яки якын темадагы текстлар белән танышуның да тәрҗемәчегә ярдәме зур.

Тәрҗемәченең үз эшенә мөнәсәбәте дә стратегияне билгели: тәрҗемәгә керешкәнче ул тулы текстны игътибар белән

укып чыга; текстның эчтәлеге белән танышканнан соң баш исемен тәрҗемә итә; таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен язып ала; каралама (сүзгә-сүз) тәрҗемә ясый яки шунда ук ахыргы вариантны эшләргә омтыла; тәрҗемә ителмәгән өзекне үзенә яисә берәр тыңлаучыга кычкырып укый һ.б. Мондый эшгамәлләрне сайлау тәрҗемәченең белеменә һәм тәҗрибәсенә бәйле, әмма аерым компонентлар гомуми характерга да ия.

Телара арадашчылыкның теләсә кайсы төрен башкарганда тәрҗемәче мәгълүматны кабул итүчеләрнең (рецептор) билгеле бер тибын күздә тота. Димәк, тәрҗемәченең стратегиясе **рецептор**ларның характерына, аларның гомуми һәм лингвистик белемнәренә, тәрҗемә текстында бирелгән предмет белән танышлык дәрәҗәсенә бәйле. Тәрҗемәчеләр иң элек кем өчен тәрҗемә итүләрен ачыклый белергә тиеш. Кайбер очракларда аларга конкрет кешеләргә яисә кешеләр төркеменә ориентлашырга дигән бирем йөкләнә. Мондый ситуацияләр тәрҗемәче коммуникациядә катнашучылар белән турыдан-туры аралашканда, ягъни телдән тәрҗемәдә туа. Башка очракларда тәрҗемәчегә рецепторларның билгеле бер һөнәргә караулары, яшьләре яисә бүтән категорияләре (техник белгечләр, яшүсмерләр, билгеле бер дин вәкилләре һ.б.) алдан күрсәтелергә мөмкин. Конкрет рецепторга йөз тоту тәрҗемә вариантларын сайлауга хәлиткеч тәэсир итә. Әмма еш кына тәрҗемәчегә "уртакул рецептор" үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк була. "Уртакул рецептор" дигәндә тәрҗемә теле мәдәниятенә караган халыкның типик бер вәкиле күздә тотыла. Бу, әлбәттә, шартлы термин: тел коллективындагы һәр кешенең белеме үзгә була һәм аларның һәркайсы тәрҗемә текстын үзенчә кабул итә. Шулай да практик максатлардан чыгып, "уртакул" рус кешесенә теге яки бу атамалар, фактлар яхшы таныш, ә "уртакул" татар кешесенә алар мәгълүм түгел (киресенчә дә була) һәм алар бу ике мәдәният кешеләре тарафыннан төрлечә кабул ителәләр, дип әйтергә мөмкин. Әлеге аерымлыкларны күздә тоткан хәлдә, тәрҗемәче прагматик адаптация ысулларын файдалана ала.

Сораулар һәм биремнәр

1. Тәрҗемә эшчәнлегенең барлыкка килү сәбәпләре.

2. Хәзерге фәндә “тәрҗемә” термины нинди мәгънәләрдә кулланыла?

3. Тәрҗемә кайсы очракларда башкарыла ала?

4. Тәрҗемәнең әһәмияте нәрсәдә?

5. Тәрҗемә берәмлекләре дип нинди тел берәмлекләренә әйтәләр? Шуларның кайсысы тәрҗемәнең төп берәмлеге була?

6. Тәрҗемә теориясе һәм тәрҗемә ничек аерыла?

7. Тәрҗемә теориясенең һәм тәрҗемәнең төрләре.

8. Тәрҗемә теориясе нинди фәннәр белән бәйләнештә тора?

9. Телдән һәм язма тәрҗемәләрнең охшаш һәм аермалы яклары.

10. Телдән тәрҗемә төрләре.

11. Тәрҗемәченең нинди хокуклары һәм бурычлары бар?

12. Тәрҗемәнең төп принципларын бәян итегез.

13. Дөрес тәрҗемә дип нинди тәрҗемәләргә әйтәләр?

14. Ялгыш тәрҗемә төшенчәсе кайсы очракларда кулланыла?

15. Уңай һәм тискәре мәгънәләрдә йөри торган тәрҗемәләр турында сөйләгез.

16. Тәрҗемә эквивалентлыгының ничә тибы бар? Бу типлар арасындагы төп аерма нәрсәдә чагыла?

17. Тел тамгаларының нинди мәгънәләре булырга мөмкин? Тәрҗемәдә аларның кайсы ни дәрәҗәдә саклана?

18. Референциаль мәгънәләр һәм аларны тәрҗемә итү юллары.

19. Прагматик мәгънәләр һәм аларны тәрҗемә итү мәсьәләсе.

20. Лингвистик мәгънәләрне тәрҗемә итү.

21. Тәрҗемә трансформацияләре һәм аларның төрләре.

22. Тәрҗемә процессының модельләре һәм аларның асылы.

23. Тәрҗемәченең эш стратегиясен нәрсәләр билгели?

24. Адаптив күчерү төрләре.

25. Матур әдәбият һәм мәгълүмати текстлар тәрҗемәсенең үзенчәлекләре.

Бүлек буенча өстәмә әдәбият

Бархударов Л.С. Язык и перевод. Вопросы общей и частной теории перевода. – М., 1975.

Виноградов В.С. Введение в переводоведение (общие и лексические вопросы). – М.: Издательство института общего среднего образования РАО, 2001.

Комиссаров В.Н. Современное переводоведение. – М.: ЭТС, 2002.

Комиссаров В.Н. Теория перевода (лингвистические аспекты). – М.: Высшая школа, 1990.

Латышев Л.К. Технология перевода. – М.: Издат.цент “Академия”, 2005.

Ревзин И.И., Розенцвейг В.Ю. Основы общего и машинного перевода. – М., 1969.

Сибәгатов Р.Г. Тәрҗемә методикасының нигезләре. – Уфа, 1979.

Федоров А.В. Основы общей теории перевода. – М.: ООО “Издательский дом “ФИЛОЛОГИЯ ТРИ”; СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2002.

Юсупов Р.А Тәрҗемә теориясенә кереш. – Казан, 1972.

Юсупов Р.А. Введение в теорию и практику перевода: Учебное пособие. – Казань: КГПИ, 1988.

Юсупов Р.А. Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.

Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода (на материале русского и татарского языков): Учебное пособие. – Казань: КГПУ, 2005.

II бүлек.

ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕНӘ ГОМУМЛИНГВИСТИК КЕРЕШ

2.1. ЛИНГВИСТИК ТИКШЕРЕНҮЛӘР ОБЪЕКТЫ БУЛАРАК ТӘРҖЕМӘ

Тәрҗемә – кеше эшчәнлегенең катлаулы һәм күпкырлы төре. Тәрҗемә турында “бер телдән икенче телгә күчерү” дип кенә әйтсәләр дә, ул бер телне икенчесе белән алмаштыру гына түгел. Тәрҗемә вакытында төрле мәдәниятләр, төрле шәхесләр, төрле фикер ияләре, төрле әдәбиятлар, төрле чорлар, төрле үсеш дәрәҗәләре, төрле гореф-гадәтләр очраша. Тәрҗемә белән культурологлар, этнографлар, психологлар, тарихчылар, әдәбиятчылар кызыксына. Тәрҗемә эшчәнлегенең төрле яклары билгеле бер фән кысаларында өйрәнү объекты булырга мөмкин. Шул ук вакытта тәрҗемә турындагы фәндә – тәрҗемә белемендә культурологик, когнитив, психологик, әдәби һ.б. аспектлар аерылып чыгарыла ала.

Әмма хәзерге вакытта тәрҗемәдә төп рольне телләр уйнавы турындагы традицион караш ныклы фәнни нигез алды һәм хәзерге тәрҗемә белемендә тәрҗемәнең лингвистик теорияләре алдынгы урынны тота. Шунысын да әйтергә кирәк, тәрҗемә тел белеме өлкәсенә күптән түгел генә кертеп карала башлады һәм монда кайбер кыенлыкларны да үтәргә туры килде. Гәрчә Р.Якобсон “киң таралыш алган телара коммуникация практикасы, аеруча тәрҗемә эшчәнлеге лингвистик фәннең даими күз уңында торырга тиеш” дип ассызыклаган булса да, әлегә кадәр лингвистикага караган фундаменталь хезмәтләрнең күбесендә тәрҗемәнең лингвистик тикшеренүләр объекты булу ихтималына ишарә дә юк иде.

XX гасырның беренче яртысында күпчелек тел белгечләренең тәрҗемә проблемаларына битарафлыгы лингвистикада структурализм идеяләренең өстенлек алуына китерә. Телне объектив тасвирларга, тел белемен “төгәл” фәннәргә якынайтырга омтылган тел белгечләре Ф. де Соссюрның телне “үз эчендә һәм үзе өчен” өйрәнү өндәмәсен хуплап кабул итәләр һәм “эчке лингвистика” яки

“микролингвистика” белән генә чикләнәләр. Фәнни төгәллек һәм объективлыкка ирешү юлында тел галимнәре төп игътибарны тел структурасындагы турыдан-туры күзәтеп, үлчәп, санап, тасвирлап һәм төркемләп була торган якларга (телнең авазларына, морфемалар һәм лексик составына, синтаксик төзелешенә, берәмлекләренең синтагматик һәм парадигматик бәйләнешләренә, үзара ярашуларына, текстта урнашуларына, куллану ешлыгына һ.б.) юнәлтәләр. Нәтиҗәдә тел белеме күп кенә телләрнең структур оешуын фәнни анализлауда зур уңышларга ирешә.

Әмма телне өйрәнүгә структур якын килү үзеннән-үзе телнең эчтәлек ягын тикшерүдән баш тартуга китерә. Шулай ук мәгънәләр турында фикерләр фәнни түгел, “менталистик” дип бәяләнә һәм тел турындагы фәндә семантикага урын табылмый. Шул сәбәпле анализга дучар булган иң зур тел берәмлеге җөмлә була, чөнки аңардан зуррак сөйләм берәмлекләрен (текстларны) семантик структураларына кагылмыйча гына объектив анализлау мөмкин түгел. Аңлашыла ки, мондый лингвистика тәрҗемә мәсьәләләре белән шөгыльләнә алмый, чөнки тәрҗемәнең асылы чит тел текстының эчтәлеген икенче тел чаралары белән әйтеп бирүдән гыйбарәт.

Үз чиратында тәрҗемәчеләр дә эшчәнлекләренең үзенчәлекләрен тикшерүдә тел фәненең роленә ышанмыйча, шикләнеп карыйлар. Киң таралыш алган караш буенча, тәрҗемә процессында тел факторлары (тәрҗемәченең ике телне белүе дә шул исәптә карала) музыка иҗат иткәндә нотага сала белү кебек икенчел дәрәҗәгә ия дип санала. Нигездә тәрҗемә – лингвистик операция түгел һәм тел белеме тәрҗемә теориясенә күп нәрсә бирә алмый дип уйланыла.

Тик тел белгечләре тәрҗемә проблемаларын исәпкә алмау гына түгел, бәлки “тәрҗемә итеп булмау” теориясе барлыкка килүгә дә өстәмә нигез тудыралар. Бу теориягә караганда, тәрҗемә гомумән була алмый. Әгәр шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр һәм филологлар тәрҗемәдә оригиналның сәнгать үзенчәлекләрен, милли спецификаны, әдәби, тарихи һәм мәдәни көнкүреш ассоциацияләрен һәм шуның кебек башка нечкәлекләрне күчереп булуга шикләрен белдерсәләр, телнең сүзлек составының һәм һәр телнең грамматик төзелешенең

уникальлеген белгән тел белгечләре исә оригинал һәм тәрҗемә текстларының тулысынча тәңгәллеге гомумән була алмый, димәк, тәрҗемә дә мөмкин түгел дип белдерәләр.

Тел белеме тәрҗемә белән "күзгә-күз" барыбер "очраша", тик бу хәл XX гасырның икенче яртысында гына була. Моңа тәрҗемәче эшчәнлегендәге һәм лингвистиканың үзендәге җитди үзгәрешләрне чагылдырган берничә объектив һәм субъектив фактор сәбәп була.

Икенче бөтедөнья сугышыннан соң булган "мәгълүмати шартлау" (кешеләр һәм халыклар арасында мәгълүмат алмашу кискен арту) тәрҗемәдә дә "шартлау" тудыра. Нәтиҗәдә, бөтен дөньяда тәрҗемәчелек масштаблары киңәя. Тәрҗемәнең яңа төрләре (синхрон тәрҗемә, кинофильмнар, радиотапшырулар, телепрограммалар һ.б. тәрҗемәсе) барлыкка килә. Тәрҗемәчеләргә ихтыяҗ арта. Аларны инде берәмләп түгел, ә күпләп әзерләүгә зарурлык туа. Моңарчы күрелмәгән тәрҗемәчелек масштабы һәм профессиональ тәрҗемәчеләрне күпләп әзерләү бурычы тәрҗемә феноменын төрле яклап өйрәнү ихтыяҗын барлыкка китерә.

Лингвистларның игътибарын тәрҗемә проблемаларына юнәлтүгә тәрҗемә эшчәнлегенең сыйфаты үзгәрү дә зур йогынты ясый. Дөньяда элеккечә матур әдәбият әсәрләре күпләп тәрҗемә ителсә дә, күләме һәм әһәмияте ягыннан беренче урынга мәгълүмати (фәнни-техник, иҗтимагый-сәяси, икътисади, юридик һ.б.) тәрҗемәләр чыга. Әгәр матур әдәбият тәрҗемәсендә тәрҗемәченең төп проблемалары оригиналның сәнгати-эстетик үзенчәлекләрен күчерү зарурлыгы белән бәйле булса, мәгълүмати текстлардагы кыенлыклар лингвистик характерга ия. Бу текстлар күпчелек очракта аноним, стандарт, гомумсөйләм телендә язылган, аларда авторның индивидуаль үзенчәлекләре чагылыш тапмый. Мондагы тәрҗемә проблемалары, нигездә, ике тел берәмлекләренең мәгънәләрендәге аермалар, аларның кулланылышы, сөйләм хәбәрләмәләрен һәм текстларын төзү ысулларына бәйле.

Тәрҗемәчелектәге үзгәрешләр лингвистларның игътибарын җәлеп итсә, тел белеме үсеше исә үз кысаларына тәрҗемәне алуга мөмкинлек бирә. XX гасырның икенче яртысына лингвистика үз ориентациясен тамырдан үзгәртә.

Телнең формаль структурасын өйрәнүдә җитәрлек, җитди уңышларга ирешкәннән соң, тел белгечләре, тикшеренүләр өлкәсен тагын да киңәйтеп, аңа тышкы лингвистика (макролингвистика) проблемаларын да кертәләр. Бу нисбәттән, телнең җәмгыять, фикерләү һәм чынбарлык белән бәйләнеше, вербаль коммуникациянең лингвистик һәм экстралингвистик аспектлары, кешелек җәмгыятендә мәгълүмат оештыру һәм тапшыру ысуллары һ.б. шундый фундаменталь мәсьәләләр карала башлый. Тел фәнендә сөйләм хәбәрләмәләре һәм текстлар структурасының эчтәлеген, тел берәмлекләренең контекстуаль мәгънәләрен, ситуацияне тасвирлау ысулларын тикшерү мөһим урын ала. Яңа лингвистик фәннәр (психолингвистика, социолингвистика, прагмалингвистика, текст лингвистикасы, сөйләм актлары теориясе, когнитив лингвистика һ.б.) барлыкка килә:

Тәрҗемәне өйрәнә башлагач, тел галимнәре тел белеменең тәрҗемә теориясенә генә түгел, бәлки тәрҗемәнең дә тел белеменә күп нәрсәләр бирә алуын ачыклыйлар. Тәрҗемәләр тәрҗемә процессында катнашкан телләр турында кыйммәтле мәгълүмат җиткерәләр. Тәрҗемә эшчәнлеге вакытында ике тел хәбәрләмәләрен һәм текстларын коммуникатив тиңләштерү ягыннан үзенчәлекле лингвистик эксперимент үткәрелә. Бу вакытта әлеге телләрдәге берәмлекләр һәм структуралар (төзелмәләр) кулланылышында аерма һәм охшашлыклар табыла.

Тәрҗемәнең лингвистик теориясе үсешендә машина тәрҗемәсенең төрле системаларын табарга омтылулар өстәмә стимул була. Тиз эшли торган электрон-хисаплау машиналары пәйда булу камилләшкән компьютерларның тәрҗемәче вазифаларын тизрәк һәм очсызгарак башкара алу өметен уята. Компьютерлар шифрланган хәбәрләрнең кодын ачуда уңышлы кулланыла башлый. Тәрҗемәне дә оригинал теле белән шифрланган текстның тәрҗемә телендә кодын ачу (декодирование) дип күзалларга мөмкин. Беренче машина тәрҗемәләре бик үк уңышлы нәтиҗәләр бирми, әмма зур хәтергә ия компьютерларның яңа буыны бу бурычны уңышлы хәл итәр дигән ышаныч кала. Тик тиздән шунысы ачыклана: машина тәрҗемәсенең төп проблемалары компьютер хәтере җитәрлек булмауга түгел, бәлки кеше кебек күп санлы тәрҗемә

кыенлыкларын чишә алырлык программа уйлап таба алмауга бәйле. Ә кешенең ничек тәрҗемә итүен бирәү дә аңлата алмый, чөнки әлеге эшчәнлек җитәрлек өйрәнелмәгән. Шунлыктан машина тәрҗемәсе белән шөгыльләнүче күп кенә тәрҗемәчеләр, кыенлыкларны чишү юлларын табарга теләп, “кеше” тәрҗемәсен өйрәнүгә керешәләр.

Хәзерге вакытта да машина тәрҗемәсенең заманча программалары теләсә нинди авырлыктагы текстларны югары сыйфатлы итеп башкара алмый, шуңа күрә тәрҗемәчене дә тулысынча алыштыру мөмкинлекләре юк. Шулай да, машина тәрҗемәсе өч очракта уңышлы кулланыла:

1) тар специализациягә караган, стандарт формадагы, лексик һәм грамматик яктан чикләнгән текстларны тәрҗемә итү өчен программалар бар;

2) машина ярдәмендә зур күләмле текстларны тиз генә түбән сыйфатлы итеп тәрҗемә итәргә була һәм шуның буенча оригинал эчтәлеге турында фикер йөртергә, тәрҗемәчегә төгәл тәрҗемә итү өчен нинди өлешләрен бирергә икәнлеген хәл итәргә мөмкин;

3) эшкә редактор катнаша: ул текстны я тәрҗемәгә әзерли, машина өчен авыр булган урыннарны алып ташлый яки хаталарны һәм төгәлсезлекләрне бетереп редакцияли.

Тәрҗемәдә субъектив фактор да билгеле бер роль уйный. Тәрҗемә факультетлары һәм бүлекләр, нигездә, чит тел университетлары, институтлары каршында ачыла һәм булачак тәрҗемәчеләрне хәзерләү чит тел укытучылары, филологлар, лингвистлар җилкәсенә төшә. Беренче чиратта нәкъ менә алар тәрҗемәче эшчәнлегенә теоретик караш кирәклеген тоеп ала һәм үз фәннәренең методлары ярдәмендә әлеге бурычны хәл итәргә омтыла.

Шулай да макролингвистика чикләрендә дә тәрҗемә эшчәнлегенең барлык якларын өйрәнү мөмкин дип ышанып булмый, тәрҗемәнең иң мөһим аспектлары телгә бәйләнгәнлеге күзгә ташлана. Телнең яшәү һәм кулланылыш үзенчәлекләре тәрҗемә зарурлыгын, тәрҗемәче очратырга ихтимал кыенлыкларны һәм аларны хәл итү мөмкинлекләрен билгели.

1. Кешеләр төрле телләрдә сөйләшкәнгә күрә тәрҗемә кирәк. Тел белгечләре традицион рәвештә аерым илләрдәге һәм

бөтен дөньядагы тел ситуацияләрен өйрәнәләр. Инде телләр төрлелеген тәрҗемәнең яшәү сәбәбе буларак карау зарурлыгы туа. Тел киртәләрен җиңеп чыгу өчен, тәрҗемә шактый катлаулы чараны тәшкил итә. Бу киртәләрнең барлыкка килү мәсьәләсе, аларның озак яшәү-яшәмәү проблемасы, алардан котылу җае тел белемен һәм тәрҗемә белемен кызыксындырмый кала алмый.

Телләр күптөрлелегенең биологик нигезе юк. Барлык кешеләр дә бер биологик төргә карый. Бөтен кешеләрнең дә баш мие бердәй төзелешле, теш һәм умыртка саннары да тигез, ашкайнату, кан әйләнеше системалары да, башка эчке органнары да охшаш. Алар барысы да кислород сулый, кислород җитмәгәндә яшәүдән туктый. Кешелекнең бу анатомик һәм физиологик охшашлыгын исәпкә алганда, бөтен кешеләрнең дә бер телдә сөйләшүе табигый булыр иде.

Дөрес, кешеләр берничә расага бүленә, тән төсе, сөякләр үлчәме һәм формасы, кан составы һ.б. билгеләре буенча берничә төркем аерыла. Бу нигездә дә дөньяда биш-алты тел һәм берничә диалект булу җитә кебек.

Чынбарлыкта исә эш башкачарак тора. Төрле исәпләүләр буенча хәзерге дөньяда 4-5 мең тел бар дип санала. Төгәл санны атау кыен, чөнки тел һәм диалект чикләре аерылмаган. Телләрнең күптөрлелек мәсьәләсе аңлатуга мохтаҗ.

Вавилон манарасы турында риваятьне яки чит планета кешеләре тәэсир итү ихтималын чынга алмаганда, телләрнең күптөрлелеге кешелекнең тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән дип ышанырга туры килә. Аерым төркем кешеләр ризык эзләү өчен үз кабиләләреннән китеп һәм аннан ерактарак урнашып, барлык бәйләнешләрны югалткач, тел мөстәкыйль рәвештә үсә башлый. Нәтиҗәдә кабилә теле һәм әлеге төркем теле аерыла башлый, бу аермалар тора-бара арта һәм яңа тел барлыкка килүгә сәбәп була.

Үз теле булу этник коллектив оешуда, кабилә, аннары милли үзаң үсүдә, бердәм хуҗалык, ау, җир эшкәртү, хәрби эшләр оештыруда мөһим роль уйный.

Әмма хәзерге чорда телләрнең күплеге негатив күренеш буларак карала, ул кешеләрнең һәм халыкларның үзара аңлашуына комачаулый, конфликтлар һәм сугышлар чыгуга

китерә дип санала. Шунлыктан аны юкка чыгару, һичьюгы начар тәэсирен киметү юллары эзләнә.

Шундый юлларның берсе – бөтен кешелек аралаша алырлык, бердәм ясалма тел уйлап табу. Мондый тел уйлап табуга караган фикерләр антик дөньяда ук барлыкка килә. XVII-XX гасырларда меңнәрчә проектлар эшләнә, әмма аларның берничәсе генә тормышка ашырыла (воляпюк, бесик, инглиш, эсперанто һ.б.). Алар арасында *эсперанто* киң таралыш ала, күп илләрдә аның тарафдарлары арта. Эсперанто телендә китаплар языла, симпозиумнар һәм конференцияләр уздырыла, төрле теллэрдән әдәби әсәрләр тәрҗемә ителә. Тик аның башка телләрне алыштырырлык бердәм телгә әйләнүе шикле. Кешеләрнең үз телләреннән, шуның белән бергә үз мәдәниятеннән, әдәбиятыннан, тарихыннан аерыласы килми. Теләсә кайсы ясалма тел бары тик өстәмә, ярдәмче роль генә үтәргә мөмкин.

Кешелек бердәм телгә тарихи үсеш юлы белән киләчәк дигән фаразлар да акланмый. Кешеләрнең зур бердәмлекләргә туплануы, аерым кечкенә төркемнәрнең юкка чыгуы кими. Мөгаен, кешеләрнең бер җәмгыятькә, бердәм дөньякүләм мәдәниятк ә, бер телгә хәрәкәте дә якын киләчәктә күзәтелмәс. Хәзерге заманда халыкара багланышларда *дөнья телләре* дип аталган телләр (дөньядагы күпчелек халыклар белгән милли телләр) куллану күзәтелә. Бүгенге көндә инглиз, француз, рус һәм испан телләре шундый роль уйный. Киләчәктә күп кешеләр икетелле (туган телен һәм бер дөнья телен белгән) булыр дип көтелә. Шунысын да әйтеп үтү мөһим: дөнья телләренең киң таралуына карамастан, тәрҗемәгә һәм тәрҗемәчеләргә ихтыяҗ кимеми. Киресенчә, хәзерге заманда тәрҗемәчелек эшчәнлегенең масштаблары көннән-көн үсә һәм якын киләчәктә тәрҗемәчеләргә эшсез калу куркынычы янамый.

2. Тәрҗемәче очрата торган кыенлыкларның беришесе телләрнең үзенчәлекләре һәм аларның объектларны атауда, ситуацияләрне тасвирлауда кулланылыш ысулларына да бәйле. Монда өч тип кыенлыкны аерып чыгарырга мөмкин: тел берәмлекләре семантикасындагы үзенчәлекләр; телгә карамаган чынбарлыкны чагылдыру өчен барлыкка китерелгән “дөнья

сурәтләренең (картиналарының)” туры килмәве; тәрҗемә ителгән текстларда тасвирланган чынбарлыктагы аермалар.

Тел берәмлекләре – билгеләнгән объектларны атау өчен кулланыла торган ярлыклар гына түгел. Һәрбер тел тамгасының ныклы, аңа гына хас мәгънәсе бар һәм, кагыйдә буларак, бу мәгънәләр төрле тел берәмлекләрендә туры килми. Шунлыктан тәрҗемә бер форманы икенчесе белән алмаштыруга гына кайтып калмый, тәрҗемәчегә тәрҗемә телендәге кайсы берәмлекләрнең мәгънәсе оригинал эчтәлегенә туры килүен даими хәл итәргә кирәк була.

Тәрҗемәче җиңеп чыгарга тиешле икенче лингвистик киртә – һәр тел чынбарлыкны үзенчә бүлгәли, шул рәвешчә үзенчәлекле “дөнья сурәтен (картинасын)” барлыкка китерә. Бу еш искә алына торган экзотик (эскимослардагы *кар* атамалары һәм Аргентина көтүчеләрендәге *ат төсе* кебек) мисалларга гына карамый, ә күп кенә гадәти атамаларга да кагыла. Моның өчен рус телендәге “собака”, “пёс” сүзләрен инглиз телендәге “dog” сүзе белән чагыштыру җитә. Дөньяның төрлечә бүлгәләнүе тәрҗемә вариантлары сайлаганда аерым кыенлыклар тудыра.

Тәрҗемә кыенлыклары тәрҗемәне кабул итүчеләр мәдәниятендә булмаган күренешләргә бәйле очракларда да килеп чыгарга мөмкин (*Никах нәрсә? Сабантуй?*). Мондый очракларда тәрҗемәче чит мәдәният факторлары белән таныш булырга гына түгел, аларны тәрҗемәдә чагылдыру, тәрҗемәне укучыларга аңлату турында кайгыртырга тиеш.

3. Тел факторлары тәрҗемәдә кыенлыклар гына китереп чыгармый, ә аларны хәл итү өчен шартлар да тудыра. Гәрчә һәр тел уникаль булса да, телләрнең төзелешендә һәм кулланылышында бер үк шартлар ята һәм менә шулар тәрҗемәдә аларны тәңгәлләштерергә мөмкинлек бирә. Барлык телләр дә яңгырашка һәм мәгънәгә ия ике яклы берәмлекләрдән тора, аларның башка кешеләр белән аралашканда фикер формалаштыру һәм тапшыру чарасы булып хезмәт итә торган сүзлек составы һәм грамматик төзелеше бар. Барлык телләр дә телдән тыш яши торган чынбарлык турында хәбәрләр төзү өчен кулланылалар. Алар барысы да вакыт, урын, сан, модальлек һ.б.ш. категория төшенчәләрен төрле юллар белән белдерәләр, предметлар классын, аерым объектлар һәм аларның билгеләрен,

процесс һәм халәтне аңлаталар. Телләргә күптөрле универсаль, гомуми һәм хосусый сыйфатлар хас. Бу универсальлек кешенең фикерләвен һәм әйләнә-тирә дөньяны чагылдыра. Ахыр чиктә нәкъ менә шулар тәрҗемәнең мөмкинлегенә китерә.

Теләсә кайсы кешенең теләсә нинди телгә өйрәнүгә тумыштан бирелгән сәләте – кеше теле һәм фикерләвенә хас универсаль характерның гаҗәеп чагылышы. Баланың, кайсы милләт вәкиле булуга карамастан, үзе яшәгән коллектив телен җиңел үзләштерә алуы мәгълүм. Бу сәләтне тел материалының күләме белән дә, өлкәннәрнең максатчан рәвештә өйрәтүе белән дә бәйләп булмый. Дөрес, ул факторлар да әһәмиятле. Күрәсең, кеше миендә телләргә өйрәнүнең ниндидер генетик механизм бар.

Хәзерге тел белемендә әлеге механизмның барлыкка килүен аңлатырга тырыша торган берничә гипотеза тәкъдим ителә. Америка лингвисты Н.Хомскиның *универсаль грамматика концепциясе* киң таралган. Аның фаразлары буенча, һәр баланың миенә дөньядагы барлык телләрнең төзелешен үз эченә алган универсаль грамматика салынган. Әйләнә-тирә тәэсирендә балада әлеге структураларның берсе активлаша һәм ул билгеле бер телгә өйрәнә. Универсаль грамматика булу аркасында балалар теләсә нинди милли варианттагы кеше теле кебек катлаулы системаны кыска вакыт эчендә үзләштерә ала. Телне өйрәнү баланың үз-үзен тотышындагы башка катлаулы формаларны (мәсәлән, йөреп китү) үзләштерүгә охшаган, алар да күпмедер дәрәҗәдә нейрофизиологик факторлар белән контрольдә тотыла. Н.Хомски гипотезасы баланың теләсә кайсы телне тиз өйрәнә алу сәләтен ачып бирә. Әмма аны барлык галимнәр дә кабул итә дип булмый. Мәсәлән, эволюция нәтиҗәсендә кеше миендә шундый катлаулы һәм тулаем диярлек кулланылмый торган структураның ничек формалашуын күз алдына китерү кыен.

Америкада яшәүче икенче бер лингвист Д.Бикертон Гавай утрауларында яшәүче эшче иммигрантларның балалары сөйләшә торган *креоль теле*н өйрәнә. Ул әлеге телне төрле илләрдән килгән һәм төрле телләрдә сөйләшүче балаларның (эти-әниләре катнашыннан башка) үзләре уйлап табуын ачыклый. Бу креоль теле грамматик төзлеше ягыннан алдагы

буыннарга таныш башка телләргә бөтенләй охшамаган, әмма җир шарының икенче өлешләрендә кулланыла торган креоль телләре белән структур яктан охшаш икән. Гавай утрауларында креоль теленең үсеше бала сөйләшергә өйрәнгәндә абстракт типтагы креоль теле барлыкка килә дип фаразларга мөмкинлек бирә. Башкача әйткәндә, кешедә тумыштан килгән механизм балага грамматик модельләр җыелмасын бирми, ә анда бердәм һәм үзенчәлекле модель формалаштыра. Тумыштан килгән грамматика соңыннан әлеге урындагы лексик берәмлекләр белән тулылана һәм креоль телләре барлыкка килә. Д.Бикертон, үз гипотезасын дәлилләп, түбәндәге фактларны китерә:

- балачакта инглиз балалары ясаган хаталар креоль теле модельләренә туры килә;
- әгәр креоль теленең грамматик төзелеше җирле телнекенә туры килмәсә, балалар даими рәвештә җирле тел структурасына хас булмаган хаталар ясыйлар;
- әгәр ике телнең (креоль һәм җирле) грамматик структуралары туры килсә, бала җирле телне яшьтән дөрес һәм тиз үзләштерә.

Бу гипотезалар дөрестерме-юктырмы, әмма барлык телләрдә дә универсаль сыйфатлар булу шик уятмый. Бу универсальлек тәрҗемәдә бер телдән икенче телгә уңышлы күчү өчен мөһим алшарт булып тора. Моннан тыш, тәрҗемә практикасы, төрле тел текстларының өзекләрендә аерым тел берәмлекләренең мәгънәләре туры килмәсә дә, аларның коммуникатив яктан тиңләштерелә алуын күрсәтә.

Төрле тел фәннәренең нигезләмәләре тәрҗемә эшчәнлегенең мөһим аспектларына ачыклык кертеп кенә калмыйча, тәрҗемәне тикшерү белән шөгыльләнүчеләрне күп кенә анализ методлары белән коралландыра. Алар ярдәмендә бу катлаулы феномен турында объектив мәгълүматлар тупларга мөмкин. Хәзерге тәрҗемәчелек белемендә тулысынча яки берникадәр кирәкле үзгәрешләр кертеп, лингвистик тикшеренү методларыннан файдаланыла.

Тәрҗемә процессында төрле тел текстлары арасында билгеле бер тәңгәллек, нисбәт урнаштырылганлыктан, тәрҗемәне өйрәнү дә *чагыштырма анализ процедуралары*н куллануны күздә тота. Текстларны чагыштыру – тәрҗемә

турында әһәмиятле мәгълүмат чыганагы. Хәзерге тәрҗемә белемендә мондый анализның дүрт процедурасы кулланыла:

1) тәрҗемә тексты оригинал белән чагыштырыла. Бу чагыштыру оригинал белән тәрҗемә эчтәлегенең һәм структурасының якынлык дәрәҗәсе турында кыйммәтле мәгълүмат бирә. Ул шулай ук эквивалентлыкка ирешү ысуллары, тәрҗемәдәге стандарт алымнар һәм тәрҗемә процессына караган башка шундый әһәмиятле характеристикалар хакында күзаллау булдырырга мөмкинлек тудыра;

2) бер үк оригиналның төрле тәрҗемәче тарафыннан эшләнгән берничә тәрҗемәсе чагыштырыла. Бу тәрҗемәченең квалификация дәрәҗәсенә һәм индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле булмаган гомуми закончалыкларны билгеләргә ярдәм итә;

3) тәрҗемәләр тәрҗемә телендәге оригинал текстлар белән чагыштырыла. Әлеге юл белән тәрҗемә теленең билгеле бер милли телнең аерым подсистемасын тәшкил итүе ачыклана. Чит тел оригиналы тәэсирендә тәрҗемәче вакыт-вакыт тәрҗемә теле нормаларын һәм узусын бозарга мөмкин. Бу бозулар еш кына чагыштырма анализ вакытында ачыклана һәм тәрҗемә хатасы буларак кабул ителә. Тәрҗемәче белепме, әллә белмичәме, аңлы яки аңсыз рәвештәме алынмалар, калькалаштыру, сүзгә-сүз тәрҗемә алымнарын һ.б. кулланып, тәрҗемә теленең коммуникатив мөмкинлекләрен киңәйткән очраклар теоретик планда аеруча зур кызыксыну уята. Мондый тайпылышлар үзенчәлекле тәрҗемә нормасын тәшкил итә һәм аклана, чөнки алар оригинал эчтәлеген тулырак күчерү максаты белән эшләнә;

4) тәрҗемә һәм оригинал телләрендәге параллель текстлар чагыштырып анализлана, ягъни якын эчтәлектәге, шундый ук функциональ стильгә яки жанрга караган текстлар чагыштырыла. Шул рәвешчә ике телдәге бердәй текстларда тел чараларын куллану аермалары ачыклана.

Төрле тел текстларын чагыштырып анализлау синтаксик бөтен буларак текстлар төзелешендә һәм эчтәлегендә охшашлык-аермалар, тәңгәллекләр билгеләүне генә түгел, бу текстлардагы аерым элементларны чагыштыруны да күздә тота. Бу вакытта тәрҗемә теориясе *компонентлы анализ*,

трансформацион анализ һәм *статистик хисаплау* кебек лингвистик тикшеренү методларыннан файдалана.

Тел берәмлекләре мәгънәсендә элементар мәгънәләрне (семаларны) аерып чыгару өчен *компонентлы анализ* куллану оригинал һәм тәрҗемә берәмлекләренең семалар составын чагыштырырга, аларның бер-берсенә тәңгәллек дәрәҗәсен билгеләргә ярдәм итә. Мәсәлән, рус телендәге *студент* сүзен инглиз (татар) теленә тәрҗемә иткәндә “укучы (обучаемый)”, “берлек сан” семалары күчерелә, әмма “югары уку йорты укучысы” һәм “мужской род” семалары юкка чыга *(student)*. Әгәр юкка чыккан семалар аралашу өчен әһәмиятле булса, алар тәрҗемәдә башка берәмлекләр ярдәмендә бирелергә тиеш. Киресенчә, оригиналдагы аерым семаларны нейтральләштергәндә, аларны тәрҗемәдә югалту аклана. Мәсәлән, рус телендәге “Хороший студент не будет прогуливать лекции” фразасында “мужской род” нейтральләшә, чөнки сүз ир-атлар хакында гына бармый, ә “югары уку йорты укучысы” семасы “лекция” сүзе мәгънәсендә аңлашыла. Шуңа күрә инглиз (татар) теленә “студент (student)” дип бирү җитә.

Тәрҗемә процессын тасвирлау өчен *трансформацион анализ методы* уңышлы кулланыла. Бу метод төп (ядерный) структураларны һәм аннан ясалган трансформаларны аерып чыгара. Трансформацион үзгәртүләр, бер яктан оригиналны адекват аңлау чарасы һәм иң соңгы тәрҗемә вариантын сайлау ысулы буларак карала ала. Икенче яктан, тәрҗемә процессы үзе үк телара трансформациянең аерым төре итеп тәкъдим ителә: шул рәвешчә тәрҗемә алымнарын тәрҗемә трансформацияләре итеп күрсәтергә һәм тасвирларга мөмкин.

Оригинал һәм тәрҗемә текстларының нисбәте турында өстәмә мәгълүматларны *төгәл статистик* яки *якынча хисаплаулар* белән алырга була. Аерым сүз төркемнәре, синтаксик төзелмәләр, лексик берәмлекләр, үзгәртү типлары һ.б. ешлык ягыннан чагыштырыла. Шул рәвешчә тулы кыйммәтле тәрҗемә таләпләрен канәгатьләндерү юллары билгеләнә: фигыль яки исемнәрне күбрәк куллану, эмоциональ лексиканың күплеге, җөмләләрнең уртача озынлыгы һ.б.

Тәрҗемә тикшеренүләрендә *лингвистик модельләштерү* методы (тәрҗемә процессының теоретик модельләрен төзү)

мөһим урын тота. Тәрҗемә фикерләү операцияләре ярдәмендә тәрҗемәче башында барганлыктан, аны күзәтеп булмый. Тәрҗемә процессының лингвистик моделе аны оригинал текстын тәрҗемә текстына эзлекле үзгәртүләр рәвешендә күз алдына китерә. Теләсә кайсы модель гипотетик характерга ия. Хәзерге тәрҗемә белемендә берничә тәрҗемә моделе (ситуатив, трансформацион, семантик, психолингвистик) кулланыла.

Тәрҗемәчеләр тел белгечләреннән *информантларны сораштыру* процессын да үзләштерәләр. Бер яктан, тәрҗемәче үзе информант була һәм ничек эшләве хакында сорауларга җавап бирә. Интроспекция методын куллану мөмкинлеге тәрҗемәчелек эшчәнлеген тикшерүдә чикләнгән, тәрҗемәче еш кына интуитив рәвештә эшли, шулай да кайбер мәгълүматларны бу ысул белән алырга мөмкин. Икенче яктан, информантлар тәрҗемәдән файдаланучылар (рецептор) булганда, алар тәрҗемә теле, аның укылучанлыгы турында фикерләрен әйтә, тәрҗемәгә карата үз таләпләрен куя.

Психолингвистик экспериментлар куллану да мәгълүматларның объективлыгын арттыра. Бу вакытта информантлар эксперимент шартларында эшли. “Кычкырып уйлау” методы нәтиҗәләре аеруча мөһим. Әмма монда тулы картина тумаска мөмкин, чөнки тәрҗемәче кайбер эш-гамәлләрен интуициягә таянып башкара һәм ул турыда әйтүне кирәк тапмый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тәрҗемәне лингвистик методлар ярдәмендә өйрәнү үзен-үзе аклый һәм бу максатка ярашлы дип санала.

2.2. ТӘРҖЕМӘНЕҢ ЛИНГВОСЕМИОТИК НИГЕЗЛӘРЕ

Алда әйтеп үтелгәнчә, тәрҗемә галимнәре күп кенә тел фәннәренең төшенчәләрен, методларын һәм мәгълүматларын файдаланалар. Тәрҗемәчелекнең теоретик нигезләрен эшкәртүдә гомуми тел белеме мәгълүматлары, аерым алганда аның семиотик концепцияләре зур роль уйный. Телнең төзелешендәге һәм яшәешендәге мөһим якларны ачыклаганда лингвистика тамгалар турындагы фәннең (семиотика) төрле нигезләмәләренә таяна. Безнең аңыбыздагы билгеле бер фикер эчтәлеге, төшенчә

яки бер төркем башка объектлар яисә аерым объект белән бәйле материаль объектка **тамга** дип әйтәләр. Тамгалар үзләре белдергән объектлар белән төрле бәйләнештә торырга мөмкин. Иконик тамгалар, тамга-символлар, тамга-сигналлар һәм конвециональ (шартлы) тамгалар була. Кеше күптөрле тамгалар чолганышында яши һәм алар аның тормышында гаять мөһим урын тота. *Иконик тамгалар* башка объектларны билгеле бер рәвештә сурәтләп, аларны охшашлыклары белән чагылдыралар. Картина, фотография һәм объектларның тышкы кыяфәтен төгәл итеп чагылдыра торган башка ысуллар шундый функция үти. *Тамга-символлар* билгеләнгән объектларны символик рәвештә күз алдына китерә. Мәсәлән, флаглар, герблар, значоклар һ.б. *Тамга-сигналлар* билгеле бер объектларның булуына ишарә итә: төтен – утны, күк күкрәү – яшенне һ.б. белдерә. Шул ук вакытта күп кенә тамгаларның үзләре белдергән объектлар белән турыдан-туры бәйләнеше юк. Аларның тамга функцияләре шартлы, *конвенциональ* характерда, алар иҗтимагый практика белән теркәлгәннәр. Мәсәлән, светофордагы төсләр, Морзе әлифбасындагы нокталар һәм сызыклар һ.б. Конвенциональ тамга бары тик система эчендә генә, башка тамгалар белән бәйләнештә генә яши ала. Яшел төс үзе генә тамга түгел, ул бары өч төс системасында гына (яшел, сары, кызыл) “хәрәкәт итәргә ярый” дигән функция үти башлый. Алга таба сүз шундый тамгалар турында барачак.

Һәр тамга өч төрле бәгланыш эчендә яши, алардан башка ул үз функциясен үти алмый. Беренчедән, тамга үзе белдергән әйбер, күренеш белән бәйләнештә, семиотикада бу *тамганың семантикасы* дип атала.

Икенчедән, система эчендә ул башка тамгалар белән бәйләнештә тора. Бу бәйләнеш *тамганың синтаксикасы*н барлыкка китерә.

Өченчедән, тамга үзен кулланучы кешеләр белән бәйләнештә, чөнки ул кем өчендер кирәк булганда гына тамгалыгын саклый. Әгәр әлеге предметны тамга буларак кабул итүче кешеләр юк икән, димәк, тамга үзе дә юк. Бу өченче бәйләнеш *тамганың прагматикасы* дип атала.

Әлеге өч төр бәйләнеш тамганың мәгънәсен, ул аңлата торган мәгълүматны тәшкил итә, шулар булганда гына тамгалар

нинди дә булса эчтәлекле хәбәрләрне формалаштыру һәм тапшыру өчен кулланыла алалар.

Тел катлаулы тамгалар системасыннан гыйбарәт, аның ярдәмендә башка тамгалар таныла һәм шәрехләнә ала. Тел тамгалары телнең яшәешен һәм кулланылышын, шулай ук тәрҗемә итү мөмкинлеген һәм үзенчәлекләрен ача торган билгеләргә, сыйфатларга ия.

Телнең төп семиотик сыйфатларыннан, иң беренче чиратта, ***ике яклылыкны, иреклелек*** һәм ***мәгънәлелек***не атарга кирәк.

Тел тамгасының ***ике ягы*** бар: матди (аваз ягы яки аның график сурәтләнеше) һәм идеаль як – тел берәмлегенең яңгырашы белән бирелә торган фикер, уйлау эчтәлеге. Бу ике як *белдерү планы* һәм *эчтәлек планы* дип тә йөртелә (форма һәм эчтәлек). Гәрчә алар аерым кешеләр хәтерендә сакланса да, иҗтимагый характерга ия. Тел коллективындагы барлык кешеләр өчен тамга бердәм, тотрыклы мәгънәгә ия, әмма коллектив әгъзалары телне төрле дәрәҗәдә белгәнлектән, аерым тамгаларны үз күзаллаулары һәм ассоциацияләре белән бәйләп карыйлар. Белем һәм телне белү дәрәҗәсе һәр кешенең үзенчәлекле *идиолект*ын характерлый. Тел тамгаларының иҗтимагый характеры телне аралашу чарасы буларак кулланырга мөмкинлек бирә.

Тел тамгасының мәгънәсе телдән тыш яши торган чынбарлыкның гомумиләшкән чагылышыннан гыйбарәт һәм фикерләүнең тагын бер гомумиләшкән формасы – *төшенчә*гә мөнәсәбәттә тора. Кеше аңы әйләнә-тирәне ике сигнал системасы формаларында чагылдырырга сәләтле. Беренчел сигнал системасы тирә-юньне кешенең тою-сизү органнары ярдәмендә кабул итә. Бер тою органына (күрү, ишетү, тою һәм тән сизү) тәэсир нәтиҗәсендә *сизем* барлыкка килә. Билгеле бер объект белән бәйле сиземнәр нигезендә кеше әлеге объектны тулаем кабул итә. Кабул ителгән объект хәтердә тиешле күзаллау булып саклана, моның өчен аны яңадан сизү-тою кирәк тә түгел.

Икенчел сигнал системасы, конкрет объектлардан читләшеп, әйләнә-тирә дөнья турында гомумиләшкән төшенчәләр формалаштырырга мөмкинлек бирә. Төшенчәдә

күләм һәм эчтәлек аерып карала (*күләм* – төшенчәдә гомумиләштерелгән объектлар классы; *эчтәлек* – объектларның билгеләре). Төшенчәгә күбрәк билге кергән саен аның күләме кими һәм киресенчә. Мәсәлән, “акча” төшенчәсенең эчтәлегенә “металлдан эшләнгән” дигән өстәмә билге кертелсә, таррак күләмле икенче төшенчә (монета – вак акча) аңлашыла.

Тел берәмлекләренең мәгънәсе стихияле төстә барлыкка килә һәм күләм белән эчтәлекнең катгый нисбәтеннән азат була (терминнардан кала).

Тел мәгънәләре икенчел сигнал системасына карый һәм барлык төшенчәләр сүзләр ярдәмендә атала, шуңа күрә тел тамгаларының мәгънәләрен дә, фәнни төшенчәләрдән аермалы буларак, *тел, көнкүреш* яки *гомумхалык* төшенчәләре дип йөртәләр. Әгәр фәнни төшенчәнең эчтәлеген һәм мәгънәсен билгеләмә белән ачып булса, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен еш кына ул нисбәтле булган төшенчә билгеләмәсен өстәмә мәгълүмат белән анықларга, синонимнар китерергә, цитаталар белән кулланыш үзенчәлекләрен һ.б. тасвирларга кирәк була. Мәсәлән, “утрау” төшенчәсен – “тирә-яктан су белән әйләндереп алынган коры җир кисәге” дигән билгеләмә ярдәмендә аңлатырга мөмкин. Әмма бу билгеләмә “чүлдәге яшел утраулар”, “шәһәрдәге тынлык утравы” кебек тезмәләрне аңлата алмый. Бөтен кешеләрдә төп төшенчәләр гомумилеге турында әйтеп булса, төрле телләрдәге бердәй төшенчәләргә караган сүз мәгънәләренең аермасы күзгә күренеп тора. Менә шулар тәрҗемәдә шактый гына кыенлыклар тудыра да инде.

Тел тамгалары чынбарлыкка төрлечә мөнәсәбәттә торырга мөмкин. Алар чынбарлыктагы чын объектларны (өй, агач, эт) яки кеше хыялында туган нәрсәләрне (су анасы, шүрәле, бәхет кошы), бердәнбер булган объектны (Мәскәү, Явыз Иван, Африка), абстракт төшенчәләрне (мәңгелек, билгесезлек) һ.б. атыйлар.

Тел тамгасының *эчтәлеге* катлаулы семантик төзелешкә ия була ала. Төп тел берәмлекләре эчтәлегендә сүз формасына гына хас мәгънә эчтәлеген һәм бер төркем сүзләргә хас мәгънә элементларын (грамматик мәгънә) билгелиләр. Лексик мәгънәдә берничә макрокомпонентны аерырга мөмкин, аларны шулай ук “мәгънәләр” дип йөртәләр. Бу иң элек лексик берәмлекнең

предметлы-логик мәгънәсе, аның объектларның билгеле бер классын атау сыйфаты. Сүз, үзе белдергән төшенчә кебек үк, предметлы-логик эчтәлектә белдерелгән объектлар классын һәм бу класска хас билгеләрне (сигнификат) чагылдырырга мөмкин. Шуңа күрә предметлы-логик мәгънә *денотатив-сигнификатив* яки *денотатив мәгънә* дип тә атала.

Денотатив мәгънәдән тыш, тел берәмлеге семантикасына өстәмә – *коннотатив* (эмоциональ, стилистик, образлы һ.б.) *мәгънәләр* дә керергә мөмкин. Күп кенә сүзләр нинди дә булса денотатны атаудан тыш, бу денотат белән бәйле аерым хис-тойгыларны да чагылдыралар. Тулаем алганда, эмоциональ характеристика уңай һәм тискәре була ала. Коннотациянең стилистик микрокомпоненты сүзнең билгеле бер аралашу шартларында күбрәк кулланылуына ишарә итә. Шундый эмоциональ-стилистик характеристикалы сүзләрне *гади сөйләм, китапча, рәсми һәм поэтик сүз*ләргә бүләргә мөмкин. Образлы характеристика предмет-күренештәге образ нигезендә (метафора яки чагыштыру) сөйләшүчеләр даими кулланган билгене аерып чыгара. Мәсәлән, “кар” – явым-төшемнең бер төре генә түгел, “аклык” эталоны да. Рус телендәге “щепка” – кешенең ябыклыгын белдерү өчен йөри, ә “энә”дә андый образлы коннатация юк.

Денотатив мәгънәләр дә, коннотатив мәгънәләр дә күп кенә тәрҗемә кыенлыклары китереп чыгара (алар “Гомуми тәрҗемә теориясе нигезләре” курсында карала).

Тәрҗемәнең асылын аңлауда тел тамгасының икенче үзенчәлеге – аның ***ирекле*** булуы да әһәмиятле. Күп очракта тел берәмлегенең яңгырашы белән мәгънәсе арасында нинди дә булса табигый яки логик бәйләнеш юк. Мәсәлән, кешенең табигатендә, тышкы кыяфәтендә яки үз-үзен тотышында аны “эт” дип атарлык бер билге дә юк. Тел берәмлегенең иреклелеге аның яңгыраш һәм мәгънә бәйләнешен аеруча ныклы итә, ни дисәң дә аларның берсе икенчесеннән башка була алмый: мәгънәсез авазлар тезмәсе тамга түгел, мәгънә нинди дә булса материаль форма белән бирелә. Бу бер үк мәгънәне төрле формалар белән, шул исәптән төрле тел чаралары белән белдерү мөмкинлеген аңлата. Тәрҗемәдә нәкъ менә шул күзәтелә дә. Тамганың иреклелеге аның ассиметриясен чагылдыра: бер

форма үзара бәйләнештәге берничә мәгънәгә ия (полисемия) яки төрле мәгънәләр белдерә ала (омонимия). Тулы иреклелек беренчел тамгаларга хас: ясалма форма да, мәгънә дә тулысынча яки өлешчә мотивлашкан була (ак – аклык, язу – язучылык һ.б.).

Тел тамгасының өченче төп сыйфаты – ***эчтәлеклелек, мәгънәлелек***. Бу тамга мәгънәсенең башка тамгаларның мәгънәләренә бәйле булуын аңлата. Мәсәлән, русча *собака* (“эт”) сүзенең мәгънәсе аның йорт хайваннарының бер төрен билгеләү белән генә түгел, бәлки “пёс” сүзенең мәгънәсе белән дә билгеләнә. *Лошадь* сүзенең мәгънәсен дә “конь” сүзе чикли һ.б. Кешенең дусты да “пёс” түгел, “собака”, ә җиңүче горур кыяфәттә “конь”га атланып бара, “лошадь”ка түгел. Нәкъ менә сүзләрнең эчтәлеге аерылу төрле телләрдә якын мәгънәле сүзләрнең (шулай ук синтаксик төзелмәләрнең) туры килмәвенә китерә. Ул билгеле бер дәрәҗәдә телдә үзенчәлекле “дөнья сурәтен (картинасын)” барлыкка китерә, шул исәптән тәрҗемәче өчен җитди кыенлыклар да тудыра.

Теләсә кайсы тамга системасы кебек үк, тел аерым берәмлекләрнең гадәти җыелмасы гына түгел. Ул үзара бәйләнештәге элементлардан торган бербөтен. Тел берәмлекләре системада бердәй халәт-торышларга ия булу сәбәпле (парадигматик бәйләнешләр) яки сөйләмдә бергә кулланыла алу (синтагматик бәйләнешләр) аркасында үзара бәйләнгән була. Тел берәмлекләре арасындагы бәйләнешләр тел системасының *структура*сын оештыра.

Тел структурасына кергән берәмлекләр берничә подсистема төзи, алар исә бер-берсе белән ярусара мөнәсәбәтләр ярдәмендә бәйләнгән. Телнең төп яруслары (дәрәҗә баскычлары) – фонетик, морфемик, лексик һәм синтаксик дәрәҗәләре. Бер баскычта торган берәмлекләр, икенчеләре белән ярашып, югары баскыч берәмлекләрен барлыкка китерә. Мәсәлән, фонемалар – морфемаларны, морфемалар – сүзләрне, сүзләр – җөмләләрне оештыра. Тәрҗемә процессында ике тел берәмлекләре арасында бер баскычлы мөнәсәбәтләр дә урнаштырыла ала.

Тел тамгаларының тел структурасына салынган төзелеш һәм кулланылыш мөмкинлекләренең барысы да реальләшми. Мәсәлән, рус телендә *читать, греть, жить* фигыленнән хәзерге

заман хәл фигыль (деепричастие) ясап була (грея, живя), ә *писать, петь, пить* фигыльләреннән мондый формалар ясау тел нормасын боза. Шулай ук *человеки, победю* сүзләре дә нормага сыешмый.

Тел нормасыннан тыш, тел тамгаларының кулланылышы сөйләм нормалары (узус) белән дә билгеләнә. Теләсә кайсы телдә гомумкулланылыш формалары һәм сирәк кулланылышлы төзелмәләр дә бар. Тел нормасын бозу сөйләмне хаталы (грамотасыз) итсә, узусны бозу аны гайре табигый, гадәти булмаган хәлгә китерә. Русча "Ответь на телефонный звонок" дияргә була, әмма күбрәк "Возьми трубку" диләр. (Держись подальше от травы. – По газонам не ходить.). Тәрҗемәчегә куелган төп таләп: тәрҗемә теленең дөреслеген саклау. Тәрҗемәдә тел нормасын бозу сирәк күренеш булса, сөйләм нормасын саклау тәрҗемәченең аеруча игътибарлы булуын сорый.

Телгә Ф. де Соссюр тәкъдим иткәнчә семантик яктан якын килү телнең аралашу чарасы буларак мөһим аспектларын ачарга ярдәм итә. Гәрчә Соссюр телне үз эчендә карау, ягъни эчке лингвистика белән чикләнүне күздә тотса да, телне тамга (кодлы) системаларына кертеп карау тел коды ярдәмендә хәбәрләрнең оешу мәсьәләсен куярга мәҗбүр итә. Соссюр бу мәсьәләне ачыклауга үзенчә юл күрсәтә: сөйләм эшчәнлегендә телне һәм сөйләмне, башкача әйткәндә кодны һәм хәбәр оештыруны аерып карарга кирәк, ди. Соссюр фикеренчә, тел – төшенчәләрне белдерә торган тамгалар системасы. Сөйләм – сөйләм эшчәнлегенең индивидуаль ягы, ул сөйләүче фикерләрен белдерү өчен кулланган тел кодын (комбинацияләрне дә кертеп) һәм әлеге комбинацияләрне объективлаштырырга ярдәм иткән психофизик механизмны үз эченә ала.

Ф. де Соссюр сөйләмнең индивидуаль һәм очраклы булуына басым ясый, шуңа бәйле рәвештә ул сөйләмне тел белеме кысаларыннан чыгара, чөнки, аның фикеренчә, тел белеме бары тик телне генә өйрәнергә тиеш. Дөрес, ул бу ике күренешнең бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булуын аңлый, әмма аның өчен телне система буларак өстенрәк икәнен раслау мөһимрәк тоела. Ә инде тел һәм сөйләмне аерып карау тел белеме үсеше өчен гаять әһәмиятле була.

Соссюр билгеләп үткәнчә, сөйләм акты ким дигәндә ике кешенең индивидуаль аралашуыннан, сөйләү һәм тыңлау, яки сөйләү һәм аңлау бердәмлегеннән гыйбарәт. Дөрес, һәр актның "сөйләү" өлешендә дә, "тыңлау" өлешендә дә билгеле бер конкрет индивидларга хас һәм башка актларда шундый ук рәвештә очрамый торган үзенчәлекләр була. Боларга, беренче чиратта, аралашуда катнашучыларның психофизиологик механизм үзенчәлекләрен кертергә була, алар индивидуаль "сөйләм фонын" барлыкка китерә (тотлыгу, артык паузалар, хырылдау, үзенчәлекле тембр, сүзләрнең яңгырашын бозу һ.б.). Болар сөйләм ярдәмендә аралашуга берничек тә тәэсир итми торган факторлар итеп, һичьюгы аңлашуга комачаулый торган коммуникатив шау, тавыш буларак кына кабул ителергә тиеш.

Тел коды берәмлекләреннән торган хәбәрләр *хәбәрләмә* (высказывание) рәвешендәге аралашу берәмлеген хасил итәләр. Формасы ягыннан хәбәрләмә бер сүздән дә, сүзтезмә яки җөмләдән дә торырга мөмкин. Мәгънәләре ягыннан бәйле хәбәрләмәләр төркеме яки мөстәкыйль кулланылган аерым хәбәрләмәләр *текст* барлыкка китерә. Текст телдән дә, язмача да төзелә ала. Хәбәрләмәгә эчтәлек һәм форма хас, шуңа күрә аны кайчак *конкрет җөмлә* дип йөртәләр һәм шул рәвешчә сүзнең телдәге грамматик берәмлек турында түгел, ә сөйләм берәмлеге хакында баруын искәртәләр. Текст һәм хәбәрләмә генә турыдан-туры тәрҗемә объекты булып хезмәт итә.

Аралашу вакытында хәбәрләмәләр алмашы бара, аларның эчтәлеге кулланылган тел берәмлекләре җыелмасы белән билгеләнә. Әмма хәбәрләмәнең мондый *тел эчтәлеге* гомуми мәгънәнең бер өлешен генә тәшкил итә. Хәбәрләмәнең мәгънәсе формалашу һәм аны аңлау катлаулы юл белән бара. Моны гадәти бер аралашу ситуациясе белән аңлатып үтик.

Әйтик, сез урам буйлап барганда, бер хатын-кыз каршыгызга килә һәм үтеп барышлый "Ничә?" дип сорый. Сез "Ике" дип җавап бирәсез, ә ул юлын дәвам итә. Кичен кайтканда сез тротуар кырыенда машина күрәсез, анда радиоалгыч эшләвен ишетәсез һәм шофердан "Ничә?" дип сорыйсыз, ә ул "Икегә – өч, Рубин" дип җавап бирә. Ике очракта да аралашу уңышлы була һәм аралашучылар бер-берсен дөрес аңлый диярга мөмкин. Ә бу ничек шулай була соң? Ни өчен беренче очракта

“Ничә?” дигән сорау “Сәгать ничә?” дип аңлашыла, ә икенче очракта шофер уен исәбен сорау дип уйлый. Баксаң, тел ярдәмендә уңышлы аралашу өчен аралашучылар җитди фикер йөртергә, хәбәрләмәнең тел эчтәлеген аңлау өчен аны ике фактор белән чагыштырырга тиеш икән: бу, беренчедән, аралашу обстановкасы һәм, икенчедән, үзенең тел буенча белемнәре һәм чынбарлык турында элеккеге тәҗрибәсе.

Ашыгып барган хатын соравын дөрес аңлау өчен, аның урам уртасында бирелүен исәпкә алу кирәк. Әгәр әлеге хатын соравын сез кибеттә бананга чират торганда бирсә, ул вакыт белергә тели дип һич уйламас идегез. Әйтелгәннең эчтәлеген дөрес аңлау өчен күп белергә дә кирәк. Мисал өчен, сез кешеләрнең иртән эшкә ашыгуын, тиешле вакытка эшкә барып җитәргә тиешлеген, юкса эштә күңелсезлекләр булачагын һ.б. аңларга тиеш. Шулай ук татар (рус) телендә “Сәгать ничә?” дип кенә түгел, “Вакыт күпме?” дип тә сорау мөмкинлеген истә тоту мөһим. Башкача әйткәндә, сезнең тормыш һәм лингвистик тәҗрибәгез булу кирәк: шул вакытта бу тәҗрибәне һәм аралашу актын хәбәрләмәнең тел эчтәлеге белән чагыштырып, нәрсә сораулары турында нәтиҗә ясала.

Күргәнегезчә, гади генә хәбәрләмәне аңлау өчен күпме фикер эшчәнлеге таләп ителә. Монда тагын ике хәлне дә исәпкә алу әһәмиятле. Беренчедән, әйтүче тыңлаучы дөрес фикер йөртер һәм әйтергә теләгәнен аңлар дип уйлый. Икенчедән, телдән аралашу – гаять катлаулы, ул ялгыш аңлау яки бөтенләй аңламау ихтималын да күздә тота. Тыңлаучы, белеме җитмәгәнлектән, тиешле мәгънәне тотып алмаска мөмкин. Шуңа күрә “Ничә?” соравына “Нәрсә ничә?” дип җавап кайтаруы бар.

Телдән аралашу үзенчәлекләреннән тәрҗемә асылын аңларга ярдәм итә торган тагын бер нәтиҗә ясарга була. Һәрбер аралашучының телне белү дәрәҗәсе (идиолекты) һәм үз фон белемнәре була, шунлыктан аларның хәбәрләмәне кабул итүләре һәм аңлаулары бертөрле түгел. Шуңа күрә һәр текст ике яссылыкта – тыңлаучы өчен һәм сөйләүче өчен яши. Берәү әйткән нәрсә ул әле икенче берәү кабул иткән һәм аңлаган нәрсә булмый. Әмма бу очракта “бертелле” аралашуның ике үзенчәлеген дә истә тотарга кирәк. Беренчедән, аралашучылар бу ике яссылык булуын белми, алар текстны берәү әйткән,

икенче кабул иткән әйбер дип уйлый, ягъни бу ике яссылык бер булып кабул ителә. Икенчедән, текст яшәгән яссылык “бертелле” аралашуда якынлыклары белән берләшә. Бер телдә сөйләшүчеләр аралашуда күпчелек кешеләр өчен гомуми мәгънәгә ия тамгалардан файдалана һәм аларның фон белемнәре дә охшаш була. Алар бер үк мәдәнияткә карый, тарихлары, әдәбиятлары, көндәлек тормышлары охшаш. Бу күп очракта уңышлы аралашуга китерә. Төрле телләрдә сөйләшүчеләр аралашканда әлеге гомумилек булмау тәрҗемәнең үзенчәлеген тудыра.

Телдән аралашуның тагын бер сыйфаты түбәндәгедән гыйбарәт: хәбәрләмә төзелешендә иреклелек һәм мәҗбүрилек яраша, берләшә. Бер яктан, сөйләүче үз ниятеннән чыгып, тел чараларын ирекле сайлый ала. Икенче яктан, тел аңа билгеле бер форма һәм эчтәлекне көчләп тага. Мәсәлән, рус телендә сөйләүче ихтыярсыздан род, вид кебек грамматик мәгънәләрне куллана, сыйфатларны исем белән родта, санда һәм килештә яраштыра. Телләр бер-берсеннән нәрсә белдерә алулары белән генә түгел, ә нәрсәне белдерергә ярамаулары белән күбрәк аерылалар.

Шулай итеп, хәбәрләмәнең тел эчтәлеге хәбәрнең бер өлешен генә тәшкил итә, шуның нигезендә глобаль эчтәлек килеп чыга.

Шул ук вакытта уңышлы аралашу өчен хәбәрләмә эчтәлегеннән алып булган барлык мәгълүматтан файдалану ихтыяҗы да юк. Еш кына аралашучылар глобаль эчтәлекнең бер өлеше белән дә канәгатьләнәләр. Мәсәлән, текстта тропик урман сурәтләнә һәм агачлар арасында колибрилар очу турында әйтелә, ди. Орнитолог моннан колибриларның тышкы кыяфәте һәм яшәү рәвеше турында мәгълүмат ала. Әмма уртакул укучыга бу мәгълүматны алу мөмкин дә, кирәк тә түгел. Аңа колибриның ниндидер экзотик кош булуын аңлау да җитә. Ул бу кошны күргәч танымаска да мөмкин, тик әлеге аралашу акты өчен ул мөһим саналмый.

Бирелә торган мәгълүматның күпмедер өлеше югалуга карамастан, аралашу мөмкинлеге “тәрҗемә ителмәү” теориясенең урынсыз булуын дәлилли. “Тәрҗемә мөмкин булмау” дип белдерү оригиналга тулысынча туры килгән текст

кына тәрҗемә була, ә инде нәрсәдер югалган икән, бу инде тәрҗемә түгел, дигән ялган шарт белән бәйле. Әмма тәрҗемә – төрле телләрдә сөйләшүчеләргә аралашу мөмкинлеген тудыру чарасы. Шуңа күрә телара коммуникациянең мәгълүмати югалтулардан башка булуын таләп итәргә урын юк, чөнки андый югалтулар бер телдә аралашканда да күзәтелә.

Телара коммуникация схемасы түбәнгедән гыйбарәт: нинди дә булса телне белгән кеше башкаларга нидер әйтергә теләсә, әлеге тел берәмлекләреннән тиешле хәбәрләмә төзи; шушы ук телне белгән икенче берәү исә, аралашу халәтенә һәм фон белемнәренә бәйле рәвештә, бу хәбәрләмәдән кирәкле мәгълүматны ала. Табигый, телне белмәгәннәр бу хәбәрләмәне аңлый алмый һәм алар белән аралашу өчен ике телне дә белгән арадашчы (тәрҗемәче) катнашу кирәк була. Тәрҗемәче чыганак тел хәбәрләмәсеннән кирәкле мәгълүматны ала да, тәрҗемә телендә яңа хәбәрләмә барлыкка китерә. Бөтен текст тәшкил иткән бер төркем хәбәрләмәләр белән дә эш шулай тора. Чыганак телдәге текст нигезендә тәрҗемә телендә текст оештырыла.

Тәрҗемәне телара коммуникация кысаларында тикшерү-карау тәрҗемә теориясенең предметы турындагы мәсьәләгә ачыклык кертергә мөмкинлек бирә.

Тәрҗемә турындагы фәннең теоретик өлеше, ягъни тәрҗемә теориясе тәрҗемәне өйрәнү белән шөгыльләнергә тиешлеге аңлашыла. Әмма, нәрсә соң ул тәрҗемә? Көндәлек кулланышта бу сүз ике мәгънәгә ия: 1) тәрҗемә процессы; 2) бу процессның нәтиҗәсе булган текст.

Тәрҗемәнең лингвистик теориясе барлыкка килгәннән соң, тәрҗемә процессын яки аның нәтиҗәсен теория предметы буларак карау дөресме, дигән бәхәс кузгала. Бер концепция тарафдарлары нәкъ менә тәрҗемә процессы тәрҗемә эшчәнлегенең асылын тәшкил итә дип белдерәләр һәм аны башка бер генә фән дә өйрәнергә тиеш түгел дип фикер йөртәләр. Аларга каршы торучылар, тәрҗемә процессы тәрҗемәченең башында бара, аны өйрәнү мөмкин түгел, аның турында мәгълүматны бары нәтиҗәсен өйрәнеп кенә алырга була дип дәлиллиләр. Бу капма-каршылык тәрҗемәгә коммуникатив якын килүнең бөтен мәгънәсен югалта. Дөрес,

телара коммуникация кысаларында тәрҗемәнең процессы да, нәтиҗәсе дә – барлык лингвистик һәм экстралингвистик факторлар да өйрәнелергә тиеш, чөнки нәкъ менә шул факторлар төрле телләрдә сөйләшүче кешеләрнең аралашу мөмкинлеген һәм характерын билгели.

Тәрҗемә белеменең предметын тагын да төгәлрәк итеп билгеләү телара коммуникация ысулларының кайберләрен аеруны таләп итә. Оригинал эчтәлеген икенче телдә төрле процедуралар ярдәмендә биреп була. Оригинал текстны тәрҗемә итәргә, эчтәлеген сөйләргә, реферат, аннотация һәм резюме язарга мөмкин. Теләсә нинди очракта да тәрҗемәче телара коммуникациядә арадашчы ролен үти һәм шуңа күрә хәзерге тәрҗемә белеме аларның һәркайсын өйрәнә. Тәрҗемәдән тыш, бу ысулларга оригинал эчтәлеген яңадан эшләү, билгеле бер кагыйдәләр буенча төзелешен, хәбәрен үзгәртү хас. Шунлыктан аларны "адаптацияләнгән күчерү", "адаптив транскодлаштыру" дип йөртәләр һәм "чын тәрҗемә"гә каршы куялар. Дөрес, соңгысына билгеләмә бирүдә кайбер кыенлыклар да туа.

Беренче карашка, тәрҗемә адаптив транскодлаштырудан оригинал эчтәлеген үзгәртмәү, ә тулысынча, төгәл, эквивалент күчерү белән аерыла кебек. Шуңа бәйләп, күпчелек тәрҗемәчеләр "тәрҗемә" төшенчәсенең билгеләмәсенә бу сыйфат билгесен кертәләр. Әмма чынлыкта тәрҗемәләрнең яхшысы да, начары да, оригиналны теге яки бу дәрәҗәдә төгәл чагылдырганы яки аннан шактый читләшкәне дә була. Кайчак оригиналга якын тәрҗемә начар сыйфатлы, ә төп нөсхәнең җентекләп сөйләнгән эчтәлеге яхшырак булырга мөмкин. Шунлыктан "тәрҗемә"гә туры килә торган билгеләмә табу өчен тәрҗемә текстларының аларны кабул итә торган мәдәнияттәге куллашылыш-яшәешен дә күздә тотарга кирәк. Тәрҗемәне кабул итүчеләр аны функциональ яктан гына түгел, бәлки эчтәлек һәм төзелеш ягыннан да оригинал белән тиңләштереп карыйлар, алар тәрҗемә һәм оригинал эчтәлеге бер үк дип уйлыйлар (әмма бу алай була алмый), шулай ук тәрҗемә оригиналга тулаем гына түгел, ә детальләре белән дә туры килә, бу ике текстның төзелешләре дә бердәй дип фикер йөртәләр. Әгәр тәрҗемәдә 10 бүлек һәм бүлекчә икән, оригиналда да шулай дип фараз итәләр. Тәрҗемәдә нindидер фикер икенче бүлек башында булса,

оригиналда да шулайдыр дип уйлыйлар. Тәңгәллек турындагы бу фикерләр тәрҗемәнең автор фамилиясе астында басылуына да бәйле.

Димәк, укучы өчен тәрҗемә тексты оригиналның тулы кыйммәтле алыштырмасы буларак кабул ителә.

Тәрҗемәне аерып тора торган билге дә нәкъ менә шул – оригиналның тулы хокуклы алмаштырмасы булып хезмәт итү. Моннан тәрҗемәгә билгеләмә бирү мөмкинлеге туа: тәрҗемә – икенче телдә оригиналның тулы хокуклы алыштырмасы барлыкка китерелә торган телара арадашчылык төре. Бу билгеләмә барлык төр тәрҗемәләрне (яхшы, начар) үз эченә ала, тәрҗемәне мондый максатка хезмәт итми торган башка телара коммуникацияләрдән аера.

Тәрҗемәнең асылын һәр тәрҗемәче аңларга тиеш, чөнки тәрҗемәне кабул итүче аны һәрвакыт оригиналга тиң дип уйлый. Кагыйдә буларак, тәрҗемәнең оригиналга ни дәрәҗәдә тәңгәл булуын рецептор оригиналны күрмичә әйтә алмый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: хәзерге тел белеменең телне семиотик система буларак карау нигезләмәләре һәм тел тамгаларын, төзелмәләрен тел ярдәмендә аралашу процессында куллану тәрҗемә эшчәнлегенең әһәмиятле якларын, лингвистик механизмын һәм аның аралашудагы ролен өйрәнү өчен концептуаль нигез барлыкка китерәләр.

2.3. ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕНЕҢ ТЕКСТОЛОГИК НИГЕЗЛӘРЕ

Хәзерге тәрҗемә белеме өчен текст лингвистикасы өлкәсендәге тикшеренү нәтиҗәләре дә зур әһәмияткә ия. Инде алда әйтелгәнчә, тәрҗемә вакытында төрле тел текстларын тәңгәлләштерү бара. Моны эшләү һәм нәтиҗәләрне бәяләү төрле тип текстларның формасын, эчтәлеген чагыштыру, һәр телдә текстның төзелеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен исәпкә алу, текстны төзегән тел берәмлекләрен һәм төзелмәләрен тулы текстка нисбәттә анализлау осталыгын таләп итә. Болар исә текст лингвистикасы нигезләмәләре һәм алымнары ярдәмендә генә башкарыла ала.

Текст – вербаль (тел ярдәмендә) аралашу өчен кулланыла торган сөйләм әсәре. Ул сөйләүче нияте белән сайланган һәм телнең грамматик кагыйдәләре буенча төзелгән тел берәмлекләреннән торган хәбәрләмәләрдән гыйбарәт. Әмма ул хәбәрләмәләрнең гади җыелмасы гына түгел. Текст – катлаулы төзелешкә ия мәгънәви бөтен, аның коммуникатив мөмкинлекләре хәбәрләмәләрнең тулаем мәгънә җыелмасыннан күпкә зуррак. Тәрҗемәче оригинал текстының әлеге бөтенлеген аңлап, тәрҗемә текстының да бөтенлеген тәэмин итәргә тиеш.

Текстның эчтәлеге, мәгънәви төзелеше *вертикаль, горизонталь* һәм *тирәнлек* үлчәмнәрендә каралырга тиеш.

Текстның *вертикаль төзелешен* аның формаль-тематик эчтәлеге барлыкка китерә: подтема, субподтема, микротема һ.б. Текстны "өстән-аска" таба "тарату, җәеп салу" сөйләүче тарафыннан башкарыла, ә кабул итүче текстны, киресенчә, "астан-өскә" таба, ягъни эчтәлекнең ваграк өлешләреннән текстны тулаем аңлауга таба формалаштыра. Әмма текстның вертикаль төзелеше һәрвакыт ачыктан-ачык күренеп тормаска һәм логикага сыймаска да мөмкин: кайбер микротемалар төшеп кала, чит подтемалар килеп кереп, бер-берсенә каршы килә һ.б. Бу җитешсезлекләр аралашучыларның белемнәре һәм тәҗрибәләре белән тулыландырыла.

Текстның бөтенлеген тудыруда хәбәрләмәләр арасындагы формаль һәм мәгънәви бәйләнешләргә нигезләнгән *горизонталь төзелеш* тә зур әһәмияткә ия. Текстның формаль оешуы (*когезия*) төрле тел чаралары ярдәмендә бара: теркәгечләр, кабатлаулар, заман һ.б. формаларның ярашуы. Текстның мәгънәви бөтенлеген (*когерентлык*) сөйләмнең логик эзлеклелеге һәм каршылыксыз булуы, логик бәйләгечләр ("шулай итеп", "нәтиҗәдә", "йомгак ясап әйткәндә" һ.б.), хәбәрләүнең башламын һәм ахырын аңлата торган стереотип формулалар һ.б. барлыкка китерә.

Когерентлык текстның тема-рема төзелеше белән дә турыдан-туры бәйле. Тема һәм рема нисбәте, яки актуаль бүленеш аерым хәбәрләмәнең мәгънәви төзелешенә дә хас. Хәбәрләмә эчтәлегендә ике мәгънәви фокусны аерып күрсәтергә була. Берсе аның – *тема*, тыңлаучыга таныш өлеш, икенчесе – *рема*, хәбәрнең төп мәгънә үзәге, тыңлаучыга җиткерелә торган

яңа мәгълүмат. Тәрҗемәче текст оештырганда оригиналның тема-рема төзелешен сакларга тиеш.

Тәрҗемә теориясе һәм практикасы өчен текст эчтәлегенең *тирәнлеген* җентекләп тасвирлау да әһәмиятле. Сөйләүче үзе уйлаган хәбәрне җиткерү өчен сайлаган тел чаралары үзенә бертөрле "мәгънә кирпечләрен" тәшкил итәләр. Алар һәр аерым хәбәрләмәдә башкалар тиешле мәгълүматны ала алырлык итеп сайланалар һәм оештырылалар. Бу мәгълүмат хәбәрләмәдәге "мәгънә кирпечләре"нең гадәти суммасы гына түгел. Бер яктан, хәбәрләмәдәге тел чараларының шушы очрак өчен иң әһәмиятле мәгънәләре генә сайлап алына. Димәк, хәбәрләмә эчтәлеге андагы берәмлекләрнең мөмкин булган мәгънәләре суммасына караганда таррак була. Икенче яктан, хәбәрләмәдәге тел берәмлекләре, үзара бәйләнешкә кереп, аларда моңарчы булмаган яңа мәгълүмат барлыкка китерә һәм, нәтиҗәдә, хәбәрләмәнең мәгънә эчтәлеге мәгълүматка баерак булып чыга.

Хәбәрләмә составындагы тел берәмлекләренең мәгънәләреннән килеп чыккан мәгълүмат аның *тел эчтәлеген* тәшкил итә. Бу – тел чаралары җыелмасына бәйле булган "өстән-өстән" генә бирелгән мәгънә. Ул һәрвакыт гомумиләштерелгән була, күп төрле вариантларда бирелергә мөмкин типик ситуацияне сурәтли.

Аралашканда "өстән" генә аңлау да җиткән һәм конкрет ситуация белән бәйле булмаган очраклар күзәтелә (мәсәлән, таныш булмаган кешеләрнең таныш булмаган әйбер турында фикер алышуы). Теләсә кайсы аралашу актында хәбәрләмәне аңлау "тирәнлеге" төрлечә була, аларның кайберләрен хәбәрләмәнең тел эчтәлеге дә канәгатьләндерә. Тик кайвакыт тел эчтәлеге өлешчә генә аңланырга яки бөтенләй аңланмаска мөмкин. "Вербаль белем" дип аталган күренеш бар, бу вакытта сөйләүче укыганны яки ишеткәнне аңламаган килеш кабатлый ала. Шунысы кызык: мондый механик кабатлауның, сөйләүчегә аңлашылмаса да, башкалар өчен аңлаешлы булуы ихтимал.

Текстның тел эчтәлеге аның тирән мәгънәви структурасында беренче катлам гына, текстның глобаль эчтәлеге шушы катламның үзеннән һәм аның аша алына. Ул, гадәттә, текст биргән мәгълүматның бер өлешен, аның да бик үк

әһәмиятле булмаган өлешен генә үз эченә ала. Әмма текстның тел эчтәлеге мөстәкыйль рәвештә дә кайбер конкрет аралашу функцияләрен үти ала, типик ситуацияне тасвирлау конкрет референтлар белән мөнәсәбәттә була һәм һәр хәбәрләмә бердәнбер контекстка керә. Инде ул өстәмә рәвештә конкрет фикер предметы белән шәрехләнә. Тел берәмлекләренең шул рәвешчә икенчел актуальләшүе мәгълүмат дәрәҗәсен киңәйтә һәм баета.

“Кичә кич белән Наил безнең тәрәзә каршында үсеп утыра торган агачны кисте” фразасы конкрет кешенең билгеле бер урында һәм билгеле бер вакытта башкарган эш-гамәлләрен сурәтли. Шуңа күрә коммуникатлар өстәмә мәгълүматка да ия булырга мөмкин: кем ул Наил; нинди агач иде ул; бу агач әлеге урынны бизәгәнме, әллә комачаулаганмы; Наилнең аны кисәргә хокукы булганмы һ.б. Бу хәбәрләмәдә мактау, соклану, ачу һ.б. чагылырга мөмкин. Нәкъ менә хәбәрләмәнең конкрет контекстуаль мәгънәсе күпчелек сөйләм актларының төп эчтәлеген тәшкил итә. Бер үк тел берәмлекләре җыелмасы белән күп конкрет очракларны тасвирлый алу телнең аралашу мөмкинлекләрен киңәйтә, сөйләмне кешеләрнең практик эшчәнлегенә кертә, әйтелгәннәрне күрү-сизү органнары белән кабул ителгәннәр белән бәйли.

Тел хәбәрләмәләрен конкрет ситуацияләр белән бәйләп карау барлык кешеләргә дә хас. Чөнки хәбәрләмәнең һәм тулаем текстның конкрет-контекстуаль мәгънәсе кешенең белеменә, хисләренә, ассоциацияләренә бәйле һәм алар бар кешедә дә бердәй булмый. Гәрчә төрле тулылыкта булсалар да, алар аралашу вакытында хәбәрләмәнең тел эчтәлеген контекстуаль мәгънә нигезе буларак кабул итәләр.

Текстның глобаль эчтәлеге ике семантик катлам (тел эчтәлеге һәм конкрет-контекстуаль мәгънә) белән бик сирәк очракта гына чикләнә. Хәбәрләмәнең тел эчтәлеге сөйләм коммуникациясендә өстәмә мәгънә бирергә дә сәләтле, бу да мөһим роль уйный. Әлеге өстәмә мәгънә хәбәрләмә белән *имплицит* рәвештә бәйләнгән була. *Импликация* – фаразлауның бер формасы, ә текстның *имплицит мәгънәсе* – импликациянең үзенчәлекле бер төре. Тәрҗемәдә моңа бәйле кайбер кыенлыклар килеп чыга. Хәбәрләмәнең фаразланган мәгънәсендә ике төр

имплицитлыкны аерып карыйлар: аның беренчесе конкрет-контекстуаль мәгънә белән *(контекстуаль-индивидуаль имплицитлык)*, ә икенчесе хәбәрләмәнең тел эчтәлеге белән бәйле. Конкрет контекстта теләсә кайсы хәбәрләмә өстәмә мәгънә алырга мөмкин. Мәсәлән, "Мин мәктәпкә барам" фразасыннан "Шуңа күрә ашыгам", "Мин инде зур", "Минем сезнең белән сөйләшәсем килми" һ.б.ш. өстәмә мәгънәләр аңлашыла ала. Мондый имплицитлык тел берәмлекләре җыелмасы белән бик үк бәйләнмәгән һәм бары конкрет аралашу актының индивидуаль үзенчәлекләренә карый. Шуңа да ул ачыктан-ачык күренеп тора һәм аралашучылар тарафыннан дөрес аңлана.

Импликациянең икенче төре хәбәрләмәнең тел эчтәлеге белән турыдан-туры бәйләнгән. Тел берәмлекләре аралашуда мөһим роль уйный торган өстәмә мәгънәләр барлыкка китерергә сәләтле. Мондый имплицитлык, бер яктан, текст импликациясенең бер өлешен тәшкил итә, икенче яктан, ул тел факторлары белән билгеләнә. Шуңа күрә ул тотрыклы һәм билгеле бер составка ия хәбәрләмә төрле текст ситуацияләренә эләккәндә дә саклана. Индивидуаль-контекстуаль имплицитлыктан аермалы буларак, аны *гомумкоммуникатив имплицитлык* дип атарга була.

Гомумкоммуникатив имплицитлык ассоциация характеры буенча аерыла, шулар нигезендә өстәмә мәгънә барлыкка килә. Белдерелгән һәм күздә тотылган мәгънәләр арасында предметлы тәңгәллек тә ("ачкычны бору" – ишекне бикләү яки ачуны күздә тота), логик нәтиҗә дә ("ул 100 метр араны 8 секунд эчендә йөгереп үтте" – дөнья рекордын күпмегәдер яхшыртуны аңлатырга мөмкин), символик эчтәлек тә ("ул башын какты" – килешүне белдерә), әдәпле итеп әйтү дә ("түгәрәкләнеп китү" – тазару), образлы итеп сурәтләү ("өрмәгән җиргә дә утыртмау" – бик кадерләү) һ.б.ш. мөнәсәбәтләр булырга мөмкин.

Импликация белән тел берәмлекләренең мәгънәсе арасындагы бәйләнеш хәбәрләмәнең сөйләм һәм тел чигендәге халәтен чагылдыра: бер яктан, хәбәрләмә – текст берәмлеге, икенче яктан – тел системасы берәмлеге.

Телне белүче кешеләрнең аралашу сәләтенә, тел буенча белемнәреннән тыш, хәбәрләмәнең тел эчтәлеген шәрехли алу, аннан контекстуаль һәм имплицит мәгънәләр чыгару кирә. Аралашучылар хәбәрләмәдән бөтен мәгълүматны алу мөмкинлегенә ия. Әмма аралашу вакытында мәгълүматның бер өлеше генә дә кабул ителә. Белдерелгән эчтәлекне тулысынча аңлау белән беррәттән, а) имплицит мәгънәне аңламау (буквальаңлау), ә) конкрет контекстуаль мәгънәгә төшенү өчен тел эчтәлеген предметлы белем белән бәйли алмау (“вербаль” аңлау), б) хәбәрне өлешчә аңлау яки бөтенләй аңламау кебек очраклар да күзәтелүе ихтимал.

Тәрҗемәнең бурычы – оригинал текстының эчтәлеген күчерү. Идеалда тәрҗемәче текстның бөтен глобаль эчтәлеген бирергә омтылырга тиеш кебек. Әмма бу глобаль эчтәлек белдерелгән мәгънәдән дә, аның коммуникантлар өстәгән өстәмә мәгънә компонентларыннан да килеп чыга. Тәрҗемә текстының да глобаль мәгънәсе нәкъ шундый компонентлардан төзелә. Шуңа күрә тәрҗемәдә оригиналның тел эчтәлеген төгәлрәк чагылдыру уңышлы чишелешне тәшкил итә, рецепторлар шуннан мөстәкыйль рәвештә конкрет контекстуаль һәм имплицит мәгънәләр чыгара алалар. Тик монда да кайбер кыенлыклар очрый.

Иң элек, оригиналның тел эчтәлеге тәрҗемәдә беркайчан да тулы күләмендә чагыла алмый һәм тулы тәңгәллеккә ирешү мөмкин түгел. Тәрҗемә һәм оригинал текстларының фактик тәңгәллегенә эквивалентлыкның төрле дәрәҗәләрендә, мәгънә элементларының кайберләрен югалту хисабына ирешелә.

Тәрҗемәдә оригиналның имплицит мәгънәсе дә төрлечә күчерелергә мөмкин. Оригиналда күздә тотылган (имплицит) мәгълүмат тәрҗемәдә дә имплицит булып калырга тиеш. Күп кенә очракларда оригиналның тел эчтәлеген эквивалент итеп күчерү текстның имплицит мәгънәсен дә саклый. Шулай да ачыктан-ачык чагылыш тапкан һәм күздә тотылган мәгънәләрнең беренчел нисбәтен саклау тәрҗемәдә еш кына мөмкин булмый.

Тәрҗемә проблемалары – нигездә текстны анализлау, аңлау һәм төзү проблемалары ул. Шунлыктан күп кенә тәрҗемә

белгечләренең текстны төп тәрҗемә берәмлеге итеп караулары очраклы түгел. Моның берничә сәбәбе бар:

1) текст мәгънәви бөтен тәшкил иткәнгә, аның аерым элементларының мәгънәсе дә үзара бәйләнгән һәм шул бөтенгә буйсынган. Шуңа күрә аерым хәбәрләмәләрне аңлау теге яки бу дәрәҗәдә текстның эчтәлегенә һәм текстта тоткан урыннарына бәйле була. Шул рәвешчә, текст чикләрендә барлык тел чараларының контекстуаль мәгънәсе турындагы мәсьәлә хәл ителә;

2) тәрҗемәдәге югалтуларны бәяләгәндә бөтеннең өлештән өстенрәк булу принцибы туры килә. Бу – текстның глобаль эчтәлеген уңышлы күчерү өчен бик үк әһәмиятле булмаган детальләрне корбан итәргә мөмкинлекне аңлата;

3) тәрҗемәченең ахыргы максаты – когезия һәм когерентлык таләпләренә җавап бирерлек текст оештыру.

Текстның тәрҗемәдә беренчел дәрәҗәдәге ролен истә тотып, теоретиклар текстларның тәрҗемәгә хас типологиясен эшләргә тырышалар, ул тәрҗемәченең гомуми стратегиясен, оригиналның аерым элементларын һәм функцияләрен төрле дәрәҗәдә күчерүне, тәрҗемәченең тәрҗемә текстын оештырудагы ролен чагылдырырга тиеш. Немец галиме К.Райс өч тип текстны аерырга тәкъдим итә.

I тип текстта тасвирлау функциясе, *II типта* – хис-кичерешләрне белдерү функциясе, *III типта* – өндәү функциясе өстенлек итә. Аудиомедиаль текстлар *IV тип* итеп күрсәтелә, алар телдән формада куллану өчен генә төзеләләр. Бу типология тәрҗемә бурычлары белән турыдан-туры бәйләнгән. Беренче тип текстлар, беренче чиратта, эчтәлеккә (коммерция, фәнни, эшлекле һ.б.) юнәлтелгән, аларны тәрҗемә иткәндә тәрҗемәченең максаты – әлеге эчтәлекне мөмкин кадәр тулырак бирү. Икенче тип текстлар формага (матур әдәбият) йөз тота, тәрҗемәченең бурычы оригиналның сәнгати-эстетик тәэсирен күчерүдән гыйбарәт була. Өченче тип текстлар мөрәҗәгатькә нигезләнә, шуңа күрә тәрҗемәдә дә тыңлаучыга яки укучыга мөрәҗәгать ачык бирелергә тиеш. Аудиомедиаль текстлар (радио, телетапшырулар, сәхнә әсәрләре) тагын да зуррак бөтеннең бер өлешен тәшкил итәләр, шуңа күрә тәрҗемәдә телдән тыш (техник) шартларга да игътибар итү мөһим.

Практикада исә оригинал тексты барлык типларның билгеләрен дә үз эченә алырга мөмкин, әмма шуларның берсе барыбер өстенлек итәчәк һәм шул тәрҗемә методын билгеләячәк.

Икенче бер немец галиме А.Нойберт текстларны башкача төркемли һәм нигез итеп прагматик ориентацияне ала.

I тип текстларда оригиналда да, тәрҗемәдә дә ихтыяҗга нигезләнгән гомуми максатлар була. Оригинал эчтәлеге чыганак телле аудиториягә генә юнәлтелми (фәнни-техник әдәбият, реклама һ.б.). Максатларның охшашлыгы хәбәр ителгән мәгълүматка карата тәрҗемә теле аудиториясендә дә шундый ук прагматик мөнәсәбәт туарга мөмкинлекне аңлата.

II тип мөнәсәбәтләр бары чыганак тел аудиториясенә генә багышланган текстларга (боерыклар, җирле мәгълүмат, күңел ачу материаллары һ.б.) хас. А.Нойберт фикеренчә, бу текстлар прагматик мөнәсәбәттә караганда гаять үзенчәлекле, шунлыктан алар бу мәгънәдә бөтенләй тәрҗемә итмиләр.

III тип – матур әдәбият. Гәрчә болар чыганак тел аудиториясе өчен туса да, гомумкешелек ихтыяҗларын да канәгатьләндерә ала. Шунлыктан алардагы прагматик мөнәсәбәтләр кайбер чикләүләр белән тәрҗемә ителә ала. Монда тәрҗемә ителү дәрәҗәсе жанрга бәйле: поэзия белән чагыштырганда, беллеристика һәм драмматургия югарырак дәрәҗәдә тәрҗемә ителә.

IV тип текстлар чыганак телдә төзелсәләр дә, тәрҗемәне күздә тоталар һәм башта ук тәрҗемә теле аудиториясенә багышланалар (чит илләрдә басылу өчен). Боларда прагматик тәрҗемә иң югары дәрәҗәдә күзәтелә.

Инде билгеләп үтелгәнчә, хәзерге тәрҗемә белемендә *текстоцентрик концепция* яши, аның буенча тәрҗемәче – беренче чиратта текстлар оештыручы. Текстлар ярдәмендә билгеле бер прагматик максатларга ирешелә. Бу концепция *скопос-теория* (скопос – максат) дип атала. Әлеге концепция буенча тәрҗемәнең уңышы куелган максатларга ирешү дәрәҗәсенә бәйле. Нindидер очракларда тәрҗемәнең максаты оригиналга максималь якын килү, икенчесендә билгеле бер мәгълүматны җиткерү, нәрсәгә дә булса ышандыру һ.б. булырга мөмкин. Монда инде тәрҗемәче гади арадашчы гына түгел, бәлки консультант, белгеч, аерым илнең телен, мәдәниятен,

икътисадын яхшы белүче һәм әлеге ил вәкилләре белән уңышлы килешүләр өчен кирәк булган текстлар төзергә сәләтле кеше.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, текст – тәрҗемәнең максаты, объекты һәм нәтиҗәсе. Шуңа күрә хәзерге тәрҗемә белемендә текстологик мәсьәләләргә аерым урын бирелә.

2.4. ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕНЕҢ КУЛЬТУРОЛОГИК ҺӘМ СОЦИОЛОГИК АСПЕКТЛАРЫ

“Тел һәм җәмгыять” проблемаларының төрле аспектларын өйрәнә торган *социолингвистика* да хәзерге тәрҗемә белеменең лингвистик базасын барлыкка китерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Бу проблемага бер-берсен тулыландыра биреп якын килгән ике алым тәрҗемә теориясендә аеруча мөһим урын тота. Бер яктан, тел билгеле бер этносны аерым мәдәнияткә ия халык буларак характерлый торган бербөтен социаль-мәдәни бердәмлек итеп карала. Икенче яктан, телдә иҗтимагый тормышның төрле һәм күпкырлы булуы, бер мәдәният эчендәге кешеләрнең иҗтимагый, һөнәри һ.б. яклардан аерылуына бәйле вариантлылык төрләре өйрәнелә.

Тел һәм мәдәният мөнәсәбәтләре элек-электән тел белгечләрен үзенә җәлеп иткән. Әмма соңгы унъеллыкта “мәдәният” төшенчәсе киңрәк аңлатыла, шәрехләнә башлады. Мәдәниятне цивилизациянең матди һәм рухи казанышлары җыелмасы буларак карауга алмашка бу терминны киңәйтеп аңлату килә. Аңа билгеле бер этноска хас тарихи, иҗтимагый һәм психологик күренешләр, гореф-гадәтләр, кыйммәтләр, карашлар, институтлар, халыкның үз-үзен тотышы, тормыш шартлары, көнкүреше – гомумән, аның яшәешендәге һәм аңындагы барлык яклар кертелә. Мәдәниятне шул рәвешчә аңлау, кешелек яшәешенең төп шарты буларак, телне һәм вербаль коммуникациянең башка аспектларын мәдәният эчендә карау зарурлыгы тудыра.

“Мәдәният” төшенчәсенең яңа трактовкасы теоретик планда алга таба ике юнәлештә үстерелә:

1) кеше турында глобаль фәннең мөһим өлеше буларак “культурология” дигән яңа фән формалаша башлый;

2) традицион “тел һәм мәдәният” проблемасы яңа эчтәлек һәм масштаб ала.

Вербаль коммуникация коралы булган тел мәдәниятнең мөһим өлешен тәшкил итә, аның төзелешендәге һәм яшәешендәге барлык үзенчәлекләр тел (этник) коллективы мәдәниятенең чагылышы итеп санала ала. Әмма телнең башка мәдәни элементлар белән катлаулы бәйләнештә булуын да истә тотарга кирәк. Әйләнә-тирә, рухи тормыш һәм кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары кеше аңында билгеле бер когнитив төзелмәләрдә чагылыш таба, алар үз чиратында тел категорияләрендә һәм формаларында реальләшә.

Когнитив чараларның, аеруча тел төзелмәләренең формалашуы һәм үсүе тышкы факторлар (башка мәдәни элементлар) тәэсире астында гына түгел, тел системаларын бербөтен итеп яшәргә мөмкинлек биргән эчке законнар нигезендә дә бара.

Тел коллективының мәдәниятенә турыдан-туры яки читләтеп бәйләнгән тел үзенчәлекләре тәрҗемәчелек эшчәнлегенең закончалыкларын тикшерү өчен аеруча кызыклы. Мондый үзенчәлекләр тел төзелешенең төрле дәрәҗәләрендә, вербаль аралашу кагыйдәләрендә, телдән тыш яши торган чынбарлыкны тасвирлау ысулларында да күзәтелә.

Социаль-мәдәни детерминация телнең сүзлек составында ачык чагылыш таба. Монда билгеле бер эшчәнлек өлкәсендәге атамалар саны, бу өлкәнең иҗтимагый әһәмиятлелек дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйле булуы турында гына сүз бармый. Гадәттә, мондый очракка мисал итеп эскимослардагы кар атамаларын китерәләр. Әмма билгеле бер мәдәният вәкилләренең тел берәмлекләре мәгънәсендә һәм кулланылышында әйләнә-тирәне үзенчәлекле кабул итүне чагылдыру фактлары да зур кызыксыну уята.

Социаль-мәдәни факторлар аралашучыларның фон белемнәре формалашуда да мөһим роль уйный. Билгеле бер мәдәният вәкилләренең тормыш шартларын һәм гореф-гадәтләрен чагылдыра торган хәбәрләр тәрҗемә теориясе һәм практикасы өчен аеруча кызыклы.

Вербаль коммуникациянең мәдәнияткә бәйлелеген өйрәнү тәрҗемә белеме өчен дә мөһим, чөнки тәрҗемәчелек ике

телнең үзара тәэсирен генә түгел, бәлки ике мәдәният арасындагы багланышларны да аңлата. Һәр аерым мәдәнияткә хас уникаль үзенчәлекләр белән беррәттән, күп мәдәниятләр өчен уртак факторлар да була. Моннан тыш, төрле мәдәниятләр һәрвакыт бер-берсенә тәэсир итеп тора. Реаль чынбарлык мәдәниятләрнең аерымлыгы һәм үзара үтеп керә алмаулары турындагы фикерне инкар итә. Кайбер лингвистлар, этнографлар, фәлсәфәчеләр һ.б. мәдәният эшлекләре төрле мәдәниятләр арасында тулы кыйммәтле контакт булу ихтималына шикләнеп карый.

Тел белемендә *"Сепир-Уорф гипотезасы"* дигән концепция билгеле. Бу концепция нигезендә "тел структурасы фикерләү структурасын һәм тышкы дөньяны танып-белү ысулын билгели" дигән күзаллау ята. Анынча чынбарлыкны танып-белү характеры субъект фикер йөртә торган телгә бәйле. Кешеләр дөньяны кисәкләргә тарката, аны төшенчәләр ярдәмендә оештыра һәм мәгънәләрне билгели. Танып-белүгә объектив, гомумкешелек характеры хас түгел: фикерләүдәге тел көчләп таккан төрлелекләр аркасында охшаш күренешләр төрле сурәт-картиналарга туплана. Моннан төрле мәдәният вәкилләренең, төрле телләрдә сөйләшүчеләрнең бер-берсен тулысынча аңлаулары мөмкин түгеллек килеп чыга: телләр төрле мәдәният кешеләренең фикерләве арасында үтеп булмаслык киртә тудыра.

Инде алда әйтелгәнчә, һәр тел үзенең "дөнья сурәтен (картинасын)" тудыра, бу тәрҗемәдә кыенлыклар барлыкка килүгә сәбәп була. Телнең төзелеше, чыннан да, хәбәрләр оештыруның мөмкин булган ысулларын билгели, вакыты белән сөйләүчегә теге яки бу формаларны кулланырга мәҗбүр итә. Әмма шунысы да дөрес: хәбәрләмәнең тел формасы аның эчтәлеген билгели алмый, ул бары тик аның глобаль эчтәлеген аңлауда нигез хезмәтен генә үти. Бер үк мәгънә күп төрле тел төзелмәләреннән килеп чыгарга, яки киресенчә, бер үк төзелмә төрле хәбәрләмәләрне оештыру һәм аңлау нигезе булырга мөмкин. Шулай итеп, фикерләр һәм аларның телдә белдерелү ысуллары арасындагы бәйләнеш чагыштырмача һәм чикләнгән була. Сөйләүче хәбәрләмәнең формасы белән эшнең асылы арасындагы аерманы тоя, тел көчләп таккан стереотиплардан

котыла ала. Әгәр дә татар кешесе “Кояш чыга һәм бата” дип сөйли икән, ул әле Коперник белән килешми, Кояш Җир тирәли әйләнә дип уйлый дигән сүз түгел. Ул моның киресе булуын белергә мөмкин, әмма бу фикерне белдерү ысулы дөнья төзелеше турындагы әллә кайчангы күзаллауларны чагылдыруы ихтимал. Тик ул хәзерге кешенең фикерләү сәләтен билгеләми.

Тел киртәләре мәдәниятара багланышларга да комачауламый. Бер мәдәният вәкиле үз илендә дә, аннан читтә дә икенче мәдәният турында язмача яки телдән (турыдан-туры аралашу, әдәбият, телевидение, вакытлы матбугат һ.б. чыганаклардан) күп төрле мәгълүмат ала. Хәзерге заманда киң таралган чыганакларның берсе – тәрҗемә. Мәдәни кыйммәтләрнең, гореф-гадәтләрнең үзенчәлеген һәм күптөрлелеген чагылдырган хәлдә, тәрҗемәләр халыкларның үзара аңлашуына ярдәм итәләр, һәр халыкның телен, әдәбиятын, фән-техникасын баетуга өлеш кертәләр. Күп кенә милли телләрнең тәрҗемә тәэсире йогынтысында (бигрәк тә антик телләрдән) формалашуы мәгълүм.

Төрле мәдәниятләрнең билгеле бер үсеш этапларында тәрҗемәгә куелган таләпләре дә аерыла. Бу таләпләр тәрҗемә текстларын сайлауга гына түгел, тәрҗемәченең тиешле стратегия белән эш итүенә дә кагыла. Мәсәлән, дини текстларны тәрҗемә итүчеләр букваль тәрҗемәгә йөз тотып, тел нормалары сакланмауга һәм эчтәлек бозылуга игътибар итмәгәннәр. Матур әдәбиятны тәрҗемә итүчеләр, киресенчә, оригиналдан ирекле файдаланганнар. Күренекле рус тәрҗемәчеләре Карамзин һәм Жуковский ирекле тәрҗемәнең гаҗәеп үрнәкләрен барлыкка китерсәләр, Вяземский, Гнедич һәм Фет хәрефкә-хәреф тәрҗемә яклы булалар.

Тәрҗемә әдәби жанры артта калган яки зур үсешкә ия булмаган мәдәнияткә караса, тәрҗемәчеләр оригиналның жанр үзенчәлекләрен җентекләбрәк саклыйлар. Киресенчә, билгеле бер жанр кабул итүче мәдәнияттә нык үскән булса, тәрҗемәләр жанрның бу мәдәнияткә караган таләпләрен саклыйлар.

Тәрҗемәче стратегиясенә социаль-мәдәни тәэсир еш кына тәрҗемәдә оригинал эчтәлеген чагылдыруның тулылыгында да чагыла. Әгәр оригиналдагы ниндидер өлешләр кабул итүче мәдәнияттә идеологик, әхлакый һәм эстетик яктан

рөхсәт ителми икән, алар кыскартыла яки бөтенләй төшереп калдырыла.

Бердәм мәдәният һәм бер тел булу гына мәдәни-тел коллективының бертөрле булуын аңлатмый әле. Теләсә кайсы җәмгыятькә күпсанлы җирле, иҗтимагый, һөнәри, яшь буенча һ.б. аермалар хас, алар төрле төркемнәрнең тел чараларын куллану үзенчәлекләрендә чагылыш табалар. Моннан тыш, бер үк кешеләр дә төрле ситуацияләрдә телдән төрлечә файдаланалар. Телнең мондый вариантлылыгы социолингвистиканың тикшеренү өлкәсенә карый, хәзерге тәрҗемә белеме дә бу фән мәгълүматларыннан иркен файдалана.

Тел чараларын куллануда гы аермалар иң элек бер үк телдә сөйләшүчеләрнең төрле җирләрдә яшәве белән бәйле. Әгәр тел берничә илдә кулланыла икән, аның һәркайсында берникадәр аерма барлыкка килә. Нәтиҗәдә, телнең милли вариантлары пәйда була. Мәсәлән, инглиз теленең британ, Америка һәм Австралия вариантлары бар. Бер үк ил эчендә дә телнең җирле вариантлары туа, алар арасында аерма әллә ни сизелмәслек тә, кискен дә булырга мөмкин, хәтта җирле диалектлар белән әдәби тел арасында аермалар аерым тел дәрәҗәсендә дә була ала. Кайбер илләрдә диалектлар арасындагы аермалар вакытлар үтү белән югала, ә кайберләрендә тотрыклылыгын саклый.

Тәрҗемә теориясендә җирле диалектларга тәрҗемәче өчен китереп чыгарган проблемалар ягыннан игътибар ителә. Оригиналда диалект формаларының кулланылышы ике төрле характерда була. Бер яктан, диалект телнең аерым төрен тәшкил итә һәм чыганак тел функциясен үти. Бу проблема тәрҗемәдә зур кыенлык тудырмый, монда тәрҗемәченең әлеге диалектны белүе җитә һәм ул оригиналны башка телләрдән тәрҗемә иткән кебек үк башкара. Икенче яктан, диалекталь формалар персонажның тел үзенчәлекләрен чагылдыру өчен кулланыла. Бу очракта исә эш катлаулырак: тәрҗемәче текстта сөйләүче файдаланган җирле үзенчәлекләр турында өстәмә мәгълүматка ия булырга тиеш. Күп вакыт бу максатларда тәрҗемә телендәге шундый ук диалекталь формалар белән эш итү мөмкин түгел, чөнки алар бөтенләй башка төркем кешеләрнең тел үзенчәлеген чагылдырачак.

Бу мәсьәләне хәл итү иҗтимагый диалектлар булу белән өлешчә җиңеләя. Тел коллективындагы кешеләрнең сөйләме төрле җирләрдә яшәүләре белән генә түгел, аларның җәмгыятьтә төрле иҗтимагый катламнарга керүләре белән дә аерыла. Төрле илләрдә тел үзенчәлекләре белән туры килми торган иҗтимагый катламнар төрлечә булырга мөмкин. Әдәби тел нормалары белән сөйләшүче кешеләр һәм "белемсез, надан" кешеләр сөйләмендәге аермалар барлык телләрдә дә күзәтелә, шуңа күрә аларны тәрҗемәдә чагылдыру җиңелрәк.

Тәрҗемә практикасы өчен иҗтимагый һәм җирле диалектлар арасында еш кына тыгыз бәйләнеш булуын да белү мөһим. Җирле аермалар күбесенчә белем дәрәҗәсе түбән кешеләр арасында күзәтелә һәм белем алу барышында алар кими. Аерым диалект географик яктан да, иҗтимагый хәле белән дә аерымланырга, ягъни бер үк вакытта җирле һәм иҗтимагый диалект булырга мөмкин. Шул рәвешчә, җирле диалект формалары биргән өстәмә мәгълүматны "белем дәрәҗәсе түбән" кешеләр сөйләмендәге чаралар белән бирү мөмкинлеге туа.

Төрле илләрдәге иҗтимагый катламнарга бүленешнең, димәк, телдәге шундый ук катламнарның аермалы булуын тәрҗемәдә чагылдыру да кыенлыклар китереп чыгара. Мондый очракларда тәрҗемәдә эквивалентлык төрле тип сөйләмнәр арасында урнаштырыла. Иң әһәмиятлесе: сөйләм формаларындагы аермаларның тиешле иҗтимагый статуста булуы. Ни генә булса да, тәрҗемәче ике телнең дә тәрҗемәдә кулланылган диалектларын яхшы белергә, аларның үзенчәлекләрен чагыштыра алырга тиеш.

Телдә төрле профессия, һөнәр ияләре вәкилләренең сөйләмендәге үзенчәлекләрне чагылдыра торган тагын бер диалект булу тәрҗемәдә зур кыенлыклар тудырмый. Мисал өчен, моряклар, солдатлар, студентлар һ.б.ш. сөйләме дә һәртөрле үзенчәлекләргә (бигрәк тә лексикада) ия булырга мөмкин. Болар телдә *һөнәри диалектлар* (жаргоннар) барлыкка китерә. Күп очракта төп һөнәри төркемнәр төрле мәдәниятләрдә дә очрый һәм тәрҗемәдә тиешле һөнәри диалект формасын куллану мөмкинлеге була.

Тел чараларының вариантлылыгы телнең җирле, иҗтимагый, һөнәри катламнары булу белән генә чикләнми.

Телдә билгеле бер аралашу өлкәсендә күбрәк кулланыла торган тел чаралары җыелмасын тәшкил иткән *функциональ стильләр* аерылып тора. Гәрчә телләрдәге функциональ стильләр саны туры килмәсә дә, аларның чикләре күзгә ташланып тормаса да, күпчелек телләрдә түбәндәге функциональ төрләр шактый ачык аерыла: матур әдәбият стиле (проза һәм поэзия стиле), публицистик стиль, фәнни стиль (фәнни-техник һәм фәнни-гуманитар стильләр җыелмасы), эшлекле рәсми стиль (рәсми-эш документлары җыелмасы), мәгълүмати-газета стиле, сөйләм стиле һ.б. Һәр функциональ стильдә башка стильләрдә дә очрый торган тел чаралары файдаланыла, әмма шушы стильдә күбрәк кулланылган тел чаралары җыелмасы да була. Функциональ стиль чигендә текстларның аерым жанрлары һәм типлары билгеләнә. Мәсәлән, фәнни стильдә – монография, фәнни мәкалә, лекция, доклад чыгыш, хәбәр һ.б.ш. Жанрлар шулай ук кискен аерылмаса да, аларның доминантасын билгеләп була.

Төрле функциональ стильләр бер-берсенә тәэсир итү һәм үтеп керү сәләтенә ия. Стильләрне чагыштыру алар арасында контраст билгеләрне дә, шул ук вакытта берничә функциональ стильдә очрый торганнары да булуны күрсәтә. Мәсәлән, катлаулы синтаксик төзелмәләр рәсми-эш стилендә генә түгел, фәнни текстларда да очрый; эмоциональ лексика аз булу фәнни прозада гына түгел, мәгълүмати-газета материалларында да күзәтелә; фәнни текстның үзенчәлекле билгесе булган логик сөйләү рәвеше күп кенә матур әдәбият текстларына да хас һ.б.

Функциональ стильләрнең лингвистик классификациясе тәрҗемә белеме өчен дә әһәмиятле. Шул нигездә тәрҗемә белемендә тәрҗемә аерым төрләргә бүленә: *матур әдәбият тәрҗемәсе* һәм *прагматик (мәгълүмати) тәрҗемә*. Бу капма-каршы куелыш әлеге хезмәтләр тәрҗемәсе алдына куелган төп бурычларның төрле булуына нигезләнә. Матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә иткәндә тәрҗемәченең бурычы оригиналның сәнгати-эстетик казанышларын бирүдән, тәрҗемә телендә тулы кыйммәтле матур әдәбият әсәре тудырудан гыйбарәт. Матур әдәбият тәрҗемәләре әдәбиятның бер өлешен тәшкил итә. Сәнгатьлелеккә ирешү өчен, тәрҗемәче вакыты белән оригинал эчтәлеген бирүдә максималь төгәллектән баш тартырга да мөмкин. Мәгълүмати тәрҗемәдә, киресенчә, төп игътибар

үзәгендә чыганак тексттагы мәгълүмат һәм тәрҗемәче аны мөмкин кадәр тулы итеп бирергә омтыла. Тәрҗемәнең алга таба төрләргә бүленеше матур әдәбият тәрҗемәсендә әдәби жанрлар буенча, ә мәгълүмати тәрҗемәдә – аерым функциональ стильләр буенча башкарыла.

Тәрҗемәне жанрлы-стилистик төркемләү тәрҗемәдә ике тел кулланылу белән бәйле һәм һәркайсының үзенчәлеген чагылдыра. Оригиналның нинди дә булса функциональ стильгә каравы аның тәрҗемәдә бирелергә тиешле өстенлекле функциясен ачыклый һәм тәрҗемәдә дә функциональ стиль сайлауны билгели. Тәрҗемәдә сайланган стиль тәрҗемә теле нормаларын һәм үзенчәлекләрен саклауны таләп итә, әмма ул теге яки бу дәрәҗәдә оригиналдагы шундый ук стиль нормалары белән туры килмәскә дә мөмкин. Ике телдә билгеле бер стильләрдә тел характеристикасы туры килмәгән вакытта тәрҗемә жанрларын билгеләү аеруча әһәмиятле. Бу очракта тәрҗемә стилистик яктан берникадәр җайлаштырыла.

Тел чараларын сайлау шулай ук аралашу ситуациясенә һәм катнашучыларның роленә дә бәйле. Төрле ситуацияләрдә кешеләр төрлечә сөйләшә. Докладчының чыгышы урамда таныш булмаган кеше белән яисә туганнар белән сөйләшүдән аерыла. Сөйләмнең мондый төрләрен гадәттә *регистр* дип йөртәләр. Аралашу ситуацияләре гаҗәеп күп төрле һәм регистрлар да төрлечә төркемләнә. Еш кына тантаналы, рәсми, дустанә һәм интим регистрларны аералар. Тәрҗемә вариантын сайлаганда тәрҗемәче аралашуның кайсы регистрда баруына да игътибар итәргә тиеш.

Тәрҗемә белеме өчен билингвизм проблемаларын өйрәнүгә багышланган лингвистик тикшеренүләр дә кызыксыну уята (*билингвизм* – кешенең ике тел системасыннан файдалануы һәм бу системаларның кеше сөйләмендә үзара тәэсир итешүе). Тел контактлары теориясе билингвизмның ике телне дә камил белүдән алып кеше икенче телне яңа үзләштерә башлаган ситуациягә кадәр төрләрен өйрәнә. Телдән коммуникация процессында телләрнең төрлечә тәэсир итешүләре тасвирланган. Бер яктан, ике телнең коммуникатив тигез очрагы була, алар икесе дә иҗтимагый әһәмиятле һәм һәр кеше тарафыннан нәтиҗәле файдаланыла. Икенче яктан, бер тел икенчесенә

караганда мөһимрәк, әһәмиятлерәк һәм дәрәҗәлерәк булып, кешенең төп аралашу чарасын тәшкил итә.

Ике тел бер-берсеннән аерым яшәргә мөмкин: кеше аларның икесеннән дә иркен файдалана, ике тел берәмлекләре арасында бәйләнеш урнаштыра алмый, аларда тәңгәллекләрне авыр таба. Киресенчә, катнаш икетеллелек булганда, кеше бер телдә сөйләшкәндә урынлы итеп икенче тел сүзләрен һәм гыйбарәләрен кертеп җибәрә.

Билингвизм проблемалары тәрҗемәчелеккә турыдан-туры йогынты ясый. Тәрҗемәче үзе дә икетелле кеше (матур әдәбият тәрҗемәсендә, телне белмичә, юлга-юл тәрҗемә белән эшләүчеләр искәрмәгә керә: андыйларга башта кемдер юлга-юл тәрҗемә ясый, аннары, тәрҗемә теленә һәм жанр таләпләренә туры китереп, тәрҗемә телендә поэтик әсәр тексты төзелә). Ике телне белү тәрҗемә эшчәнлегенә мөмкинлек тудыра һәм күп очракта ул үзе үк чит тел хәбәрен икенче телгә теге яки бу дәрәҗәдә тулы итеп күчерү осталыгын күздә тота. Әмма тәрҗемәченең профессиональ компетенциясе телләрне белүгә генә кайтып калмый. Кайчак телләр белгән кешеләр хәтта таныш темага язылган текстларны да тәрҗемә итә алмый. Тагын шунысы бар: “табигый тәрҗемә” профессиональ тәрҗемә таләпләренә җавап бирмәскә мөмкин.

Телара интерференция проблемасы да тәрҗемәдә һәрьяклап өйрәнелә. Кеше аңында бер телнең икенче телдән өстенлеге нәтиҗәсендә доминанта тел (гадәттә ул кешенең туган теле була) кешенең икенче телдәге сөйләмендә берникадәр үзгәрешләр барлыкка китерә. Кеше ихтыярсыздан үз теленең кайбер үзенчәлекләрен икенче телгә дә кертеп җибәрә. Мондый тел интерференциясе - чит телне өйрәнүдәге киртәләрнең берсе, ул туган теле булмаган телдә сөйләшүчеләрнең күпчелегенә хас акцент тудыра. Ул, гадәттә, нормага җавап бирми һәм уңышлы аралашуга комачаулык ясый торган тискәре күренеш буларак бәяләнә.

Тәрҗемә теориясендә интерференция проблемаларына аерым игътибар ителә. Тәрҗемәдә ике телнең даими контактта торуы чит тел тәэсирендә тәрҗемә теленә үзгәрешләр керүгә сәбәп була. Бик үк тәҗрибәле һәм белеме җитәрлек булмаган тәрҗемәчеләр, вакыты белән тәрҗемәдә тел нормаларын һәм

узусын бозып, үзенчәлекле “тәрҗемә теле” барлыкка китерәләр. Шул ук вакытта тәрҗемәче аңлы рәвештә кайбер техник алымнар (транскрипция, калькалаштыру һ.б) кулланып, оригинал теле формаларын һәм төзелмәләрен туган теленә күчереп куя. Оригинал берәмлекләре тәэсирендә тәрҗемә теле берәмлекләренең мәгънәләре киңәергә мөмкин. Шул ук вакытта төп нөсхәнең эчтәлеген төгәлрәк күчерергә тырышу нәтиҗәсендә, еш кына тәрҗемә телендәге аерым берәмлекләрнең кулланылу ешлыгы да үзгәрә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тәрҗемә белеме өчен социолингвистика проблемалары да ят түгел. Бу өлкәдә алып барылган тикшеренүләр тәрҗемә эшчәнлегенең күп кенә якларын өйрәнү өчен кыйммәтле мәгълүмат бирәләр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен тәрҗемәне төрле фәннәр өйрәнә?

2. Тәрҗемә тел белеменең тикшеренү өлкәсенә кайчан һәм ни сәбәпле кертеп карала башлый?

3. Лингвистикадагы структурализмны ничек аңлыйсыз?

4. Машина тәрҗемәсе нәрсә ул һәм аны кайсы очракларда кулланырга мөмкин?

5. Тәрҗемә белән телләр күптөрлелеге арасындагы бәйләнешне нигезләп аңлатыгыз.

6. Телләрнең үзенчәлекләре тәрҗемәдә нинди кыенлыклар тудырырга мөмкин?

7. Тел факторларының тәрҗемә проблемаларын хәл иткәндә ярдәме бармы?

8. Н.Хомски һәм Д.Бикертон гипотезаларын тасвирлап бирегез.

9. Тәрҗемәдә кулланырга мөмкин булган нинди лингвистик методларны саный аласыз? Аларны нинди максатларда файдаланырга мөмкин?

10. Тел тамгаларының төп семиотик сыйфатларын искә төшерегез.

11. “Тәрҗемә ителмәү” теориясен ничек аңлыйсыз? Үз фикерләрегез ярдәмендә бу теориянең урынсыз булуын исбатлагыз.

12. Телара коммуникация ничек бара?

13. Чын тәрҗемә адаптив транскодлаштырудан ничек аерыла?

14. Текстның эчтәлеген нинди үлчәмнәрдә карап була?

15. Текстның тел эчтәлеге нидән гыйбарәт?

16. Текстның глобаль эчтәлеге нәрсәдән килеп чыга?

17. Тәрҗемәче текстның тел эчтәлеген күчерү белән чикләнергә тиешме, әллә тулаем (глобаль) эчтәлекне бирү дә аның бурычына керәме?

18. Күпчелек галимнәр ни сәбәпле текстны төп тәрҗемә берәмлеге итеп карый?

19. Тәрҗемә белемендәге текст типологиясе нидән гыйбарәт?

20. Текстоцентрик (скопос-теория) концепциянең асылын аңлатыгыз.

Бүлек буенча өстәмә әдәбият

Комиссаров В.Н. Современное переводоведение. – М.: ЭТС, 2002.

Латышев Л.К. Технология перевода. – М.: Издат.центр “Академия”, 2005.

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. – Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшр., 1993.

Солодуб Ю.П., Альбрехт и др. Теория и практика художественного перевода. – М.: Издат.центр “Академия”, 2005.

Соссюр Ф. Курс общей лингвистики. – М., 1977.

Тхорик В.И, Фанян Н.Ю. Лингвокультурология и межкультурная коммуникация. – М.: ГИС, 2006.

III бүлек.
ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫНЫҢ ТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ

3.1. ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮНЕ ОЕШТЫРУНЫҢ ГОМУМИ ПРИНЦИПЛАРЫ

Тәрҗемә кеше эшчәнлегенең бик борынгы төре булса да, күпсанлы профессиональ тәрҗемәчеләр хәзерләүгә ихтыяҗ күптән түгел генә барлыкка килде. Тәрҗемәчеләрдән башка төрле телле кабилә һәм халыкларның аралашуы, күпсанлы һәм күптелле халыкларны берләштергән дәүләт һәм империяләрнең яшәве, иҗтимагый дәрәҗәгә ия хаким милләтләрнең мәдәнияте раслану, дини һәм иҗтимагый тәгълиматларның таралуы мөмкин булмас иде. Шуңа карамастан, билгеле бер вакытка кадәр илдә тәрҗемәчеләрнең саны чагыштырмача күп булмаган, алар гадәттә нинди дә булса махсус белем дә алмаганнар. Элеккеге аерым тәрҗемәчеләр шактый югары профессиональ дәрәҗәдә эшләсәләр дә, кайбер талантлылары вакыт-вакыт тәрҗемә шедеврлары иҗат итсәләр дә, гомумән алганда, күпчелек тәрҗемәләрнең сыйфаты бик үк яхшы булмаган. Кагыйдә буларак, тәрҗемәләрнең югары дәрәҗәдәге төгәллеге таләп тә ителмәгән, тәрҗемә башбаштаклыгы кайчак акланган һәм хәтта макталган, тәрҗемәчегә һөнәри таләпләр гомуми рәвештә генә формалаштырылган.

Бу хәлләр XX гасырның икенче яртысында тамырдан үзгәрә башлый. Дөньяда “мәгълүмати шартлау” булганнан соң, кешеләр һәм халыклар алмаша торган мәгълүматның күләме кискен арта. Халыкара багланышлар үсә, дөнья картасында яңа дәүләтләр пәйда була, күпсанлы халыкара оешмалар, дөньякүләм хәрәкәтләр, дәүләтләрнең төбәк союзлары барлыкка килә. Фәнни-техник революция төрле илләр арасында фәнни мәгълүмат алмашуга зур ихтыяҗ тудыра. Халыкара сәүдә күләме, дипломатик эшчәнлек, халыкара хат алышу-язышу бик нык арта. Халыклар арасында мәдәни багланышлар киңәя, халыкара туризм массакүләм характер ала.

Кешелек тормышындагы әлеге үзгәрешләр тәрҗемәгә һәм тәрҗемәчеләргә моңарчы күрелмәгән сорау тудыра.

Тәрҗемәче профессиясе массакүләм төс ала һәм югары квалификацияле тәрҗемәчеләргә ихтыяҗ арта. Мондый тәрҗемәчеләрне максатчан һәм планлы рәвештә хәзерләргә кирәк була, шуңа күрә күп кенә илләрдә профессиональ тәрҗемәчеләрне укыту максатын куйган төрле уку йортлары барлыкка килә.

Әмма тәрҗемәчеләрне укытуга керешкәнче өч сорауга җавап бирү мөһим:

- тәрҗемәгә ни өчен өйрәтергә?
- нәрсәгә өйрәтергә?
- ничек өйрәтергә?

Беренче сорау бер карашка мәгънәсез кебек тоела, чөнки тәрҗемәчеләрне хәзерләү таләбе җәмгыятьнең яңа ихтыяҗларына җавап бирә торган мөһим иҗтимагый бурычка әверелә. Әмма эш шунда, тәрҗемә итәргә өйрәтү зарурлыгына һәм мөмкинлегенә ике позициянең фикерләре каршы куела. Бер яктан, тәрҗемә итү өчен ике телне һәм тәрҗемә ителә торган тексттагы предметны белү җитә дип белдерелә. Димәк, телләрне өйрәнеп һәм төрле өлкәләр буенча белемнәр туплап, кеше тәрҗемә итәргә дә өйрәнә. Чыннан да, чит телгә өйрәтүнең беренче этапларында укытучы укучыларга чит телгә яки туган телгә аерым фразалар, тексттан өзекләр тәрҗемә итәргә куша һәм, гәрчә аларны махсус рәвештә беркем тәрҗемә итәргә өйрәтмәсә дә, укучылар моны эшли ала. Шул рәвешчә, тәрҗемәгә өйрәтүгә каршы фикернең берсе түбәндәгедән гыйбарәт: тәрҗемә күнекмәләре (“табигый тәрҗемә”) телләр өйрәнү барышында һәркемдә барлыкка килә һәм чит тел белгән һәркем тәрҗемәче була ала.

Икенче яктан, моңа капма-каршы фикер яши: тәрҗемәгә өйрәтеп булмый, чөнки тәрҗемә итү – музыкаль яки иҗади сәләт кебек, табигый сәләт, шуңа күрә тәрҗемәче булып туарга кирәк. Табигый талантың булса – тәрҗемәче була аласың, талантың булмаса, беркем дә сине яхшы тәрҗемә итәргә өйрәтә алмый.

Бу ике фикер теоретик күзаллаулар белән дә, тәрҗемә практикасы белән дә кире кагыла. Һичшиксез, “табигый” тәрҗемә бар һәм чит телне белгән кешеләр, тәрҗемәгә махсус өйрәнмәсәләр дә, чит телдәге текст эчтәлеген башкаларга тапшыра алалар. Кайберәүләрнең “табигый” тәрҗемә сәләте

шулкадәр үскән була ки, алар профессиональ дәрәҗәдә тәрҗемә итә ала. Тик күпчелек очракта “табигый” тәрҗемә чын профессиональ тәрҗемәнең алшарты гына булырга мөмкин. Ни дисәң дә, табигый тәрҗемә – тәрҗемә таләпләренә җавап бирми торган, бик үк төгәл булмаган тәрҗемә. Аерым очраклардан кала, профессиональ тәрҗемәгә куелган таләпләрне канәгатьләндерү өчен телләрне һәм предметны белү генә җитеп бетми.

Мәгълүм булганча, академик Л.В.Щерба “чиста” һәм “катнаш” икетеллелекне аерырга тәкъдим итә. Чиста икетеллелек вакытында ике тел системасы кеше аңында бер-берсенә бәйсез рәвештә барлыкка килә һәм яши, алар бер-берсенә бернинди дә тәэсир ясамый. Кеше бу ике телнең һәркайсыннан иркен файдалана, бер тел берәмлегенә туры килгән икенче тел берәмлеген эзләүдә кыенлык кичерми. Л.В.Щерба, мондый икетеллелек чит телне яшьтән “гувернантка методы” белән өйрәнгәндә барлыкка килә дип уйлый (берәү бала белән чит телдә генә аралаша, ә башкалар туган телендә сөйләшә).

“Катнаш” икетеллелек исә чит телне берникадәр соңрак, кешенең үз туган телендә төшенчәләр системасы формалашкач өйрәнгәндә туа. Бу вакытта чит тел берәмлекләре туган тел берәмлекләре аша үзләштерелә һәм кеше аңында алар белән чагыштырыла. Мондый икетеллелеккә ия кешеләр ике тел берәмлекләре арасында тәңгәллекләрне җиңел таба, бер телдәге сөйләмгә икенче тел сүзләрен һәм гыйбарәләрен җиңел кертеп җибәрә. Мөгаен, табигый тәрҗемә таланты нәкъ менә шундый икетеллелеккә нигезләнәдер.

“Табигый” тәрҗемәгә сәләт элек-электән мәгълүм һәм чит телгә өйрәткәндә иркен файдаланыла. Чит тел хәбәрләрен аңлау дәрәҗәсен тикшергәндә, өйрәнелгән тел берәмлекләрен һәм төзелмәләрен куллану күнегүләре сыйфатында, укучыларга тәрҗемә күнегүләре бирелә. Мондый уку-укыту күнегүләрендә тәрҗемә итү өчен билгеле бер тел белемнәренә ия булу җитә һәм тәрҗемәгә махсус өйрәтергә кирәк түгел дип санала. Нинди дә булса чит телне белгән кеше әлеге телне белмәгән кешегә ярдәм иткәндә, арадашчы ролен үтәгәндә, көндәлек ситуацияләрдә “табигый” тәрҗемә уңышлы файдаланыла.

Билгеле, дәрестәге уку-укыту тәрҗемәсе дә, көндәлек тәрҗемә дә махсус хәзерлек таләп итми һәм тәрҗемәчелеккә өйрәтү белән шөгыльләнә торган махсус уку дисциплинасы булуны күздә тотмый. Әлеге фән барлыкка килү профессиональ тәрҗемә эшчәнлегендә XX гасырның икенче яртысында пәйда булган кайбер үзенчәлекләр белән бәйле. Бу чорда тәрҗемәче эшенең сыйфатына таләпләр шактый арта. Профессиональ дәрәҗәдә эшләнгән тәрҗемәләр нигезендә җаваплы хөкүмәт карарлары кабул ителә, катлаулы техник операцияләр башкарыла, күпмиллионлык контрактлар төзелә. Тәрҗемәченең кечкенә генә хатасы да җитди сәяси конфликтларга, техник аварияләргә яки зур финанс чыгымнарына китерү куркынычы була.

Әдәби тәрҗемәләргә дә таләпләр күтәрелә. Әдәбиятчы-тәрҗемәчеләрнең законлаштырылган үзиреклелеге (тәрҗемә иткәндә кешеләрнең исемен, вакыйгаларның урынын үзгәртү, авторны "төзәтү һәм яхшырту", текстка өзекләр өстәп язу һ.б.) үткәндә кала. Тәрҗемәчедән оригинал эчтәлеген һәм авторның индивидуаль стилен адекват күчерүне таләп итә башлыйлар.

Аерым очракларны исәпкә алмаганда, югары сыйфатлы профессиональ тәрҗемә башкару өчен "табигый" тәрҗемәгә сәләтнең җитәрлек булмавы ачыклана. Ике телне яхшы белгән күп кенә кешеләр хәтта үзләренә таныш өлкәләрдә дә югары квалификацияле тәрҗемәче сыйфатында эшли алмыйлар. Шулай итеп, тәрҗемәчеләрне махсус хәзерләргә кирәклеге исбат ителә.

Шулай да, тәрҗемә итәргә өйрәтеп буламы соң?

Чит телне өйрәнгәндә үзеннән-үзе барлыкка килгән "табигый" тәрҗемә сәләте кебек, профессиональ тәрҗемә итү таланты да тумыштан килмиме икән? Юкка гына тәрҗемәче таланты һәм тәрҗемә сәнгате турында сөйләмиләрдер. Яхшы тәрҗемәче булып туарга кирәктер, бәлки?

Тәрҗемә сөйләм-фикер йөртү эшчәнлегенең иң катлаулы төрләреннән санала, ул үзенчәлекле белем-күнекмәләргә ия булуны таләп итә һәм билгеле бер дәрәҗәдә интуитив рәвештә башкарыла. Уку процессында яки озак вакытлар тәрҗемә итү практикасы дәвамында белем һәм күнекмәләр үзләштерү нәтиҗәсендә, тәрҗемә проблемаларын тиешле дәрәҗәдә хәл итү өчен интуитив сәләт барлыкка килә. Билгеле, мондый сәләтнең

уңышлы үстерелеше кешенең индивидуаль үзенчәлекләренә дә бәйле. Иң югары казанышларга тумыштан әлеге эшчәнлеккә таланты булган кешеләр ирешә торгандыр, бәлки. Талантлы тәрҗемәчеләрнең билгеле бер махсус хәзерлектән тыш һәм бик үк күп көч куймыйча гына эш башыннан ук югары тәрҗемә осталыгы күрсәтү очраклары мәгълүм. Әмма практика исбат иткәнчә, тәрҗемә аерым талантлы кешеләр тәкъдире генә түгел, укый-укый да тиешле профессиональ нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Дөрес, укуның уңышлы нәтиҗәсе билгеле бер дәрәҗәдә уку процессын оештыру, уку программасы һәм укыту методикасына да бәйле.

Шулай итеп, тәрҗемәгә аерым уку фәне буларак өйрәтергә кирәк, тәрҗемә осталыгына ия булу аерым талантлы кешеләр хокукы гына түгел. Бу фикер җәмгатьчелек тарафыннан кабул ителгән һәм күпчелек уку йортларында тәрҗемә теориясе һәм практикасы буенча дәресләр алып барыла.

Тәрҗемә итү сәләте, телләр өйрәнү сәләте кебек, кешегә генетик яктан бирелә, гәрчә кешеләрдә бу үзенчәлек бертөрле булмаса да, аны үстерергә һәм профессиональ дәрәҗәгә җиткерергә мөмкин дигән ышану тәрҗемәгә өйрәтү методикасы фәненең нигезендә ята.

Тәрҗемәгә өйрәтү гамәли максатларны гына – укучыларда тәрҗемә компетенциясе (белем-хәбәрдарлык) барлыкка китерүне генә күздә тотмый. Ул мөһим гомумлингвистик һәм гомумбелем бирү функциясен дә үти. Тәрҗемә дәресләре тел берәмлекләренең семантикасындагы һәм куллану аспектларындагы нечкәлекләргә игътибар итәргә өйрәтә, телләрнең система буларак оешу һәм яшәү үзенчәлекләрен ача, төрле тел коллективлары вәкилләренең мәдәниятендә, фикерләвендә гомуми һәм аермалы якларны күзәтергә мөмкинлек бирә. Тәрҗемә белеме бирү булачак тәрҗемәчеләрне төрле яклап үстерергә булышырга тиеш: игътибарлылыкны һәм җаваплылык хисен үстерү, белешмә әдәбият һәм өстәмә мәгълүмат чыганакларыннан файдалану күнекмәләрен формалаштыру, сайлау, тиз генә дөрес карарлар кабул итү, күпсанлы лингвистик һәм экстралингвистик мәгълүматларны күрә белү һ.б. Тәрҗемәчене профессиональ яктан хәзерләү югары мәдәниятлелек, киң энциклопедик

эрудиция, аралашучанлык, такт, даими рәвештә белемнәрне камилләштерү, кызыксынучанлыкны күздә тота. Бу сыйфатлар ике телдә һәм ике мәдәнияттә чагылыш таба.

Тәрҗемәгә өйрәтү күп очракта укучыларның телдән хәзерлеге белән билгеләнә, ә ул үз чиратында укытудагы *ике ситуация*нең куелышына бәйле. Беренче очракта укыту процессында ике телне дә (оригинал һәм тәрҗемә телләрен) камил белгән укучылар катнаша. Бу вакытта тәрҗемәгә өйрәтү тәрҗемәчелек белемнәрен (компетенциясен) формалаштыру, тәрҗемә осталыгын һәм күнекмәләрен үстерү, телара бәйләнышларның төрле этапларында тел чараларын кулланырга өйрәтүдән гыйбарәт.

Икенче очракта тәрҗемәгә өйрәтү тәрҗемә процессында катнаша торган телләрнең берсен начаррак белгән шартларда бара һәм телне өйрәнү белән паралелль оештырыла. Бу вакытта укучыларда кайбер тиешле белемнәрнең булмавын истә тотарга кирәк.

Тәрҗемәгә ни өчен өйрәтергә дигән сорауга җавап шундый.

Ә нәрсәгә өйрәтергә, тәрҗемә курсының эчтәлеге нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап бирү кыенрак.

Беренче чиратта, теләсә кайсы уку фәненең эчтәлеге өйрәнелә торган предметның үзенчәлекләре һәм укытуның соңгы максаты белән билгеләнә.

Тәрҗемәчелекнең асылын тәрҗемә теориясе өйрәнә, тасвирлый һәм аның нигезләмәләре булачак тәрҗемәчеләрне хәзерләү программасының нигезендә ята. Шулай да тәрҗемә курсының төп бурычы – студентларга билгеле бер белемнәр җыелмасын җиткерү генә түгел, бәлки аларны югары квалификацияле, профессиональ дәрәҗәдә тәрҗемә итә алырлык белгечләр итеп хәзерләү. Шунлыктан курсның төп өлеше профессиональ тәрҗемә осталыгын һәм күнекмәләрен үстерүгә, тәрҗемә стратегиясе һәм техникасы элементларын үзләштерүгә, төрле авырлыктагы текстларны тәрҗемә итү тәҗрибәсен туплауга багышлана. Курс эчтәлегенең конкрет төзелеше аның уку планындагы урынына һәм сәгатьләр санына бәйле.

Тәрҗемәгә өйрәтү методикасы әлегә кадәр эшкәртелмәгән. Тәрҗемәгә өйрәтүне оештыру һәм аның

методлары кайбер постулатларны кабул итүгә нигезләнә. Алар түбәндәгеләр:

1. Тәрҗемә акыл эшчәнлегенең катлаулы һәм күпкырлы төре санала. Ул төрле максатларны күздә тотарга, төрле шартларда, төрле ысуллар һәм күптөрле факторлар тәэсире астында башкарылырга мөмкин.

2. Башка һәртөрле эшчәнлек кебек үк, тәрҗемә дә билгеле бер белемнәр, осталык һәм күнекмәләр булуны таләп итә, алар укыту барышында формалашырга тиеш.

3. Тәрҗемәчелек тәрҗемәче тарафыннан аңлы яки интуитив рәвештә башкарылырга мөмкин. Шартларга бәйле рәвештә, аңлылык һәм интуиция нисбәте төрле тәрҗемәчеләрдә, төрле текстларны тәрҗемә итүдә төрлечә була. Болар да уку һәм практика дәвамында үстерелә.

4. Тәрҗемәчелек белемнәрен алу тәрҗемәченең бөтен тел эшчәнлеге катнашында бара. Ул тәрҗемәчедә төрле яклы лингвистик белемнәрнең, киң гомуммәдәни эрудициянең, тиешле психологик сыйфатларның һәм әдәби сәләтләрнең булуын күздә тота.

5. Тәрҗемәгә өйрәтүнең бурычы – ниндидер нормалар, кагыйдә яки рецептлар үзләштерү түгел, ә тәрҗемә принциплры, метод һәм ысуллары белән таныштыру, аларны конкрет шартларда, төрле максатлар өчен сайларга һәм кулланырга өйрәтү.

6. Тәрҗемә эшчәнлегенең объекты – чыганак тексттагы мәгълүмат. Текст эчтәлеге семантик һәм формаль яктан тәмамланган бербөтен, аның аерым өлешләре үзара бәйле, әмма аралашуда бердәй дәрәҗәдә әһәмиятле булмый. Тәрҗемә төренә һәм максатына бәйле рәвештә, тәрҗемә процессында бөтеннең һәм аның аерым өлешләренең нисбәте аерып чыгарыла. Тәрҗемәдә текстның аерым элементлары төрлечә төгәллек белән чагылдырыла, бу аларның текстта уйнаган роленә бәйле.

7. Текстны төзегән тел берәмлекләре үзләре тәрҗемә объекты түгел. Әмма алар текстның эчтәлеген оештыра, аерым тел чараларының текстта булуы семантик әһәмияткә ия һәм алар тәрҗемә бурычларының характерын билгеләргә, тәрҗемәдә аерым кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Бу нисбәттән

тел берәмлекләренең мәгънәсен тәрҗемәдә бирү текстның тулаем эчтәлеген бирү проблемасы буларак карала.

8. Алда санап үтелгәннәр тәрҗемәгә өйрәткәндә кулланыла торган уку материалының характерын билгели. Беренче чиратта, алар уку процессын профессиональ тәрҗемәченең эш шартларына якынайта торган төрле тип текстлар булырга тиеш. Укыту максатларында типик тәрҗемә кыенлыкларын чагылдыра торган аерым текст өлешләрен дә кулланырга мөмкин.

9. Тәрҗемә дәресләрендә типик тәрҗемә бурычларын хәл итү методлары һәм индивидуаль иҗади чишелешләр эзләү стратегиясе өйрәнелергә тиеш.

10. Телара бәйләнешләрнең характеры оригиналның бер үк өлешләрен төрле вариантларда тәрҗемә итү мөмкинлекләрен күрсәтә. Шунлыктан укыту процессында текстның бердәнбер дөрес тәрҗемәсен булдыру максаты куелмый. Шулай ук укыту процессы уку-укыту тәрҗемәләренә тәнкыйть күзлегеннән бәя бирү һәм тәкъдим ителгән вариантларны кире кагу кебек күренешләрне дә үз эченә ала. Укытучы бу очракларда оригинал текст һәм тәрҗемәне чагыштырып анализлау юлы белән үз фикерен дәлилләргә тиеш.

3.2. ТӘРҖЕМӘЧЕНЕҢ ҺӨНӘРИ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

Компетенция – билгеле бер өлкәдә хәбәрдарлык, мәгълүматлылык.

Кайбер кешеләрнең “табигый” тәрҗемәгә сәләтләре кайчак шул дәрәҗәдә үсә ки, алар хәтта профессиональ тәрҗемәчеләр булып китәргә дә мөмкин. Тик шулай да күпчелек очракта “табигый” тәрҗемә якынча була һәм профессиональлеккә ирешү өчен үзенчәлекле тәрҗемә компетенциясе формалаштырырга кирәк. Мөгаен, “табигый” тәрҗемә тәрҗемә компетенциясен үстерү өчен нигез булып хезмәт итә торгандыр, әмма “табигый” тәрҗемәнең кайбер элементлары бу процесска комачаулый да.

Профессиональ тәрҗемә компетенциясен барлыкка китергәндә үзенчәлекле тел шәхесе формалаша, ул тәрҗемәче булмаган “нормаль” шәхестән бер төркем сыйфатлары белән

аерылып тора. Бу аермалыклар сөйләм коммуникациясенең барлык аспектларында да (тел, текст оештыру, аралашу, шәхси, профессиональ, техник һ.б.) чагылыш таба. Тәрҗемәче компетенциясенең үзенчәлекләре турында сөйләшә башлаганчы, бу аспектларны карап үтү урынлы булыр.

Аралашучыларның тел компетенциясе

Тел ярдәмендә аралашу тел чараларын аралашуның максатына һәм ситуациягә тулысынча туры китереп куллануны күздә тота. Аралашучылар тел ярдәмендә фикер алмаша алсыннар өчен, аларның хәтерендә әлеге тел буенча белемнәр, тел берәмлекләренең формалары һәм мәгънәләре сакланырга тиеш. Аерым кешенең телне шул рәвештә белүе аның ***телдән хәбәрдарлыгын*** тәшкил итә, ул исә тел коллективы әгъзалары куллана торган тел чаралары җыелмасын теге яки бу күләмдә чагылдыра. Кешенең телдән хәбәрдарлыгы зуррак булган саен, ул тел ярдәмендә аралашуның төрле формаларында уңышлы катнаша ала.

Аралашу чарасы буларак тел турында мәгълүматларны искә төшерик. Тел – катлаулы тамгалар системасыннан гыйбарәт. Бу тамгалар үзара төрле формаль һәм эчтәлекле мөнәсәбәтләрдә торалар. Телдәге һәр тамганың үзенчәлекле аваз формасы бар, аны шартлы рәвештә график яктан сурәтләп була һәм һәр тамга билгеле бер мәгънәгә, ягъни телдән файдаланучылар хәтеренә теркәлгән фикерле эчтәлеккә ия. Телне кулланучылар тел тамгаларын аера һәм аларның мәгънәләрен искә төшерә алалар. Төрле тамгаларның формалары һәм мәгънәләре арасындагы бәйләнешләрне система эчендә дә (парадигматик бәйләнешләр) һәм тамгаларны аралашканда бергә куллану очрагында да (синтагматик бәйләнешләр) белү тел компетенциясенә керә. Тел тамгаларын аралашу процессында куллану *сөйләм* дип атала.

Тел системасында тамгалар арасындагы бәйләнешләр җыелмасы телнең *структура*сын тәшкил итә. Тел структурасы сөйләмдә тел тамгаларын бергә куллану ысулын билгели. Тамгалар сөйләмдә кагыйдәләр буенча кулланыла. Алар һәр телдә үзенчәлекле була. Бу кагыйдәләр мәҗбүри (тел нормасы)

яки кулай саналган (сөйләм нормасы яки узус) булырга мөмкин. Телне бозу сөйләмне хаталы итә, узусны бозу исә аны гайре табигый ясый.

Тел берәмлекләре аралашуның төрле өлкәләрендә кулланыла. Аралашуның кайбер өлкәләре башкаларында сирәк яки бөтенләй очрамый торган билгеле бер тел берәмлекләре җыелмасы кулланылу белән аерылып торырга мөмкин. Шундый җыелмага кергән тел берәмлекләре аерым бер *функциональ стильгә караган сүзләр* санала.

Аралашу өчен бер үк телдән файдаланучы кешеләр төркеме *тел коллективы* дип атала. Тел коллективы төрле. Тел коллективына кергән кешеләр, төрле географик районнарда яшәгән хәлдә, телнең билгеле бер лексик, грамматик үзенчәлекләре булган аерым төрләреннән файдаланырга мөмкин. Төрле иҗтимагый яки профессиональ төркемнәргә кергән кешеләрнең дә сөйләмендә үзенчәлекләр була (иҗтимагый диалектлар).

Аралашу ситуациясе һәм аралашучыларның (коммуникантларның) үзара мөнәсәбәтләре дә (өлкән һәм яшь кеше, кондуктор һәм пассажир, сатучы һәм алучы һ.б.) сөйләм коммуникациясендә тел берәмлекләрен сайлау һәм куллану характерына тәэсир итә. Телне сөйләм ситуациясенә һәм рольле функцияләргә бәйле рәвештә куллану үзенчәлекләре билгеле бер *сөйләм регистрын* (тантаналы, рәсми, көндәлек, интим һ.б.) барлыкка китерә.

Коммуникантларның аралашу компетенциясе

Кешеләрнең тел ярдәмендә аралашуы үзенчәлекле, катлаулы юл белән бара һәм телне җитәрлек дәрәҗәдә белү – аралашу шартларының берсе генә. Хәбәрләмәне тәшкил иткән тел берәмлекләре аша тапшырылган мәгълүмат җиткерелә торган хәбәрнең глобаль эчтәлеге турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирүче сигнал булып кына хезмәт итә. Бу – бөтенне алыштыра торган өлеш (*синекдоха* дип аталган стилистик алымга охшаш). Аралашучылар аралашу ситуациясеннән алынган мәгълүмат һәм дөнья турында элеккеге белемнәре (фон белемнәре) ярдәмендә хәбәрләмәнең тел эчтәлеген баеталар.

Мәсәлән: “Бүген салкын” дигән фраза төрле ситуациядә һәм төрле әңгәмәдәшләр өчен “Җылырак киен”, “Мичне кабыз”, “Без бүген урамга йөрергә чыкмыйбыз”, “Этне өйгә керт” һ.б. аңлатырга мөмкин.

Сөйләүче үзенең хәбәрләмәсен тыңлаучы обстановканы исәпкә алыр һәм фон белемнәре ярдәмендә тиешле рәвештә кабул итәр дигән өмет белән төзи. Өстәмә белемнәр төрле күләмдә була. Аларның бер өлеше әлеге тел коллективының барлык әгъзаларына да яки күпчелегенә таныш була, кайберләре аерым һөнәр ияләренә генә мәгълүм, өченчеләре исә кечкенә иҗтимагый төркемнәр, җирле яки бер гаиләдәге затларга гына билгеле була. Барлык очракларда да мондый белемнәрнең характеры, сөйләм хәбәрләрен шәрехләү һәм аңлау ихтималы тел коллективы тормышының мәдәниятне тәшкил иткән (тарих, тормыш шартлары, гореф-гадәтләр, мәгариф системасы, әдәбият, дәүләт һәм җәмәгать структуралары кебек) яклары белән билгеләнә. Бер мәдәнияткә карау күп очракта тел коллективы әгъзаларының аралашу шарты булып тора.

Кешенең *инференция*гә (фон белемнәренә таянып, сөйләм хәбәрләмәләреннән аларның тулы эчтәлеге яки мәгънәсе турында дөрес нәтиҗәләр формалаштыру) сәләте аның ***аралашу компетенциясен*** барлыкка китерә.

Аралашучыларның текст оештыру компетенциясе

Әйтеп үтелгәнчә, сөйләм коммуникациясе хәбәрләмә һәм текстлар аркылы башкарыла. Текстны төзегән тел берәмлекләре аларда контекстуаль мәгънәләрдә кулланылалар.

Хәбәрләмә берәмлекләренең үзара бәйләнгән контекстуаль мәгънәләре җыелмасы аның *эчтәлек планын* тәшкил итә. Ул, алда билгеләнгәнчә, хәбәрләмә ярдәмендә тапшырыла торган мәгълүматларның бер өлешен генә бирә. Эчтәлек планы (“тел эчтәлеге”) аралашучылар теге яки бу дәрәҗәдә бердәй шәрехли торган күләмле (глобаль) мәгънәне чыгару өчен нигез булып тора. Хәбәрләмәнең мәгънәсе күптөрле, хәрәкәтчән, чөнки ул мәгълүматны кабул итүченең фон белемнәренә һәм аң дәрәҗәсенә бәйле була. Хәбәрләмәнең тел эчтәлеге мәгълүматны *эксплицит* рәвештә, ягъни тел

берәмлекләренең үз мәгънәләре аша яки *имплицит* формада, икенче төрле әйткәндә, сөйләшүче коллектив аңындагы бу мәгънәләр белән бәйле өстәмә мәгънәләр аша бирелергә мөмкин. Димәк, хәбәрләмәне оештыра торган сөйләм актлары *туры* яки *кыек* була. Мәсәлән: "Ишекне яба алмассызмы?" – моны эшләүне (ишекне ябуны) күздә тота. "Мин авырыйм" – "Мин укырга килә алмыйм" дигәнне аңлатырга мөмкин.

Хәбәрләмә мәгънәсендә төп нәрсә – авторның нияте, ул хәбәрләмәнең эчтәлеген һәм мәгънәсен билгели, әмма бу ният төрле күләмдә, уңышлы яки уңышсыз үтәлергә мөмкин. Шунлыктан авторның текст эчтәлегеннән һәм мәгънәсеннән аңлашылган нияте, аның субъектив теләкләренә төрле дәрәҗәдә тәңгәл була. Аралашу вакытында кайчак авторга (чыганакка) нәрсә әйтергә теләвен аңлатырга яки акланырга туры килә (мәсәлән, "Мин алай дип әйтергә теләмәгән идем").

Тагын да катлаулырак хәбәрләрне тапшыру өчен хәбәрләмәләр структур һәм мәгънәви яктан бер бөтенгә – текстка берләшә. *Текст* – аралашу берәмлеге. Ул бер яки берничә хәбәрләмәдән торырга мөмкин. Текстның *бөтенлеген* (когерентлык) тәэмин итү өчен *мәгънәви һәм формаль бәйләнешләр*нең (когезия) төрле чаралары файдаланыла. Структураны барлыкка китерү ысуллары һәм чаралары текстның тибы белән тапшырыла торган мәгълүматның характерына бәйле. Кабул ителгән схемалар буенча төзелә торган стандарт текстлар һәм чагыштырмача ирекле структурага ия стандарт булмаган текстлар бар. Аерым текст үз тибына (прототипка) төрле дәрәҗәдә туры килергә мөмкин.

Текст структурасында теге яки бу дәрәҗәдә ачык күренеп торган аерым өлешләр була: бүлекләр, бүлекчәләр, абзац, синтаксик бөтен һәм аерым хәбәрләмәләр. Алар текст эчендә бердәй әһәмиятле түгел һәм мөстәкыйльлекләре дә төрлечә, әмма алар һәрвакыт үзара бәйләнгән була. Бу мәгънәдә текст аерым функция башкара торган бер коммуникатив бөтен буларак яши.

Аралашу бурычына һәм ситуациясенә туры китереп, төрле тип текстлар оештыру, текстның тиешле структурасын тәэмин итү, текст берәмлекләрен телдә сөйләм берәмлекләрен төзү кагыйдәләре буенча куллану, тексттагы аерым өлешләрнең

урынын һәм нисбәтен бәяләү, текстны тоташ сөйләмнең бербөтен кисәге итеп кабул итү аралашучыларның ***текст оештыру компетенциясен*** тәшкил итә.

Икетелле аралашуның үзенчәлекләре

Телне аралашу чарасы буларак куллануның төп закончалыклары телара аралашуда да саклана. Әмма аның икетелле булуы бер төркем үзенчәлекләр китереп чыгара. Тәрҗемәче бер үк вакытта ике телдән, төрле телдәге ике тексттан файдалана, ике охшаш булмаган мәдәният белән янәшә эш йөртә. Бу шартларда аралашу түбәндәге сәбәпләр аркасында катлаулана:

- оригинал текстының авторы тәрҗемә текстын кабул итүчене (рецепторны) күздә тотмый, шунлыктан оригиналның үзенчәлекләрен гадәти рәвештә күчерү белән генә уңышлы аралашу шарты үтәлә алмый. Ул тәрҗемә текстын оештырганда аерым тәэмин ителергә тиеш. Телара багланышта катнаша торган ике текст төрле шартларда оеша, алардан файдаланучы коммуникантларның фон белемнәре төрле була, текстлардагы эксплицитлык һәм имплицитлык нисбәте дә бер-берсенә туры килми;
- текстларның ике төрле телгә, ике сөйләм системасына каравы аларның формаль яки эчтәлек ягыннан тәңгәллеген юкка чыгара. Шуңа күрә бу очракта аралашу әлеге текстларның өлешчә, чагыштырмача туры килүе нигезендә генә башкарыла һәм ул аралашуның уңышлы булуына китерергә тиеш. Ә тәрҗемәче аңа мөмкин булган тәрҗемә вариантларын сайлау нәтиҗәсендә ирешә. Сайлаганда югалтуларның зарурлыгын, оригиналның әһәмиятле үзенчәлекләрен истә тотарга кирәк һәм алар тәрҗемәдә чагылыш табарга тиеш;
- телара багланышларның үзенчәлеге тәрҗемәченең тел, аралашу һәм сөйләм компетенциясеннән тыш, ике телдә аралашу өчен үзенчәлекле тәрҗемәче компетенциясенә дә ия булуын таләп итә. Мондый компетенцияне формалаштыру - тәрҗемәгә өйрәтүдә төп бурычларның берсе.

Тәрҗемә эшчәнлегенең күптөрлелеге

Тәрҗемәчеләр хәзерләү эше күп очракта тәрҗемәчеләрнең телара коммуникациянең төрле формаларын тәэмин итү өчен башкарыла торган эшчәнлекнең күптөрле булуы белән кыенлаша. Тәрҗемәнең төрле төрләренә өйрәтү аерым методик алымнар таләп итә. Профессиональ тәрҗемәче берничә төр тәрҗемә эше буенча специальләшергә мөмкин.

Тәрҗемәнең күптөрлелеге тәрҗемә төрләре белән генә бәйләнмәгән. Тәрҗемә төрле шартларда, теге яки бу дәрәҗәдәге тыгыз вакыт аралыгында, төрле максатлар белән, төрле заказчылар өчен үтәлергә мөмкин. Тәрҗемә оригинал тексты белән гомуми танышу өчен дә, нинди дә булса мәгълүмат алу максаты белән дә һәм оригиналны чын-чынлап алыштырырлык итеп тә башкарылырга мөмкин. Санап үтелгән барлык очракларда тәрҗемәгә төрле таләпләр куела, шунлыктан тәрҗемәче төрле шартларда эшләрлек итеп әзерләнергә тиеш.

Тәрҗемәче эшенең характерына аның рәсми статусы да тәэсир итә. Ул нинди дә булса берәр бюрода яки бүлектә штаттагы хезмәткәр булырга, аерым гына яки тәрҗемәчеләр төркеме белән эшләргә, “ирекле рәссам” кебек килешүләр һәм контракт буенча тәрҗемә итәргә, тәрҗемә редакторы, консультант һәм тәрҗемәчеләр төркеме җитәкчесе һ.б. рәвештә эшләргә мөмкин.

Тәрҗемәчегә шулай ук күп кенә “тәрҗемәгә якын” эшчәнлек төрләре башкару да (килешүләр, эшлекле хат алышулар алып бару, делегацияләрне кабул итү һәм озатып йөрү, күзәтүләр ясау, әңгәмәләрнең беркетмәләрен һ.б. шундый документлар эшләү, телдән консультацияләр бирү һ.б.) йөкләнүе ихтимал.

Телара багланышларның үзенчәлекләре һәм тәрҗемә эшчәнлегенең күптөрлелеге булачак тәрҗемәчедә бер төркем сыйфатлар белән характерлана торган үзенчәлекле **тәрҗемәче компетенциясе** формалаштыруны таләп итә.

Тәрҗемәченең ***тел компетенциясе*** телне белүнең барлык аспектларын үз эченә ала, әмма шул ук вакытта аның берникадәр үзенчәлекләре дә бар. Телдән аралашуда катнаша торган барлык кешеләр кебек үк, тәрҗемәче дә тел системасы,

аның нормалары һәм узусы, сүзлек составы һәм грамматик төзелеше, сөйләм хәбәрләрен төзү өчен тел берәмлекләрен кулланудагы грамматик кагыйдәләр, төрле аралашу өлкәләрендә аерым тел берәмлекләре җыелмасын куллану зарурлыгы, тел берәмлекләренең җирле, иҗтимагый һәм һөнәри аерымлыклары, аралашу ситуациясе һәм аралашуда катнашучылар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең тел берәмлекләрен сайлауга һәм куллану характерына тәэсире турындагы белемнәрне хәтерендә саклый. Әлеге белемнәр, тиешле психофизиологик сәләт һәм сөйләм-фикер йөртү механизмы оригинал текстын аңлау һәм тәрҗемә текстын төзү өчен гаять әһәмиятле.

Болар белән беррәттән, тәрҗемәченең сөйләм эшчәнлегендәге үзенчәлекләр аның тел компетенциясенә өстәмә таләпләр дә куя. Алар тәрҗемәченең ике тел өлкәсендәге тел компетенциясе белән генә бәйләнмәгән. Барыннан да элек, телне “нормаль” белүчеләрдән аермалы буларак, тәрҗемәченең тел компетенциясенең характеры һәм чикләре күпмедер күләмдә “тыштан” билгеләнә. Гадәти аралашучы телне билгеле бер дәрәҗәдә белә, ул аны үзе теләгәнчә куллана, аралашу максатына һәм ситуациягә бәйләп, үз идиодиалектыннан тел чараларын мөстәкыйль рәвештә сайлый. Бу вакытта ул чикләнгән тел чаралары җыелмасы белән канәгатьләнергә, үз мөмкинлекләренә туры килмәгән һәм телне киңрәк, тулырак, нәтиҗәлерәк куллану таләп ителгән аралашу актларында катнашмаска мөмкин. Тәрҗемәче өчен исә аралашу өлкәсен һәм максатын, тел чараларын сайлау һәм куллану ысулларын оригинал билгели, алар тәрҗемәченең теләкләренә бәйле түгел. Шунлыктан тәрҗемәче ике телдә дә тел компетенциясенең барлык якларын белергә тиеш. Билгеле, тәрҗемәченең тел компетенциясендә дә чикләр бар, әмма ул киңрәк булган саен, тәрҗемәченең гомуми һөнәри компетенциясе югарырак була.

Тәрҗемәченең тел компетенциясенә таләпләрнең чикләнмәгән булуы аның тел белемнәрен (аеруча чагыштырма пландагы) тиз арттыру һәм тулыландыру зарурлыгын китереп чыгара. Тәрҗемәче – даими эзләнүчән, үз-үзеннән “моны икенче телдә ничек әйтергә, бу очракта икенче телдә нәрсә диләр?” кебек сорауларга даими рәвештә җавап уйлый торган кеше. Ул тыңлаганда яки укыганда нәрсә әйтелгән һәм язылганны гына

түгел, ә ничек әйтелгән һәм язылганны ишетүче һәм күрүче, ул бервакытта да сүзлектән аерылмаучы, тел турында нинди дә булса яңалык белү мөмкинлеген ычкындырмаучы, һәрвакыт үз картотекасын тулыландыручы кеше.

Шул сәбәпле тәрҗемәченең тел компетенциясе үзенең сыгылмалылыгы, сөйләгәнне кабул итүдән тиз генә сөйләүгә, бер телдән икенче телгә, кыска гына вакыт аралыгында бер стильдән һәм регистрдан икенче стильгә һәм регистрга күчә алуы белән аерылып тора.

Аралашу процессында сөйләм әсәрләре (текстлары) белән уңышлы алмашу коммуникантларның ***текст оештыру компетенциясе*** (билгеле бер тел коллективында кабул ителгән кагыйдәләр һәм стереотиплар буенча төрле тип текстлар төзү осталыгы) булуын таләп итә.

Тәрҗемәченең профессиональ компетенциясендә аның ***аралашу (коммуникатив) компетенциясе*** дә мөһим урын тота. Тәрҗемәче ике телдә дә аралашу компетенциясенә ия, шунсыз ике телне белү мөмкин дә түгел. Шуның белән бергә тәрҗемәченең һөнәри компетенциясе текстларның һәм хәбәрләмәләрнең мәгънәсен шәрехләүне генә күздә тотмый. Тәрҗемәче оригиналның тел эчтәлеген икенче телгә күчерү генә аны дөрес аңлауга китерерме дип, даими рәвештә уйларга тиеш, чөнки чыганакны икенче телдә кабул итүчеләрнең фон белемнәре аерыла. Кирәк булганда тәрҗемәче тел эчтәлеге белән аннан килеп чыккан мәгънә нисбәтенә төзәтмәләр кертә: җитешмәгән фон мәгълүматларын хәбәрләмәгә өсти, яисә астөшермәдә яки искәрмәләрдә күрсәтә. Шул рәвешчә, гадәти аралашучылардан аермалы буларак, тәрҗемәченең аралашу компетенциясе чагыштырма-динамик характерга ия. Бу мәгънәне аңлау сәләте генә түгел, бәлки ике тел коллективының мәгънәне кабул итү сәләтләрен чагыштыра алу һәм, тәрҗемәдә аның тулаем мәгънәсе турында тиешле нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге тудыру өчен, хәбәрләмәнең тел эчтәлегенә үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында нәтиҗәгә килү осталыгы да.

Тәрҗемәченең һөнәри компетенциясе кайбер ***шәхси характеристикалар***ны да үз эченә ала, чөнки алардан башка тәрҗемәче профессиональ вазифаларын уңышлы үти алмас иде.

Тәрҗемә – катлаулы аң эшчәнлеге. Ул тәрҗемәченең уй-фикерләрен туплауны, хәтерендәге ресурсларны, үзенең барлык интеллектуаль һәм эмоциональ мөмкинлекләрен эшкә җигүне сорый.

Тәрҗемәчегә төрле тематика белән эш итәргә, төрле фәнни өлкәләргә караган, аерым очракларда аеруча үзенчәлекле текстлар тәрҗемә итәргә туры килә. Аннан төрле яклап мәгълүматлы булу, югары эрудиция таләп ителә. Ул бик культуралы һәм энциклопедик белемле кеше булырга тиеш. Тәрҗемәченең даими рәвештә үз белемен күтәрүе, яңа мәгълүматлар эзләп табуы һәм үзләштерә алуы, төрле белешмәләрдән һәм башка чыганаклардан нәтиҗәле файдалана белүе аеруча мөһим. Тәрҗемәче үзе өчен гомуми белемгә ия булуның, төрле белемнәрнең артык булмавын аңларга тиеш.

Тәрҗемәченең *мораль-этик сыйфатлар*ын аерып билгеләргә кирәк. Ул үз эшенең сыйфаты, эшенә намуссыз каравыннан килеп чыгарга мөмкин булган барлык әхлакый һәм матди зыян өчен тулысынча җаваплы. Тәрҗемәче хезмәтеннән файдаланучылар аның объективлыгына һәм ышанычлылыгына исәп тота. Оригиналны белмәгәнгә, алар тәрҗемәче хезмәтен (тәрҗемәне) төп нөсхәнең тулы кыйммәтле эквиваленты итеп кабул итәләр. Башка барлык эшчәнлекләрдән аермалы буларак, тәрҗемәче эшчәнлеге тәрҗемә рецепторларының тәрҗемәче эшенә тулысынча ышануларына нигезләнә. Тәрҗемәче үз эшенә намус белән каравы, эшкә сәләтлелеге һәм җыйнаклыгы аша гына бу ышанычны аклый ала.

Тәрҗемәче гаять төрле аралашу ситуацияләрендә эш итә. Ул яшерен сәяси һәм коммерция документлары белән эш йөртергә, иң югары дәрәҗәдәге ябык сөйләшүләрдә катнашырга, күп кенә кешеләрнең шәхси тормышындагы интим нечкәлекләрне белергә мөмкин. Тыйнаклык, тактлылык, үз-үзеңне тота белү, сер саклау – тәрҗемәче һөнәренең зарури өлеше. Тәрҗемәченең язылмаган әхлакый кодексында, Гиппократ антындагы кебек, *“Зыян салма!”* дигән кагыйдә төп урынны биләргә тиеш.

Тәрҗемәченең профессиональ компетенциясен формалаштыру әлеге белгечлекнең мораль-этик кагыйдәләренә туры килүче үзенчәлекле шәхес үстерүне күздә тота.

Тәрҗемәченең профессиональ компетенциясе ***техник компетенция***гә ия булуны да үз эченә ала. Тәрҗемә белемнәре тәрҗемә эшчәнлегенең асылын һәм бурычларын аңларга ярдәм итә, тәрҗемә теориясенең төп нигезләмәләре белән таныштыра, тәрҗемә стратегиясе вариантлары һәм тәрҗемәнең техник ысуллары белән коралландыра. Тәрҗемәче стратегиясе тәрҗемә процессындагы өч төркем гомуми принципларны үз эченә ала: кайбер чыганак постулатлар; эш-гамәлләрнең тәрҗемәче конкрет карарлар кабул иткәндә таянырлык гомуми юнәлешен билгеләү; тәрҗемә процессындагы эш-гамәлләрнең характерын һәм эзлеклелеген сайлау. Тәрҗемәче стратегиясендәге чыганак постулатлар күп очракта тәрҗемәченең арадашчы ролендә, иҗатының икенчел характерда булу белән билгеләнә. Телара коммуникациядә катнашучыларның өметен аклаганда гына тәрҗемәченең эшчәнлеге мәгънәгә ия. Шунлыктан, тәрҗемә ителә торган текстны тулырак аңларга һәм тәрҗемә телендә дә аңа тулырак тәңгәллек табарга омтылу тәрҗемәче эшчәнлегенең гомуми стратегиясе нигезендә ята. Тәрҗемәченең иң мөһим стратегик принцибы – үз эшенә тәнкыйть белән карау. Әгәр оригинал буталчык, аңлаешсыз тоелса, бу авторның җитешсезлеге түгел, ә тәрҗемәченең белеме җитмәү. Шунлыктан ул оригиналны мөмкин кадәр аңлаешлы итеп укучыга (тыңлаучыга) җиткерергә тиеш. Бу – тәрҗемәченең төп стратегик принцибы. Тәрҗемәнең стратегиясе тәрҗемә максатын төгәл билгеләү һәм аны үтәү шартлары белән дә бәйле. Әлеге факторларга һәм тәрҗемә ителәсе текстның тибына бәйле рәвештә тәрҗемәдәге доминанта – тәрҗемәче омтылырга тиешле төп нәрсә ачыклана. Кабул ителгән карар нигезендә чыганак хәбәрне икенче телгә күчерү ысуллары сайлана. Тәрҗемәченең практик эш шартлары да (вакыт тарлыгы, төрле техник чаралар куллану мөмкинлеге һ.б.) тәрҗемәченең стратегиясенә билгеле бер йогынты ясый ала.

Тәрҗемә процессында эш-гамәлләрнең характерын һәм эзлеклелеген сайлау тәрҗемәченең белеменә, тәҗрибәсенә, фикер сөрешенә һ.б. бәйле, әмма кайбер үзенчәлекләр гомуми характерга ия. Бу иң элек, *тәрҗемәдән алда аңлау тора* дигән кагыйдә. Дөрес, тәрҗемә вакытында тәрҗемәче оригиналга кабат-кабат әйләнеп кайтып, аңлавын тирәнәйтә һәм тәрҗемәне

төзәткәли ала, әлбәттә. Тик шулай да тәрҗемәгә керешкәнче материалны аңлауның әһәмияте бик зур. Текстта *эзлекле кисәкләрне аерып билгеләү* шулай ук гомуми кагыйдәләргә карый: тәрҗемәче икенче кисәккә алдагысын тәрҗемә иткәннән соң гына керешә. Аңлау процессы һәм сөйләм туры сызык буенча барганлыктан, зур күләмле текстларны берьюлы тәрҗемә итеп булмый. Оригиналның "тәрҗемә адымы"н тәшкил иткән кисәге, гадәттә, бер-ике хәбәрләмәдән тора.

Тәрҗемә стратегиясенең күп кенә элементлары төрле вариантларга ия һәм аерым тәрҗемәчеләр аларны төрле шартларда төрле дәрәҗәдә файдалана. Боларга тәрҗемә телендәге охшаш текстлар, белешмәләр һәм энциклопедияләр белән алдан танышу; оригинал текстын тәрҗемәгә керешкәнче өйрәнү; терминнар һәм таныш булмаган сүзләр исемлеген төзү; каралама тәрҗемәдән файдалану яки шунда ук тәрҗемәнең соңгы вариантын сайлау; тәрҗемә өзекләрен кычкырып уку; тәрҗемә алды анализы үткәрү яки тәрҗемә иткәннән соң редакцияләү һ.б. керә.

Профессиональ техникада махсус күнекмәләргә ия булу хәлиткеч роль уйный. Уңышлы тәрҗемәгә китерә торган барлык күнекмә-осталыкларны да аерып билгеләү һәм тасвирлау мөмкин түгел. Аларның кайберләре комплекслы характерда һәм анализлауга буйсынмый (тәрҗемә осталыклары арасында аеруча мөһим саналганнары "Тәрҗемә процессында тәрҗемәченең эш-гамәлләре" параграфында яктыртылачак).

Тәрҗемәче компетенциясе турындагы концепция теоретик һәм практик яктан кызыксыну уята. Үзенең составына кергән факторларны һәм аларны формалаштыру-үстерү ысулларын төгәлрәк ачыклау өчен, ул алга таба тирәнрәк тикшеренүләргә мохтаҗ.

3.3. ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫ ФӘНЕНЕҢ УКУ-УКЫТУ ЭЧТӘЛЕГЕ

Тәрҗемәгә өйрәтү методикасы фәненең уку-укыту эчтәлеге күпчелек очракта студентларда тәрҗемәченең һөнәри компетенциясен формалаштыру өчен кирәк булган белемнәр, осталык һәм күнекмәләр белән билгеләнә.

Иң элек укытуның төп эчтәлеген тәшкил итә торган белемнәр һәм осталыкларны кыскача характерлап үтик. Алар арасында тыгыз бәйләнеш булуын һәм күп кенә осталык-күнекмәләрнең тиешле белемнәр булганда гына барлыкка килә алуын истә тотарга кирәк. Укыту дәвамында тәрҗемәче түбәндәге белемнәрне алырга тиеш:

- тәрҗемә тарихындагы төп этаплар турында һәм хәзерге заманда тәрҗемә эшчәнлегенең үзенчәлекләре хакында мәгълүмат;
- тәрҗемә ителүчәнлек, оригинал һәм тәрҗемә эчтәлекләренең тәңгәл булмавы, аз югалтулар принцибы кебек төшенчәләр турында күзаллау;
- телара коммуникация, эквивалентлык һәм тәрҗемә адекватлыгы төшенчәләреннән хәбәрдарлык;
- тәрҗемәнең прагматик аспектлары һәм тәрҗемәнең прагматик яраклашу ысуллары;
- тәрҗемәләрне төркемләү һәм тәрҗемә стратегиясе төрләре;
- төп тәрҗемә модельләре һәм тәрҗемә трансформацияләре, аларны тәрҗемә процессын һәм аның нәтиҗәләрен анализлаганда куллану ысуллары;
- төп тәрҗемә тәңгәллекләре һәм эквивалентсыз тел берәмлекләрен тәрҗемә итү юллары;
- бәйләнешле сөйләм текстын тәрҗемә итүдә төп принциплар турында мәгълүмат;
- тәрҗемәнең грамматик һәм стилистик аспектлары.

Алда санап үтелгән белемнәр студентларга махсус лекцияләрдә һәм семинарларда хәбәр ителә, гамәли дәресләрдә ныгытыла. Монда шунысы аеруча мөһим: студентлар әлеге белемнәрнең тәрҗемә практикасы белән бәйләнешен ачык күрергә, тәрҗемәдәге конкрет проблемаларны хәл иткәндә аларның кирәклеген аңларга тиеш.

Тәрҗемә эшчәнлеге тарихын һәм хәзерге замандагы торышын белү

Профессиональ тәрҗемәчегә тәрҗемәнең иҗтимагый-тарихи ролен күзаллау һәм тәрҗемә эшчәнлегенең төп үсеш этапларын белү гаять мөһим. Ул тәрҗемәчеләрнең милли телне, әдәбият һәм мәдәниятне формалаштыруга керткән зур

өлешләрен, тәрҗемәнең дипломатия, сәясәт, сәүдә, фән һәм техника өлкәсендәге халыкара багланышларда ролен аңларга ярдәм итә. Укыту программасы тәрҗемәнең борынгы чорларда ук барлыкка килүе, аның тарихи эволюциясе, букваль, ирекле һәм “кыскартылган” тәрҗемәләр өстенлек иткән чорлар һәм аның сәбәпләре, Россиядә тәрҗемә эшчәнлеге тарихындагы үзенчәлекләр, танылган рус һәм татар тәрҗемәчеләренең эшчәнлекләре турындагы мәгълүматларны үз эченә ала. Хәзерге заманда тәрҗемә эшчәнлегенең үзенчәлекләре (мәгълүмати тәрҗемәнең өстенлек итүе, тәрҗемәнең төгәллегенә таләпләр арту, материалларның тематик һәм стилистик төрлелеге, тәрҗемә ителә торган текстларның специальләшүе, тәрҗемәдә техник чараларның киң кулланылуы һ.б.) белән таныштыру да мөһим урын тота. Бу белемнәр булачак тәрҗемәчеләргә үз һөнәрләренең катлаулылыгын һәм мөһимлеген тоярга, тәрҗемәче хезмәтенең матди һәм оештыру аспектлары белән танышырга мөмкинлек бирә.

Тәрҗемә ителүчәнлек төшенчәсе, оригинал һәм тәрҗемә эчтәлекләренең тәңгәл булмавы белән таныштыру

Студентлар теләсә кайсы текстның чагыштырмача гына тәрҗемә ителүе турында мәгълүмат алалар: тәрҗемәдә югалтуларның котылгысызлыгы; мондый югалтуларның төрле аралашу максатларына бәйле рәвештә аклануы; тәрҗемә ителә торган текстның эчтәлегендә һәм формасында доминант аспектларны билгеләү зарурлыгы, аларның тәрҗемәдә һичшиксез бирелергә тиешлеге һ.б. Булачак тәрҗемәчеләр текстның нинди дә булса детален саклап калу икенче бер детальне югалту хисабына гына була алуын төшенәләр һәм, тәрҗемәче һәрвакыт икенең берсен сайлау алдында булуын аңлыйлар.

Телара коммуникация, эквивалентлык һәм тәрҗемә адекватлыгы төшенчәләре белән танышу

Тәрҗемәнең төрле телләрдә сөйләшүче кешеләргә аңлашу мөмкинлеген тәэмин итә торган тел арадашчылыгында төп ысул булуын аңлау тәрҗемә эшчәнлегенең асылы турындагы күзаллауларның нигезендә ята. Булачак тәрҗемәчеләр телара коммуникациянең төп компонентларын һәм аны тормышка ашыруга тәэсир итә торган факторларны өйрәнәләр; тел

арадашчылыгының төрле төрләре белән танышалар; тәрҗемәне оригинал текстын тәрҗемә телендә тулысынча алыштыра алырлык текст оештыру ысулы буларак кабул итәләр. Тәрҗемә белән оригиналны функциональ, семантик һәм структур тәңгәлләштерү аны тел арадашчылыгының башка төрләреннән (реферат, аннотация, резюме, эчтәлек сөйләү) аера, чөнки соңгыларында чыганак текстның эчтәлеге һәм төзелеше үзгәртелә. Студентлар тәрҗемәгә үз функциясен үтәү өчен куелган таләпләр (*эквивалентлык* – оригиналга тиешенчә һәм җитәрлек дәрәҗәдә якынлык; *адекватлык* – прагматик бурычны үтәү, тиешле коммуникатив тәэсир тудыру) белән танышалар.

Тәрҗемәнең прагматик аспектлары, тәрҗемәнең прагматик яраклашу сәбәпләре һәм ысуллары белән таныштыру

Студентлар тел тамгасының прагматикасы һәм текстның прагматик мөмкинлекләре кебек төшенчәләр белән танышалар, текстның прагматик тәэсире мәгълүмат кабул итүченең (рецептор яки реципиент) характерына бәйле булуын өйрәнәләр. Оригиналның коммуникатив тәэсирен тәрҗемәгә күчерү мөһимлеген аңлаган хәлдә, алар тәрҗемәне прагматик адаптацияләү ысулларын өйрәнәләр. Бу ысуллар тапшырыла торган хәбәрне адекват аңлауга, башка тел коллективы вәкилләренә (уртакул рецепторга) яки конкрет рецепторга тиешле прагматик тәэсир ясауга ярдәм итә. Болар белән беррәттән, студентлар аерым прагматик һәм шулай ук сәяси, пропаганда, коммерция һ.б. бурычлар белән бәйле максатларда тәрҗемә (филологик тәрҗемә, гадиләштерелгән тәрҗемә, үзгәртелгән тәрҗемә) куллану ихтималы булган очракларны өйрәнәләр. Бу тәрҗемәләрнең оригиналга турыдан-туры мөнәсәбәте юк һәм алар тәрҗемәченең яки клиентның теләкләрен чагылдыралар. Тәрҗемәнең прагматик аспектларын өйрәнү тәрҗемәченең, үз эшчәнлек кысаларыннан чыгып, тәрҗемә телендә оригинал белән бик аз гына бәйле булган параллель текстлар төзегән очракларны да үз эченә ала.

Тәрҗемә төрләре һәм тиешле тәрҗемә стратегияләре белән танышу

Тәрҗемәләрне төркемләү принциплары, мәгълүмати һәм матур әдәбият тәрҗемәләренең үзенчәлекләре, аларның

функциональ-стилистик һәм жанр төрләре, язмача һәм телдән тәрҗемәләрнең төп аермалары өйрәнелә. Студентлар аерым төр тәрҗемәләрнең төп стратегик бурычлары, аларның семантик һәм коммуникатив юнәлешләре, терминнар һәм образлылык нисбәте, чыганак һәм тәрҗемә телләрендә охшаш жанр һәм функциональ стильләрдә тел чараларын кулланудагы аермаларны тәрҗемәдә исәпкә алу зарурлыгы белән танышалар. Оригинал һәм тәрҗемә текстларының теркәлү, тәрҗемә процессында төзәтмәләр кертү, белешмә материаллар куллану, вакыт ягыннан чикләнү, телара багланышта катнашучылар белән аралашу мөмкинлеге һ.б. нисбәтеннән чыгып, язмача һәм телдән тәрҗемәләрнең аермаларын өйрәнәләр.

Төп тәрҗемә модельләрен һәм тәрҗемә трансформацияләрен (тәрҗемә алымнарын) өйрәнү

Студентлар, тәрҗемәченең эш-гамәлләре җыелмасы буларак, тәрҗемә процессы төшенчәсе белән танышалар, аның этапларын һәм тасвирлау принципларын өйрәнәләр. Тәрҗемә процессының моделен төзү зарурлыгы, модельнең бурычлары һәм аңлату көче ачыклана. Тәрҗемәнең төп психолингвистик һәм лингвистик модельләре, тәрҗемә процессын операцияләр ысулы белән тасвирлау өйрәнелә. Студентлар аерым модельләрнең асылы, тасвирламасы һәм куллану мөмкинлекләре белән таныша. Тәрҗемә трансформацияләре (тәрҗемә алымнары) төшенчәсе ачыклана һәм тәрҗемә трансформацияләренең түбәндәге төп типлары өйрәнелә:

- *лексик трансформацияләр*: транскрипция, транслитерация, калькалаштыру һәм лексик-семантик алмаштырулар (конкретлаштыру, генерализация һәм модуляция);
- *грамматик трансформацияләр*: сүзгә-сүз тәрҗемә, җөмләләрне таркату, җөмләләрне кушу, грамматик алмаштырулар (транспозиция);
- *лексик-грамматик трансформацияләр*: антонимик тәрҗемә, тасвирлама тәрҗемә, компенсация.

Тәрҗемә алымнарын өйрәнү аларны төрле тип тел берәмлекләрен, сөйләм хәбәрләмәләрен тәрҗемә иткәндә куллану сәбәпләре һәм ысуллары белән таныштыруны да үз эченә ала.

Төп тәрҗемә тәңгәллекләрен һәм эквивалентсыз тел берәмлекләрен тәрҗемә итү ысулларын өйрәнү

Тәрҗемәдә чыганак тел берәмлегенең мәгънәсен даими бирү ысулы буларак, тәрҗемә тәңгәллеге төшенчәсе ачыклана. Бердәнбер, вариантлы (күптөрле) һәм окказиональ тәңгәллекләр, аларны куллану сәбәпләре һәм очраклары өйрәнелә. Студентлар контекст төшенчәсе, оригинал эчтәлеген һәм тәрҗемә вариантын сайлауны аңлату өчен лингвистик һәм ситуатив контекстларны исәпкә алу, тел берәмлекләренең системадагы мәгънәсе һәм аларны контекстуаль куллану арасындагы бәйләнеш белән танышалар. Тәңгәллек типлары һәм аларны куллану ысулларын үзләштерәләр. Студентлар эквивалентсызлык төрләре һәм эквиваленты булмаган лексик, грамматик берәмлекләрне тәрҗемә итү методлары турында мәгълүмат алалар.

Бәйләнешле текстны тәрҗемә итүнең төп принципларын белү

Студентлар, структур бәйләнешкә (когезия) һәм мәгънәви бердәмлеккә (когерентлык) ия коммуникатив бөтен берәмлек буларак, бәйләнешле текст турында мәгълүмат үзләштерәләр. Алар текстта бөтеннең һәм өлешнең нисбәте, текстның зуррак өлешләренең мәгънәсен күчерү мөһимлеге һәм аерым детальләрнең төрле әһәмияткә ия булуы белән танышалар. Булачак тәрҗемәчеләр тәрҗемә белемендә текст типологиясе эчтәлеккә, формага һәм тәэсир итүгә нигезләнгәнлеген күрәләр, төрле телләрдә бертөрле текстларның эчтәлегендә, төзелешендә һәм бирелешендә аермалар булуга төшенәләр. Алар радио, телевидение яки сәхнәне күздә тоткан аудиовизуаль текстлар тәрҗемәсенең үзенчәлекләре турында мәгълүмат алалар. Тәрҗемәнең тәрҗемә телендә язмача яки телдән текст булуы һәм ул әлеге телдәге шундый ук тип текстларга куелган таләпләргә җавап бирергә тиешлеге төшендерелә. Студентлар, тәрҗемә теленең үз текстлары белән чагыштырганда, тәрҗемә текстларында күзәтелгән үзенчәлекләр, тәрҗемәләрнең халык әдәбиятында һәм мәдәниятендә аерым урын тотуы белән танышалар.

Тәрҗемәнең грамматик һәм стилистик аспектлары белән танышу

Студентлар тәрҗемәдә грамматик төзелмәләрнең роле, параллель һәм трансформацияләнгән төзелмәләр куллану, тәрҗемәдә сүз тәртибенә бәйле үзенчәлекләр, чыганак телнең аңлау һәм тәрҗемә итү өчен аерым кыенлыклар тудырган грамматик формалары һәм төзелмәләре турында мәгълүматлар алалар. Максималь синтаксик параллельлек таләп ителгән һәм тәрҗемәче оригинал эчтәлеген күчерү өчен грамматик структуралардан иркен файдалана ала торган очраклар күрсәтелә; төп стилистик фигуралар һәм алымнарны тәрҗемә итүдәге кыенлыклар һәм алымнар өйрәнелә; чыганак һәм тәрҗемә телләрендә охшаш стилистик чараларны кулланудагы аермалар билгеләнә.

Уку вакытының төп өлеше тәрҗемәченең һөнәри күнекмәләрен формалаштыруга бирелә. Бу бурыч гомуми тәрҗемә стратегиясен билгеләү осталыгын эшкәртүне дә, шул ук вакытта конкрет тәрҗемә кыенлыкларын җиңү осталыгы барлыкка китерүне дә үз эченә ала. Шул рәвешчә, тәрҗемә дәресләрендә эшкәртелә торган төп күнекмәләрне ике төркемгә бүләргә мөмкин: беренче төркемгә тәрҗемә алды анализы ясау өчен кирәк булган күнекмәләр керә, алар, тәрҗемәнең максаты, тәрҗемә ителә торган текстның тибы һәм рецепторларның характерына карап, гомуми тәрҗемә стратегиясен билгеләргә ярдәм итә. Икенче төркем күнекмәләр тәрҗемә процессында тәрҗемәченең эш-гамәлләрен билгели.

3.4. ТӘРҖЕМӘ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Тәрҗемә процессында аеруча кирәк булган күнекмәләрне үстерү булачак тәрҗемәчеләрне хәзерләүнең мөһим өлешен тәшкил итә. Бу күнекмәләр гомуми яки хосусый характерда булырга, эш-гамәлләрнең гомумән барысына да яки аерым бер төренә генә дә туры килергә мөмкин.

Тәрҗемә күнекмәләрен үстерүнең үзенчәлеге шунда, алар бары тик студентларның практик эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә, элеккеге тел күнекмәләренә һәм теоретик белемнәренә таянып формалаша.

Күнекмәләр формалаштыру – озакка сузылган, дәвамлы процесс. Аерым бер дәрестә теге яки бу күнекмәне үстерү максатын куярга мөмкин, әмма ул бу дәрестә генә тәмам формалашып җитәр дип ышану урынсыз. Еш кына гамәли күнегүләр башкарганда берьюлы берничә күнекмә үстерелә. Уңышлы тәрҗемәгә ирешүгә ярдәм итә торган барлык күнекмәләрне дә аерып чыгару һәм тасвирлау мөмкин түгел. Аларның күбесе комплекслы характерга ия һәм анализлап булмый. Шулай да кайберләрен карап үтик.

1. Ике телдә параллель эшләр башкару, бер телдән икенче телгә күчү осталыгы. Бу күнекмә икетеллелекнең үсеше нәтиҗәсендә кинәт кенә барлыкка килә, әмма аны профессиональ дәрәҗәгә үстерергә кирәк. Тәрҗемә тәңгәллекләрен һәм тәрҗемә алымнарын өйрәнү бу төр күнекмәләрне үстерүгә булыша ала, әмма аларны камилләштерүнең төп юлы – даими рәвештә ике тел белән эш итү, тулы текстлар яки фрагментлар тәрҗемә итү. Укытучы сөйләме дә бу процесста билгеле бер роль уйный. Мондый күнекмәләрнең асылы тәрҗемә теленең синонимик чараларын куллануга кайтып калганлыктан, дәресләрне тәрҗемә телендә алып бару максатка ярашлы санала. Телдән тәрҗемә күнекмәләрен үстерү өчен студентларга укытучы сөйләгәннәрне эчтән тәрҗемә итәргә кушып була. Бу очракта укытучы ике телдә чиратлап сөйләргә мөмкин.

2. Текстны тәрҗемәчеләргә хас булганча аңлый белү. Тәрҗемәче хәтта тәрҗемәнең беренче этапларында кабул итүче (рецептор) ролендә генә булса да, аның текстны аңлавы гадәти аңлаудан, беренче чиратта, тирәнлеге һәм тәмамланган булуы белән аерылып тора. Укытучы һәрдаим студентларга шуны искәртеп торырга тиеш: тексттагы тел берәмлекләренең мәгънәләре турында мәгълүматны алар берьюлы ике чыганактан – әлеге берәмлекнең төп, системалы мәгънәсеннән һәм кулланылган контексттан алырга тиеш. Телнең һәр берәмлеге бөтен тел коллективы өчен бердәй булган чагыштырмача стабиль, даими мәгънәгә ия. Сөйләшүчеләр, башкалар аларны дөрес аңласын дисәләр, сүзне үз мәгънәсендә кулланырга мәҗбүр. Сүз күпмәгънәле дә булырга мөмкин, әмма ул барыбер теләсә нәрсә аңлатмый. Текстта сүз үзенең бер яки ике

мәгънәсендә кулланылырга, яки контекстка бәйле рәвештә өстәмә мәгънә төсмере белән баетылырга мөмкин. Еш кына булачак тәрҗемәчеләр ике мәгълүмат чыганагы биргән бер мәгънәне күпертәләр: сүзнең сүзлектә теркәлгән мәгънәсенә генә басым ясап, контекстка игътибар итмиләр; яки контекстка туры килгән вариантны гына тәкъдим итеп, сүзнең төп мәгънәсен читтә калдыралар. Мондый очракларда укытучы студентка хатасын күрсәтә, бу ике момент ничек хәл ителергә тиешлеген дәлилли.

3. Тәрҗемә телендә синонимик төзелмәләр, синоним сүзләр рәтен төзү һәм алар арасыннан уңышлысын сайлап алу осталыгы. Тәрҗемә вариантларын дөрес сайлап алу һәр тәңгәллекнең мәгънәсен конкрет контекст белән чагыштыра белүгә бәйле.

4. Төп мәгънәдән баш тартмыйча гына читләшү. Туры тәңгәллек кулланып булмаганда, тәрҗемәче оригиналдан берникадәр читләшергә мәҗбүр, әмма ул барыбер чыганактагы мәгънәгә мөмкин кадәр якын булырга тырыша. Әлеге “аз югалтулар” стратегиясенә тел формасын үзгәртү, төрлеләндерү, шулай ук якынрак мәгънәле синонимнар куллану юлы белән ирешелә.

5. Тәрҗемәнең техник алымнарыннан дөрес файдалану. Техник компетенция – тәрҗемә эшен башкару өчен кирәкле булган махсус белемнәр, осталык һәм күнекмәләр. Аларга студентларны алдан өйрәтәләр. Текстны тәрҗемә иткәндә, укытучы чираттагы хәбәрләмәне тәрҗемә теленә күчерү өчен теге яки бу алымны кулланырга тәкъдим ясый яисә бу очракта кайсы алымны куллану уңышлырак икәнлеген сорый. Курсның программасына шулай ук тәрҗемәнең иҗади алымнарынан файдалану күнекмәләрен үстерү өчен махсус сайланган күнегүләр эшләү дә керә.

Тәрҗемәче стратегиясенең төп принциплары бер төркем техник алымнарны куллану дөреслеген дәлилләү белән тулылана. Бу техник алымнар тәрҗемәнең оригиналга формаль тәңгәллеген бозсалар да, эквивалентлыкның югары дәрәҗәсенә ирешүне тәэмин итәләр. Алар арасында иң киң таралганнары – тәрҗемә процессында лексик берәмлекләрнең урыннарын үзгәртү, өстәү һәм төшереп калдыру. Хәбәрләмәдәге лексик

бирәмлекнең *урынын үзгәртү* сүзләрнең үзара бәйләнешкә керә алу-алмауларына бәйле. Бу алым төрле грамматик алмаштырулар ярдәмендә дә башкарылырга мөмкин: мәсәлән, аергычны аерылмыш белән алмаштыру: *женщины работницы – эшче хатын-кызлар.* Кайчак тәрҗемәче аерым сүзләрне бер хәбәрләмәдән икенчесенә дә күчерә (бер үк сүзнең кабатлану, ике янәшә хәбәрләмәдә бер үк сүз кулланылу очрагы).

Лексик өстәлмәләр тәрҗемә процессында шулай ук киң кулланыла. Оригиналның тәрҗемәдә чагылыш тапмаган күп кенә мәгънә элементларын сүзләр өстәү юлы белән белдерергә мөмкин. Тасвирлаулар, аңлатулар да өстәмәгә керә.

Лексик төшермәләр – өстәмәләргә капма-каршы алым. Ул тәрҗемәдә семантик яктан артык сүзләрдән баш тартуны аңлата. Кайчак охшаш синонимнарның берсе төшеп кала; оригинал белән чагыштырганда, текстның күләме өстәлмәләр хисабына артып китү ихтималы булганда да төшереп калдыру алымы кулланыла.

Техник алымнардан тагын берсе рәвешендә *алмашлыкларны кабатлау* алымын атарга мөмкин.

6. Чыганак телнең лексик, фразеологик, грамматик һәм стилистик үзенчәлекләре белән бәйле кыенлыкларны җиңә белү күнекмәсе. Тәрҗемә теориясе мәгълүматларына нигезләнеп, укытучы студентларга әлеге тәрҗемә кыенлыклары очраган текстларны яки аерым хәбәрләмәләрне тәрҗемә итү күнегүләре оештыра.

7. Туган телгә тәрҗемә иткәндә үз фикерләреңне тәрҗемә телендә грамоталы һәм дөрес итеп белдерү осталыгы. Еш кына укытучыга махсус биремнәр ярдәмендә әлеге осталыкны үстерергә кирәк һәм ул даими рәвештә тәрҗемә теленең сыйфатына, аралашу һәм тел компетенциясен үстерүгә игътибар итәргә тиеш була. Туган телдән чит телгә тәрҗемә иткәндә мондый эш аеруча әһәмиятле. Әмма ул туган телгә тәрҗемә иткәндә дә бик кирәк.

8. Тәрҗемәченең үз эшен һәм чит тәрҗемәләрне редакцияләү, семантик һәм стилистик хаталарны табу, аларны төзәтү, тәкъдим ителгән вариантларны дәлилләп тәнкыйтьләү һәм бәяләү осталыгы. Уку барышында укытучы студентларга даими рәвештә үз вариантларын тәкъдим итәргә,

иптәшләренең тәрҗемәсе турында фикерләрен җиткерергә, киңәш-тәкъдимнәрен нигезләргә куша. Шулай ук студентларга типик тәрҗемә хаталары һәм хилафлыклар булган тәрҗемәләрне редакцияләү биремнәрен үтәтү дә уңышлы.

9. Сүзлекләрдән, белешмәләрдән, мәгълүмат банкларыннан һ.б. өстәмә чыганаклардан, төрле техник чаралардан (компьютер, диктофон һ.б.) оста файдалану.

10. Санап үтелгән күнекмәләр ***оригинал текстын анализлау осталыгы, стандарт һәм стандарт булмаган тәрҗемә проблемаларын билгеләү, аларны чишү юлларын сайлау*** белән берләшә. Бу осталык укытучы җитәкчелегендә төрле авырлыктагы текстларны тәрҗемә итү барышында формалаша. Әлеге эш тәрҗемәгә өйрәтү дәвамында алып барыла.

Тәрҗемәче-профессионал тиешле күнекмәләргә ия булу гына түгел, ә аларны тәрҗемә эшчәнлегендә куллана да белергә тиеш. Шунлыктан тәрҗемәгә өйрәткәндә бу күнекмәләрне үстерү өстендә эш алып барыла, ягьни тәрҗемәченең эш-гамәлләре автомат яки ярымавтомат характер алсын өчен тырышыла. Болар тәрҗемә күнекмәләрен куллануны күздә тоткан күнегүләр, билгеле бер күләмдәге тәрҗемәләрне тиешле срокка өлгертү белән бәйле практик биремнәр башкару аша тормышка ашырыла.

3.5. ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ КҮНЕГҮЛӘРЕ

Тәрҗемә курсының эчтәлегенә керәкле профессиональ белемнәр турында мәгълүмат бирү дә, тәрҗемә күнекмәләрен һәм осталыгын үстерү дә кирә. Тәрҗемә күнекмәләрен һәм осталыгын үстерү тәрҗемә курсының төп максатын тәшкил итә, чөнки алар тәрҗемәченең практик һөнәри эшчәнлегенә турыдан-туры булыша, аны тәэмин итә. Осталык һәм күнекмәләр махсус сайлап алынган уку материалын куллану нигезендә барлыкка килә. Мондый материалларга тәрҗемә күнегүләре һәм уку текстлары кирә.

Тәрҗемә күнегүләренең төрләре

Күнегүләр – тиешле осталыклар булдыруда төп ысул. Тәрҗемә осталыгы бәйләнешле текстлар тәрҗемә иткәндә дә үстерелә ала. Әмма теләсә кайсы текстны тәрҗемә итү бер төркем тәрҗемә бурычларын чишү белән бәйле була һәм кайсы да булса тәрҗемә проблемасы өстенлек иткән (күп булган) яки еш очраган текст табу шактый кыен. Махсус сайлап алынган күнегүләр укучыларның игътибарын аерым тәрҗемә проблемасына тупларга мөмкинлек бирә. Күнегүләр белән эшләү тәрҗемәгә өйрәтү курсының шактый өлешен алып тора. Бу вакытта тәрҗемә кыенлыкларын хәл итү ысуллары үзләштерелә, тәрҗемәнең техник алымнары эшкәртелә, тәрҗемә осталыгы үстерелә һәм тәрҗемә күнекмәләрен камилләштерү өчен нигез салына.

Башкарыла торган сөйләм гамәлләренең характерына карап, *тәрҗемә алды* (предпереводческий) һәм *тәрҗемә* (собственно переводческий) күнегүләре була. *Тәрҗемә алды күнегүләре*нең максаты – уңышлы тәрҗемә өчен шартлар тудыру, аралашуга тиешле юнәлеш бирү, студентларның тел һәм фон белемнәрен тикшерү, аларга тәҗрибәле, югары квалификацияле тәрҗемәчеләрнең типик тәрҗемә бурычларын ничек хәл итүләрен күрсәтү. Бу тип күнегүләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе – чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге параллель текстларны чагыштыру, аларның аермасын күрсәтү, басылып чыккан тәрҗемәләрне оригинал белән чагыштыру; тәрҗемәче кулланган метод һәм алымнарны тәнкыйть күзлегеннән анализлау, текстны аңлау тирәнлеген һәм фон белемнәрен тикшерүне күздә тоткан сорауларга җавап бирү, текст эчтәлегенең нигезендә яткан концепцияләрне тикшерү, аңа бәйле терминнарны һәм төшенчәләрне барлау, тәрҗемә теленнән белемнәр үзләштерүне камилләштерүгә караган күнегүләр эшләү (синонимик рәтләр төзү, синонимнарның мәгънә төсмерләрен аеру, вариантларга стилистик бәя бирү, хәбәрләрне үзгәртү, бирелгән темага чыгыш ясау һ.б.).

*Тәрҗемә күнегүләре*нең түбәндәге төрләре була:

- оригинал һәм тәрҗемә телләре берәмлекләренең, төзелмәләренең үзенчәлекләре белән бәйле тәрҗемә бурычларын хәл итү осталыгын үстерә торган *тел күнегүләре*;
- төрле тәрҗемә ысулларын һәм алымнарын куллану осталыгын эшкәртә торган *операцион күнегүләр;*
- тәрҗемә процессының төрле этапларында тиешле эш-гамәлләрне уңышлы башкару күнекмәләрен барлыкка китерә торган *коммуникатив күнегүләр.*

*Тел күнегүләре*ндәге биремнәрдә тәрҗемәдә аерым игътибар ителергә тиешле тел берәмлеге яки төзелмә күрсәтелә. Мондый күнегүләрдә студентның бурычы аерым тел берәмлекләрен тәрҗемә итү дә, хәбәрләмә составында бирелгән берәмлекләрнең һәм төзелмәләрнең мәгънәләрен күчерү, билгеле бер берәмлек-төзелмәләр булган хәбәрләмәләрне тәрҗемә итү дә булырга мөмкин.

Операцион күнегүләр тәрҗемәдә билгеле бер алымны куллану, аны сайлауны дәлилләү, бу алымны куллану ысулын аңлатуны күздә тота.

Коммуникатив күнегүләр тел берәмлекләренең контекстуаль мәгънәләрен ачыклау, хәбәрләмәнең мәгънәсен шәрехләү, тәрҗемә тәңгәллекләре сайлау, төрле авырлыктагы хәбәрләмәләр һәм текстлардан өзекләр тәрҗемә иткәндә тәрҗемә бурычларын комплекслы чишү кебек биремнәрне үз эченә ала. Башкача әйткәндә, мондый күнегүләр тулаем тәрҗемә процессының аерым этапларын башкару осталыгын үстерәләр.

Күнегүләр белән эшне оештыру

Һәр күнегү билгеле бер бурычны хәл итүгә юнәлтелә, ул, тибына карап, биремдә формалаштырыла. Әмма күп кенә очракларда биремнәр, төп бурыч белән беррәттән, тулы бер төркем өстәмә бурычлар чишүне дә таләп итә.

Кагыйдә буларак, күнегүләр билгеле бер тәрҗемә кыенлыгын үз эченә алган 15-20 җөмләдән гыйбарәт була. Алар төрле текстлардан сайлап алына, чөнки тиешле проблема җитәрлек күләмдә булган тоташ текст табу шактый кыен. Мондый күнегүләр өчен материал рәвешендә тел чараларын куллануда индивидуаль-автор үзенчәлекләре булмаган текст

алынырга тиеш. Контексттан өзеп алынган хәбәрләмәләрне куллану аларны аңлауда һәм тәрҗемә итүдә кыенлыклар тудыра. Бу кыенлыкларны өч төрле юл белән хәл итеп була:

1) тәмамланган, шәрехләү өчен зур контекст таләп итми торган җөмләләр сайлап алына. Кирәк очракта аерым җөмләне, эчтәлеген ачыклап, табигыйлыгын бозмыйча, бераз үзгәртергә мөмкин;

2) өстәмә мәгълүматны укытучы үзе хәбәр итәргә әзер булырга тиеш;

3) аңлауны һәм тәрҗемә вариантларын тикшерү.

Күнегүләр башкарганда укытучының комментарийлары әһәмиятле роль уйный. Хәбәрләмә контекстын тулыландырудан тыш, укытучы студентларга кирәкле фактик материалларны җиткерә, таныш булмаган реалияләрне аңлата, тел хаталарын төзәтә, анализлауда дөрес юлны күрсәтә һәм мөмкин булган тәрҗемә вариантларын сайлаша. Өйрәнелгән белемнәрне, алымнарны искә төшереп тору да мөһим.

Күнегүнең характерына карап, ул дәрестә эшләнергә дә, өй эше итеп бирелергә дә мөмкин.

Тел күнегүләре

Бу күнегүләр тәрҗемә телендә билгеле бер типтагы тел берәмлекләренең семантикасына һәм кулланыш үзенчәлекләренә бәйле кыенлыкларны хәл итү осталыгын үстерүне максат итеп куя. Аларны әлеге берәмлекләрнең характерыннан чыгып, *лексик, фразеологик, грамматик* һәм *стилистик* күнегүләр дигән төрләргә бүлү уңайлы.

Тәрҗемәнең лексик проблемалары төрле төр тәрҗемә тәңгәллекләрен үз эченә ала. Билгеле булганча, лингвистик тәрҗемә теориясе төп ике тип тәңгәллекне аерып чыгара:

- моноэквивалентлар (аларны сайлау контекстка бәйле түгел);
- полиэквивалентлар (тәңгәллек вариантлары). Боларны сайлау сүзнең төп мәгънәсен дә, кулланылган контекстны исәпкә алуны да таләп итә.

Тәрҗемәдә бу ике тип тәңгәллекне куллану күнекмәләре күнегүләр ярдәмендә ныгытыла. Моннан тыш, эквивалентсыз лексика тәрҗемәсенә һәм “тәрҗемәченең ялган дуслары” белән бәйле кыенлыкларны чишүгә махсус күнегүләр багышлана.

Моноэквивалентларга нисбәттә, тәрҗемәченең хәтерен төп тәңгәллекләр белән баету да тәрҗемәгә өйрәтү бурычына керә, чөнки аларны белми торып тәрҗемә итү мөмкин түгел. Шулай ук яңа моноэквивалентлар барлыкка китерү өчен транскрипция һәм калькалаштыру алымнарын куллануга бәйле тренировкалар ясау да әһәмиятле. Бу очракта ялгызлык исемнәре, географик атамалар, сәяси оешма, профсоюз, фирма, компанияләр һ.б. шундый оешма исемнәрен аерым тәрҗемә итү, хәбәрләмәләр эчендә тәңгәллек табу, терминологик диктант кебек күнегү төрләре файдалану нәтиҗәле.

Тәрҗемәдә тәңгәллек вариантларын куллану белән бәйле күнегүләр, беренче чиратта, сүзләрнең контекстуаль мәгънәләрен ачыклау күнекмәсен үстерүне күздә тота.

Сүзтезмәләр тәрҗемәсендәге кыенлыклар чыганак телдәге ирекле сүзтезмә типларының үзенчәлеге һәм фразеологизмнарны тәрҗемә итү проблемалары белән бәйле.

Эквивалентсыз лексиканың икенче телдә туры тәңгәллеге булмау әлеге берәмлек тәрҗемә ителми дигән сүз түгел, контекстта аны бирү мөмкинлеге һәрчак табыла. Тәрҗемә теориясе эквивалентсыз берәмлекләрне тәрҗемә итү өчен окказиональ тәңгәллекләр ясауның күп кенә ысулларын күрсәтә: алынма итеп алу, калькалаштыру, тәрҗемә телендәге аналогны файдалану, лексик-семантик алмаштырулар, тасвирлау.

Чыганак телдә ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләрне куллану үзенчәлегенә бәйле кыенлыкларны хәл итү күнегүләре *лексик* күнегүләр арасында аерым төркем тәшкил итә. Бу төр күнегүләр сүзтезмәләрне аерып алып тәрҗемә итүгә дә, хәбәрләмә яки текст өземтәсе составында тәрҗемә итүгә дә багышлана ала.

Тәрҗемәдәге *грамматик* проблемалар чыганак телнең тәрҗемә телендә тәңгәллеге булган формаларга һәм төзелмәләргә дә, шулай ук эквивалентсыз форма-төзелмәләргә дә карый. Димәк күнегүләрдә алар барысы да исәпкә алынырга тиеш. Модаль формаларның мәгънәләрен тәрҗемә итүгә аерым игътибар бирү мөһим.

Стилистика өлкәсенә караган күнегүләр оригиналдагы стилистик тамгаланган, аерымланган сүзләрнең мәгънәләрен күчерүгә юнәлтелергә тиеш. Шулай ук вакытта төрле стилистик

алымнарга (чагыштыру, метафора, сүз уйнату һ.б.) һәм синтаксик сурәтләү чараларына тәңгәллекләр эзләү күнегүләре дә үткәрелсә яхшы. Монда стандарт стиль чараларын тәрҗемә итүгә дә һәм индивидуаль-автор үзенчәлекләрен күчерүгә дә аерым игътибар бирелә. Тәрҗемәдә стилистик проблемаларны хәл итү оригиналның стилистик нюансларын төгәл һәм тулысынча күчереп булмауга бәйле югалтуларны компенсацияләүнең төрле юлларын иҗади файдалану осталыгын күздә тота.

Операцион күнегүләр

Бу тип күнегүләрнең максаты – теоретик курсларда өйрәнелгән тәрҗемә модельләрен, трансформацияләр һәм алымнарны практикада куллану осталыгын үстерү. Мондый күнегүләрне дүрт төркемгә бүлеп карарга була.

Беренче төркем күнегүләр тәрҗемәдә кулланылган метод һәм алымнарны тануга юнәлтелә. Моның өчен студентларга тәрҗемә хәбәрләмәләрен чыганак белән чагыштырып, һәр очракта нинди стандарт методлар кулланылуын билгеләргә кушыла. Әлеге күнегүләргә кергән хәбәрләмәләр бер ысул белән генә яки төрле ысуллар кулланып тәрҗемә ителгән булырга мөмкин. Бирелгән мисаллар үрнәк булу шарт түгел, әмма студентларга таныш алым кулланылуы ачык күренеп тору мөһим. Әгәр басылып чыккан тәрҗемәдән алынса, бигрәк тә отышлы.

Икенче төркем күнегүләрне башкарганда кулланылган тәрҗемә алымын тану гына түгел, аның уңышлымы-юкмы икәнен бәяләү дә таләп ителә. Мондый күнегүләрнең ике төре бар. Беренче очракта оригинал да, тәрҗемә дә бирелә һәм тәрҗемә алымын сайлауның дөреслеге бәяләнә. Икенче очракта студентлар бары тик оригинал белән генә эш итә һәм күрсәтелгән алымны куллану мөмкинлеген бәяли.

Өченче төркем операцион күнегүләрне башкарганда, тәрҗемәдә башка алымнар куллану мөмкин булса да, билгеле бер алымны куллану бурычы йөкләнә. Бу очракта тәрҗемә ителәсе материалдагы хәбәрләмәләр нәкъ менә күрсәтелгән алымны куллануны таләп итәргә тиеш.

Дүртенче төркем күнегүләр конкрет хәбәрләмәне тәрҗемә итү өчен иң уңышлы алымны сайлау күнекмәләрен

үстерү һәм куллануга юнәлтелә. Мондый күнегүләрне эшләгәндә студентлар кулланыласы алымны мөстәкыйль рәвештә билгелиләр.

Коммуникатив күнегүләр

Бу төр күнегүләрнең төп максаты – студентларны тәрҗемә процессында кирәк булган коммуникатив эш-гамәлләр башкарырга өйрәтү. Мондый эш-гамәлләр тәрҗемә процессында яки телара коммуникациядә катнаша торган ике телнең теләсә кайсысында үтәлергә мөмкин. Мөстәкыйль сөйләм гамәлләре таләп итә торган күнегүләрне берничә типка аерып карыйлар.

Беренче тип күнегүләр студентларның чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге төрле дәрәҗә берәмлекләр белән төрлечә эшләүне таләп итәләр. Мәсәлән, *сүз* дәрәҗәсендә түбәндәге биремнәрне үтәү максаты куелырга мөмкин: синонимик рәттәге сүзләрнең аермаларын аңлатырга; чыганак һәм тәрҗемә телләрендә параллель синонимик рәтләр төзергә һ.б. *Сүзтезмә* дәрәҗәсендә: чыганак телдә бирелгән сүзләрдән мөмкин булган сүзтезмәләр төзергә һәм тәрҗемә телендә аларның эквивалентлары бергә килә алу-алмау дәрәҗәсен күзәтергә; ике телдә мәгънәләре бердәй, әмма составлары белән аерыла торган сүзтезмәләр төзергә; тәрҗемә телендә эквиваленты булмаган тотрыклы сүзтезмәләр исемлеген булдырырга һ.б. *Грамматика* дәрәҗәсендә: бердәй грамматик категорияләрне (вакыт, заман һ.б.) белдерү ысулларын чагыштырырга һ.б.

Икенче төркем күнегүләр бирелгән текстлардагы тәрҗемә кыенлыкларын тануны һәм аларны тикшерүне күздә тота. Фикер алышу өчен гомуми проблемалар да, хосусый проблемалар да чыгарылырга мөмкин. Бер яктан, оригинал текстының максатын, тибын һәм шуларга бәйле тәрҗемә стратегиясе үзенчәлекләрен бәяләү бурычы куела ала. Икенче яктан, чыганак текстта булган үзенчәлекле лексик, грамматик һәм стилистик күренешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән аерым проблемалар турында фикер алышу тәкъдим ителә. Мондый күнегүләрнең гомуми максаты – текстка тәрҗемә алды анализы ясау күнекмәләрен үстерү.

Өченче төркем күнегүләр оригинал һәм тәрҗемә текстлары белән төрлечә эш итүне үз эченә ала. Боларга оригинал эчтәлегенең планын төзү, авторның әйтергә теләгән

төп фикерен формалаштыру, текстның эчтәлеген сөйләү һ.б. кирә. Тәрҗемә текстларына килгәндә исә, ул оригинал белән бергә дә, үзе генә дә бирелергә мөмкин. Бу вакытта түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итәргә була: текстны башкача сөйләп бирү, нормалардагы һәм узустагы хилафлыкларны төзәтү, текстны оригиналга якынайту, күздә тотылган мәгънәне әйтеп бирү һ.б.

Тәрҗемәгә куелган максатлар һәм күздә тотылган рецептор тибына бәйле рәвештә, бер үк текстны төрле ысуллар белән тәрҗемә итү күнегүләре *дүртенче төркемне* тәшкил итә. Максат сыйфатында тәрҗемә басылачак газета яки журналның характеры, тәрҗемәнең реклама, сәяси һәм пропаганда максатында кулланылу ихтималы күрсәтелергә мөмкин. Биремдә төрле яшьтәгеләр өчен, теге яки бу өлкәдә профессионаллар яки профессионал булмаганнар өчен дигән тамгалар да була ала.

Инде әйтеп үтелгәнчә, тәрҗемә курсының бурычы – махсус белем һәм осталык нигезендә автомат яки ярымавтомат тәрҗемә күнекмәләре үстерү. Шунлыктан тәрҗемә күнегүләре системасы дәрес вакытында төрле авырлыктагы һәм төрле күләмдәге текстларны даими рәвештә тәрҗемә итү белән тулыландырыла.

3.6. БӘЙЛӘНЕШЛЕ ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ

Күнегүләрдәге тәрҗемә кыенлыклары күзәтелгән аерым хәбәрләмәләр белән эшләү барышында осталык һәм күнекмәләр күпмедер дәрәҗәдә формалаштырыла. Әмма практикада тәрҗемәчегә аерым хәбәрләмәләрне генә түгел, бәлки тоташ текстларны да тәрҗемә итәргә туры килә. Шунлыктан тоташ текстлар белән эшләү тәрҗемәгә өйрәтүдә әһәмиятле урын тота.

Бәйләнешле тоташ текстны тәрҗемә итү тәрҗемә методларын һәм алымнарын комплекслы куллануны күздә тота, чөнки текст мәгънә һәм төзелеш ягыннан бербөтен тәшкил итә. Текстның төзелешеннән һәм мәгънәсеннән чыгып, тәрҗемәче теге яки бу алымны куллану мөмкинлеген һәм ничек куллану кирәклеген хәл итә. Конкрет текстның үзенчәлеге теге яки бу тәрҗемә алымын куллануга үзгәрешләр кертергә яки стандарт алымнардан бөтенләй баш тартырга һәм моңа кадәр кулланылмаган яңа юл табарга мәҗбүр итә. Шул сәбәпле текст

белән эшләү үзара бәйләнештә булган ике этаптан гыйбарәт. Бер яктан, укытучы гомуми тәрҗемә проблемаларын аерып билгели, ә икенче яктан, ул әлеге текстның тәрҗемәдә исәпкә алынырга тиеш булган үзенчәлекле билгеләренә игътибарны юнәлтә.

Инде алда әйтелгәнчә, тәрҗемәченең стратегиясе тәрҗемә ителә торган текстның характерына һәм андагы тәрҗемә кыенлыкларына гына бәйле түгел, ул тәрҗемә аталган рецептор тибын да күздә тотарга тиеш. Кагыйдә буларак, төп курста укытучы студентларга нинди дә булса конкрет рецепторны истә тотарга кушмый һәм тәрҗемә тел коллективының уртакул вәкиленә йөз тота.

Тоташ текст тәрҗемәсе өстендә эшләгәндә аудиториядә *аналитик* һәм *синтетик тәрҗемәләр* башкарыла. *Аналитик тәрҗемә* дәресләрендә укытучы ярдәмендә текстка җентекле анализ ясау, типик тәрҗемә кыенлыкларын һәм аларны чишү өчен стандарт ысулларны билгеләү, текстның индивидуаль үзенчәлекләрен ачыклау һәм шуларга бәйле конкрет тәрҗемә вариантларын табу күздә тотыла. *Синтетик тәрҗемә* эшләгәндә студент мөстәкыйль рәвештә билгеле бер күләмдәге текстны билгеле бер вакыт эчендә тәрҗемә итә, аннары аның эшен укытучы тикшерә, ахырдан ул студентның барлык уңышларын һәм уңышсызлыкларын күрсәтеп бирә.

Аналитик тәрҗемә (анализлы тәрҗемә) алдан җитди хәзерлек таләп итә. Иң элек студентлар өчен эчтәлеге дә кызыклы һәм типик тәрҗемә кыенлыклары да булган текст табу мөһим. Укытучы анализ вакытында кайсы кыенлыклар тикшереләчәген, һәр очракта нинди алымнар кулланылачагын, нинди лингвистик һәм фактологик комментарийлар кертергә кирәк булачагын алдан ук хәл итә. Мондый дәресләрнең максаты – җөмләләрне күбрәк тәрҗемә итү түгел, бәлки күпсанлы тәрҗемә алымнарын һәм ысулларын кулланырга өйрәтү.

Текст белән эшли башлаганчы тәрҗемә алды анализы эшләнә: укытучы ярдәмендә студентлар текстның темасын, характерын һәм төзелешен ачыклыйлар, тәрҗемә максатын һәм күздә тотылган рецепторны билгелиләр. Кирәк булса укытучы студентларга өстәмә фактик мәгълүмат җиткерә яисә аны студентларга мөстәкыйль рәвештә табарга куша. Алдагы дәрескә

студентлар текст тәрҗемәсенең беренче вариантын алып киләләр. Укытучы аларның эшләрен тикшереп биргәннән соң, тәрҗемәләр дәрестә анализлана. Башта текстта кыенлык тудырган хәбәрләмәләр тикшерелә, соңыннан фраза арты фраза тәрҗемәләре анализлана: бер студент үз тәрҗемәсен укый, икенчесе фикерләрен әйтә, кимчелекләрне күрсәтә, үз вариантын тәкъдим итә. Башкалар бу вариантларны бәяли.

Мондый эшнең максаты – студентларны мөстәкыйль рәвештә тәрҗемә проблемаларын билгеләргә һәм аңлы рәвештә аларны хәл итү юлларын табарга өйрәтү. Шунлыктан:

1. Укытучы үз фикерен көчләп такмый, аларны мөмкин булган бер вариант буларак кына тәкъдим итә.
2. Үз фикерен әйткәнче, укытучы фикер алышу вакытында студентларны дөрес вариантка якынайтырга тырыша.
3. Студент тәкъдим иткән теләсә нинди вариант турында фикер алышына һәм бәяләнә. Тәнкыйть сак кына, укучы хәтерен калдырмаслык итеп кенә ясала. Әгәр студентны ышандырып булмаса, аңа укытучының дәлилләрен тагын бер кат күздән кичерергә вакыт бирелә.

3.7. ТЕЛДӘН ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ

Телдән тәрҗемә тәрҗемәчегә бер төркем үзенчәлекле таләпләр куя һәм студентларны бу төр тәрҗемәгә өйрәтү аның спецификасын күздә тотарга тиеш. Телдән тәрҗемәнең язма тәрҗемәдән аермасы яшәү-саклану һәм барлыкка килү вакытында чагыла. Язма тәрҗемәдә оригинал да, тәрҗемә дә теркәлгән була (язма текст). Бу тәрҗемәчегә оригиналны тулаем кабул итәргә, аңа кабат-кабат әйләнеп кайтырга, аның эчтәлеген һәм формасын анализларга, текст мәгънәсен тирәнрәк аңларга һәм төзәтүләр кертергә мөмкинлек бирә. Тәрҗемә тексты белән дә шулайрак тора: тәрҗемәче үзе тәрҗемә иткән текстка берничә тапкыр әйләнеп кайта, аны оригинал белән чагыштыра, кирәкле үзгәрешләр кертә. Язмача тәрҗемә тәрҗемәчегә уңайлы темпта башкарыла, чагыштырмача ирекле вакыт чикләрендә эшләнә, тәрҗемәче сүзлек һәм башка белешмәләрдән файдалана, киңәш сорап бүтән белгечләргә мөрәҗәгать итә ала һ.б.

Телдән тәрҗемә бөтенләй башка шартларда башкарыла. Монда оригинал һәм тәрҗемә телдән сөйләм кисәкләре рәвешендә яши, шунлыктан кире кайту һәм төзәтү мөмкинлеге булмый. Тәрҗемә вакытында сүзлектән дә файдаланылмый. Оригинал текстын тәрҗемәче өлешләп кабул итә, ул ишеткәнен тулы текст эчтәлеге белән бәйләп карый алмый. Тәрҗемә итү вакыты кискен чикләнгән, уйларга, тәрҗемә вариантлары сайларга вакыт юк, тәрҗемә темпын ораторның сөйләм тизлеге билгели. Тәрҗемәченең хәтеренә, телдән сөйләмнең төрле формаларын кабул итү сәләтенә, сөйләү манерасына, тәрҗемәне телдән ачык һәм дөрес итеп җиткерүенә, зур аудитория каршында чыгыш ясавына аерым таләпләр куела. Телдән тәрҗемәдә тәрҗемәченең эш шартлары, техник чараларның төзеклеге, комачаулыклар булмау аерым әһәмият ала. Болар барысы да махсус күнегүләр ярдәмендә булачак тәрҗемәчеләрдә тиешле күнекмә-осталыклар булдыруны күздә тота.

Күнекмә-осталыклар теләсә нинди тәрҗемәне башкару өчен дә кирәк, алдагы бүлекләрдә аларны тасвирлаганда күбрәк язма тәрҗемә күздә тотылган иде. Әмма телдән тәрҗемә ситуациясе бу төр тәрҗемә өчен тәрҗемәчеләрне махсус хәзерләү зарурлыгын ачык күрсәтә. Телдән тәрҗемә үзенчәлекләрен анализлау телдән тәрҗемә итүчеләр ия булырга тиешле ***дүрт тип күнекмә***не аерырга мөмкинлек бирә. *Беренчедән*, телдән тәрҗемә итүче алда әйтеп үтелгән, барлык төр тәрҗемәләр өчен мөһим булган күнекмәләрнең барысына да ия булырга тиеш. Оригинал текстын җентекләп анализлау, аны тәрҗемә тексты белән кат-кат чагыштыру, текстка төзәтмәләр кертү күнекмәләре генә искәрмәне тәшкил итә. Телдән тәрҗемә текстны бер мәртәбә генә кабул итү һәм бер үк вакытта тәрҗемә текстын да барлыкка китерү белән характерлана. Кагыйдә буларак, монда оригиналга яки тәрҗемәгә икенче тапкыр кайтып булмый. Күп очракта тәрҗемәче оригинал текстын тулаем белмәгән, күрмәгән хәлдә, өлешләп, кисәкләп тәрҗемә итә. Бу хәл телдән һәм язмача тәрҗемәләрнең икесе өчен гомуми булган күнекмәләрнең санын чикли.

Икенчедән, язмача тәрҗемә өчен дә, телдән тәрҗемә өчен дә кирәк булган күнекмәләр бар, тик алар да телдән тәрҗемә очрагында бераз үзгәртү таләп итәләр. Мәсәлән, һәр тәрҗемә бер

телдән икенче телгә күчү, телара коммуникацияне тормышка ашыру осталыгын сорый. Әмма телдән тәрҗемәдә бу бик кыска вакыт аралыгында башкарылырга, автомат рәвештә эшләнергә тиеш. Башкача әйткәндә, монда осталыкның күнекмәгә әйләнүе кирәк.

Бу шулай ук төрле тел материаллары белән эшләгәндә дә, оригиналдагы тел берәмлекләренең мәгънәләрен аңлатканда һәм аларга тәрҗемә телендә эквивалентлар сайлаганда да мөһим. Телдән тәрҗемә вакытында бу эшләр автомат яки ярымавтомат рәвештә эшләнергә тиеш.

Өченчедән, телдән тәрҗемә үзенчәлекләре һәм аның барлык төрләре өчен әһәмиятле булган аерым бер төркем осталыкларны үстерергә кирәк. Телдән тәрҗемә барыннан да элек төрле темпта һәм төрле үзенчәлекләр белән яңгыраган телдән сөйләмне тиз һәм адекват аңлауны таләп итә. Бу тулы кыйммәтле ишетү осталыгын, күнекмәсен үстерү зарурлыгын китереп чыгара. Алга таба телдән тәрҗемәнең барлык төрләрендә дә тәрҗемәченең хәтере (кыска вакытлы, оператив яки озакка сузылган) әһәмиятле роль уйный. Шунлыктан булачак тәрҗемәчеләрнең профессиональ хәтерен, берникадәр күләмдәге эчтәлекне (оригинал телендә белдерелүен түгел!) истә калдыру сәләтен үстерү өстендә махсус эшләү мөһим. Һәм, ниһаять, телдән тәрҗемә тәрҗемәне әйтмә формада җиткерә белү осталыгын күздә тота. Тәрҗемәче туган телендә һәм чит телдә дөрес сөйләм техникасын белергә, ике телдә дә кирәкле актив сүзлек һәм төзелмәләр запасын үзләштерергә, үз фикерләрен төрле рәвештә формалаштыра алырга, төрле аудитория каршында һәм төрле шартларда чыгыш ясау осталыгына ия булырга тиеш.

Дүртенчедән, телдән тәрҗемәнең һәр төрендә аерым үзенчәлекләр булырга мөмкин, аларның һәркайсы махсус осталыклар булдыруны таләп итә. Алар күп очракта берьюлы берничә эшне башкару, төрле тип сөйләм операцияләрен берләштерү белән бәйле була. Бу бер үк вакытта тыңлау һәм сөйләү (синхрон тәрҗемә), сөйләү һәм уку (кәгазьдән карап тәрҗемә итү), тыңлау һәм язманы кодлаштыру, язманы аңлау һәм сөйләү (эзлекле тәрҗемә) булырга мөмкин. Осталык-күнекмәләрнең әлеге классификациясе аларның үзара бәйләнгән

булуын да күрсәтә: һәр яңа төркем осталыкны үстерү тәрҗемәче инде аңа кадәр үзләштергән төркемдәге осталыкка нигезләнә. Бу тәрҗемәнең төрле төрләренә өйрәтүнең эзлеклелеген күрсәтә: башта тәрҗемәнең гомуми һәм гадирәк осталык таләп иткән төрләре өйрәнелә, аннары инде үзенчәлеклерәк төрләр үзләштерелә. Тәрҗемәгә өйрәтүдә түбәндәге тәртип нәтиҗәле һәм уңышлы санала: язмача тәрҗемә – аерым фразаларны ишетеп тәрҗемә итү (язмыйча гына эзлекле тәрҗемә итү) – ике яклы тәрҗемә – кәгазь буенча тәрҗемә итү – язып эзлекле тәрҗемә итү – күрмә таяныч ярдәмендә синхрон тәрҗемә итү – турыдан-туры (таянычсыз) синхрон тәрҗемә. Әлеге эзлеклелек телдән тәрҗемәнең беренче төре үзләштерелеп беткәч кенә икенчесенә күчәргә кирәк дигәнне аңлатмый. Параллель рәвештә берничә төр тәрҗемәне өйрәтү дә планлаштырыла ала. Әмма соңгы өчесе аеруча катлаулы төрләр, шунлыктан аларны укуның соңгы этапларында үзләштерү кулай.

Телдән тәрҗемәнең аерым төрләренә кыскача гына тукталып үтик.

1. Ишетеп тәрҗемә итү (аерым фразаларны һәм кечкенә абзацларны эзлекле тәрҗемә итү).

Үтәлү шартлары: оратор (сөйләүче) бер яки мәгънәләре белән бәйле берничә фраза әйтә һәм пауза ясый, шуннан соң тәрҗемәче аралашуда катнашучы оригинал телен белмәгән башка кешеләргә ишеткәннәрен тәрҗемә итеп бирә.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- оратор сөйләмендәге үзенчәлекләр (бик кызу темп, начар дикция, акцент, дөрес булмаган сөйләм);
- оратор вакытында тукталыш ясамау яки пауза ясарга теләмәү белән бәйле рәвештә, тәрҗемә ителә торган өлешнең күләме артык зураеп китү;
- оратор сөйләмендә ишетеп начар аңлана торган, контексттан аерып алып булмый торган берәмлекләр – атамалар, дата, сан һ.б. (прецизион лексика) кулланылу;
- эш шартлары: зур аудитория, чит тавышлар, нерв киеренкелеге тудыра яки җаваплылык хисен арттыра торган факторлар булу һ.б.;

- тәрҗемәченең үз-үзен тотышына аерым таләпләр куелу: үзен тыйнак, әмма иркен тоту, ишарәләр ясаудан тыелу, тавышның көче белән идарә итә белү, урынны дөрес сайлау һ.б.

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- оратор сөйләмен алдан ишетү, аның сөйләм манерасы белән алдан танышу мөмкинлеге;
- аудиториянең реакциясен исәпкә алу мөмкинлеге;
- кайбер очракларда яңадан сорау һәм тәрҗемәгә төзәтмә кертү мөмкинлеге.

Таләп ителә торган осталыклар:

- телдән йөгерек сөйләмне яхшы аңлау;
- бер үк вакытта тыңлау, эчтән тәрҗемә итү һәм хәтердә калдыру;
- тәрҗемә телендә иркен һәм дөрес сөйләшү;
- прецизион сүзләрне төгәл истә калдыру һәм тәрҗемә итү (язма таяныч куллану ихтималы булырга мөмкин).

2. Ике яклы тәрҗемә.

Үтәлү шартлары: үз туган телләрендә сөйләшүче ике яки берничә кешенең үзара әңгәмәсе. Тәрҗемәче чагыштырмача кыска хәбәрләмәләрне әле бер, әле икенче телгә тәрҗемә итә.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- шул ук телдә сөйләшүчеләр белән шәхсән аралашканда саксыз сөйләшү;
- әңгәмәдәшенең аерым белемнәрен күздә тоткан кыска, тәмамланмаган репликалар;
- берничә кешенең берьюлы сөйләшүе;
- тәрҗемәченең кайбер сөйләшүчеләрне күрергә һәм ишетергә комачаулый торган урында торуы (утыруы).

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- тәрҗемәченең әңгәмәдә турыдан-туры катнашуы, кирәк булганда әйтелгәнне ачыклау һәм тәрҗемәне төзәтү мөмкинлеге;
- алдан ук әңгәмә темасын һәм катнашучыларның аңа карата позициясен белү мөмкинлеге;
- аудитория чикләнгән булу һәм халык алдында чыгыш ясау осталыгын таләп итми торган формаль булмаган обстановка.

Таләп ителә торган осталыклар: ишетеп тәрҗемә итүдәге кебек, шуларга бер телдән икенче телгә тиз генә күчү өстәлә.

3. Кәгазь буенча тәрҗемә итү.

Үтәлү шартлары: тәрҗемәчегә таныш булмаган текст яки тәрҗемә итәр алдыннан гына чыгышның тексты бирелә. Күзләре белән эчтән генә укып, ул текстны тәрҗемә телендә язылган кебек "укый", тәрҗемә итә.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- сөйләгәндә тигез темп саклау зарурлыгы, кирәкмәс паузалар, кабатлаулар һәм төзәтүләрдән тыелу;
- тиз уку зарурлыгы (уртача сөйләм тизлеге – минутына 100 сүз булган очракта, минутына 200 сүз уку);
- бер үк вакытта уку, тәрҗемә итү һәм тәрҗемәне әйтеп бирү (сөйләү);
- укыганда текстны уңышлы тәрҗемә ителә торган кисәкләргә бүлгәләү.

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- оригиналның алдагы кисәген үзең теләгән күләмдә кабул итәргә мөмкинлек бирә торган күрмә таяныч булу;
- прецизион сүзләрне күреп кабул итә алу мөмкинлеге (бу аларны тәрҗемә итүне бермә-бер җиңеләйтә);
- тәрҗемә темпын мөстәкыйль билгели алу мөмкинлеге.

Таләп ителә торган осталыклар:

- әзер тәңгәллекләрне ярымавтомат кую мөмкинлеген иркен кулланып, бер телдән икенче телгә тиз генә күчү;
- тәрҗемәне сөйләп бирү белән бергә оригиналның алдагы кисәген уку;
- эчтән тиз уку.

4. Яза барып эзлекле тәрҗемә итү.

Үтәлү шартлары: оратор шактый озак вакыт дәвамында (25-30 мин.) сөйли, тәрҗемәче эчтән генә тәрҗемә итә, язып бара. Шуларга нигезләнеп, сөйләүче чыгышыннан соң тәрҗемә итеп бирә. Куелган бурычларга бәйле рәвештә, мондый тәрҗемә тулы яки кыскартылган формада була.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- чыгышның озак вакытка сузылуы. Бу хәтергә зур көч китерә, тәрҗемәченең дикъкатен һәм нервларын киеренкеләндерә;
- катлаулы шартлы код кулланып, озак вакыт язып бару;
- ораторның сөйләм тизлеге зур булу, аны тәрҗемәченең үзенә яраклаштыра алмавы;
- зур аудитория, кирәкле элементларны саклап калып, кыскартып тәрҗемә итү зарурлыгы һ.б.

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- җентекләп эшкәртелгән кыскартып язу системасы;
- тәрҗемәнең темпын һәм формасын мөстәкыйль билгеләү мөмкинлеге;
- тәрҗемә процессының әһәмиятле компонентларын эшкәртү юнәлешендә алдан тренировкалар ясау мөмкинлеге (тыңлап кабул итү, истә калдыру, кодлаштыру, кодны чишү, телдән сөйләм техникасы).

Таләп ителә торган осталыклар:

- язмыйча гына ишетеп тәрҗемә иткәндәге кебек үк;
- тиз һәм дөрес язып бару;
- зур гына күләмле телдән сөйләмнең төп эчтәлеген истә калдыру;
- бер үк вакытта язманың “кодын” чишү һәм тәрҗемәне сөйләп бирү;
- эзлекле килгән хәбәрләмәләрнең мәгънәсен гомумиләштерү.

5. Күрмә таяныч ярдәмендә синхрон тәрҗемә итү.

Үтәлү шартлары: тәрҗемәчегә колакчыннар (наушник) бирелә, шуның аша ул ораторның сөйләмен ишетә һәм алдан бирелгән чыгыш текстына таянып, 2-3 секунд аерма белән, тәрҗемәне микрофонга сөйләп бара.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- игътибарның өчкә бүленүе – бер үк вакытта тыңлау, уку һәм сөйләү;
- ораторның бик тиз яки акрын сөйләве;
- оратор сөйләмен кабул итүгә комачаулый торган сөйләм кимчелекләре яки акцент;
- тиз ардыра торган көчле нерв киеренкелеге;

- ораторның тексттан читләшүе, кайбер өлешләрен төшереп калдыруы яки өстәве;

- аппаратурадагы җитешсезлекләр.

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- оратор сөйләменең төзелеше параллель төзелмәләр кулланырга мөмкинлек бирү;

- чыгышның тиешле паузалар кулланып, тигез темпта баруы;

- тәрҗемәченең фикер алышу проблемасын, ораторның карашларын һ.б. факторларны белүе;

- алдан җентекләп хәзерләнү – көн тәртибе, проблематика, документлар һ.б. белән танышу, терминологияне, кулланылган кыскартылмаларны, һөнәри жаргоннарны һ.б. өйрәнү;

- тәрҗемәне тәрҗемәчеләр “командасы” белән башкару (20-30 минут саен тәрҗемәчеләрнең алышынуы күздә тотыла);

- синхрон тәрҗемә техникасын һәм алымнарын яхшы белү.

Таләп ителә торган осталыклар:

- ишетеп һәм кәгазь буенча тәрҗемә итү таләп итә торган осталыклар җыелмасы;

- берьюлы ишетү, уку, күрү һәм сөйләү сәләте;

- стандарт клише һәм даими тәңгәллекләрне яхшы белеп, тиз генә тәрҗемә итү;

- ишетеп кабул ителгән текстны кисәкләргә бүлгәли белү;

- ишеткәннең мәгънәсен гомумиләштерү;

- тыңлаучыларга сиздермичә генә ялгыш башланган тәрҗемәне төзәтеп җибәрү;

- оригиналның сыйфатына карамастан, дөрес һәм тәмамланган фразалар төзи белү һәм тыңлаучыларга җиткерү.

6. Турыдан-туры синхрон тәрҗемә.

Үтәлү шартлары: алдагысына охшаган, ләкин текст биреп куелмый, ишеткән буенча гына тәрҗемә ителә. Кагыйдә буларак, бу вакытта тәрҗемәче кабинада утыра. Шулай ук бу төр тәрҗемә “пышылдау” ысулы белән дә башкарылырга мөмкин,

ягъни тәрҗемәче тәрҗемә рецепторы белән янәшә утыра һәм ишеткәнен аңа пышылдап тәрҗемә итеп бара.

Тәрҗемәне катлауландыра торган факторлар:

- шулар ук;
- пышылдаганда ораторны төрле шау-шу эчендә “колакчын”нарсыз тыңлау;
- оратор сөйләменең характерына һәм дөреслегенә зур бәйлелек.

Тәрҗемәне җиңеләйтә торган факторлар:

- күрмә таяныч белән синхрон тәрҗемә итүдәге кебек үк.

Таләп ителә торган осталыклар:

- текст белән эштән кала, барысы да шулар ук;
- теләсә нинди сөйләм төрләрен иркен һәм төгәл кабул итү;
- прецизион сүзләрне ачык танып алу һәм кирәк булганда теркәп кую;
- кирәк булса, чит телдән чит телгә уңышлы тәрҗемә итү.

Телдән тәрҗемәгә өйрәтү күнегүләре

Телдән тәрҗемәнең төрле төрләрен башкару осталыгы уку-укыту барышында махсус күнегүләр ярдәмендә үстерелә, бу эштә шулай ук аерым төр тәрҗемәләрне башкарырга өйрәтүләрнең (тренировкаларның) дә роле зур. Бер үк төр күнекмәләрне үстерү төрле тәрҗемәләрне башкару өчен кирәк булганлыктан, күнегүләр системасын осталык төренә карап оештыру мөһим. Бу очракта түбәндәге күнегү төрләрен аерып чыгарырга мөмкин.

Ишетеп кабул итү күнекмәләрен үстерү күнегүләре.

1. Аудиоязманы язмача тәрҗемә итү.
2. Тәрҗемә-диктант.
3. Прецизион сүзләрне тәрҗемә итү.
4. Тәрҗемә-эчтәлек.
5. Абзац-фразаны ишетеп тәрҗемә итү.
6. Катлаулы аудирование күнегүләре (текстның эчтәлеген башта татарча, аннары русча сөйләү).

Эш-гамәлләрне берьюлы үтәү күнегүләре

1. Текстны күз белән исәпләп кабул итү.

2. Катып калган штампларны һәм псевдоинтернациональ сүзләр, сүзтезмәләрне эшкәртү өчен, ишетеп (өйдә – язудан) тәрҗемә итү.

3. Символларга дешифровка ясау.

4. Язмача текстны кодлаштыру.

5. Телдән текстны кодлаштыру.

6. Гадиләштерелгән тәрҗемә (текст белән яки тексттан башка).

Сөйләм техникасына күнегүләр

1. Хәбәрләмәне төрле вариантларда бирүгә караган күнегүләр.

2. Сүзгә-сүз тәрҗемәдән котылу буенча күнегүләр.

3. Риторик күнегүләр (этикет формулалар).

Мондый күнегүләр, аудиториянең үзенчәлекләренә карап, төрле эзлеклелектә үтәлә ала. Синхрон тәрҗемәчеләр әзерләгәндә болардан тыш язма тәрҗемәдән телдән тәрҗемәгә күчүне күздә тоткан күнегүләр башкару кулай. Бу очракта күнегүләрнең максатын ачык билгеләү мөһим. Телдән тәрҗемәгә түбәндәге эзлеклелектә өйрәтергә була.

1. Телдән сөйләмне тәрҗемә итәргә өйрәнү.

Максат: студентларны язма текстка бәйлелектән коткару һәм тәрҗемә процессында текстка кат-кат мөрәҗәгать итү мөмкинлегеннән коткару. *Күнегү төре:* тәрҗемә-диктант. Диктант җөмләләре өч тапкыр укыла: гадәти тизлектә, диктант яздыру тизлегендә һәм тагын гадәти тизлектә. Студентлар ишеткәннәрен язмача тәрҗемә итәләр. Тәрҗемәләр тикшерелә һәм фикерләр әйтелә.

2. ***Кәгазь буенча тәрҗемә итәргә өйрәнү.***

Максат: күрмә таянычны саклаган хәлдә, студентларны ашыкмыйча гына язма рәвештә тәрҗемә итүдән һәм тәрҗемәне кабат төзәтү, яхшырту мөмкинлегеннән биздерү. Бу күнегүне эшләгәндә булачак тәрҗемәчеләр фикерләрен тиз генә, курыкмыйча карар кабул итүгә туплыйлар. *Күнегү төре:* студентларга оригинал текстыннан өзекләр (соңрак тәмамланган кечкенә күләмле текстлар) тәкъдим ителә һәм аны алдан әзерләнмичә телдән тәрҗемә итү бурычы куела. Студентлар тәрҗемә вариантларын тиз генә табарга, сөйләм тизлеген

мөстәкыйль көйләргә, аңлау һәм тәрҗемә итү арасындагы вакыт каршылыгын чишәргә өйрәнәләр.

3. ***Эзлекле тәрҗемә итәргә өйрәтү.***

Максат: язма тәрҗемә (тексттан текстка) күнекмәләреннән тулысынча телдән тәрҗемәгә күчүне тәгәлләү. Әмма монда синхрон тәрҗемәдәге ике төп кыенлык булмаска тиеш: бер үк вакытта ишетү һәм сөйләү (игътибарның бүленүе); чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге структур аермалыкларны тиз генә хәл итү зарурлыгы. Бу вакытта шулай ук эзлекле профессиональ тәрҗемәдәге хәтергә таяну һәм үзенчәлекле язу системасыннан файдалану да күздә тотылмый. Моннан тыш, әлеге төр күнегүләр студентларда аерым сүз һәм сүзтезмәләрне генә түгел, бәлки мәгънәви тәмамланган төркемнәрне “эләктереп” алу осталыгын да үстерә. *Күнегү төре:* текстның истә калдыру өчен артык кыен һәм зур булмаган өзекләре кычкырып укыла. Студентлар кичекмәстән телдән тәрҗемә итәләр, тәрҗемәләр магнитофон тасмасына языла барыла, соңыннан анализлана. Төркемдәге студентларны активлаштыру өчен, җавап бирүче ахырдан гына билгеләнә.

4. ***Ярым синхрон тәрҗемәгә өйрәтү.***

Максат: синхрон тәрҗемәнең бер кыенлыгын (чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге структур аермалыкларны хәл итү зарурлыгын) аерып чыгару, икенче кыенлыкка (бер үк вакытта тыңлау һәм сөйләүгә) игътибар итмәү. Укыту максатларында, бу төр күнегүләрне эшләгәндә студентлар тәрҗемәләрен язмача теркәп барырга мөмкин, бу аларга соңрак нәтиҗәләрне анализларга ярдәм итәчәк. *Күнегү төре:* җөмләләр кыска кисәкләргә бүленә һәм диктант яздыру тизлегендә бер генә тапкыр (!) чиратлап укыла. Һәрбер өзекне укыганда студентлар тәрҗемәләрен шунда ук яза барырга яки икенче өзекнең укылганын көтәргә мөмкин. Бу вакытта студентлар язмаларны төзәтергә тиеш түгел.

Шул рәвешчә, студентлар, нормаль сөйләм тизлегенә өлгерү һәм бер үк вакытта ишетү, сөйләү зарурлыгыннан башка гына, синхрон тәрҗемәнең төп бурычын хәл итәргә өйрәнәләр.

5. ***Гадиләштерелгән синхрон тәрҗемәгә өйрәтү.***

Максат: синхронлык элементларын кулланып, язмача тәрҗемәдән телдән тәрҗемәгә күчүне тулысынча тәмамлау. Бу

этапта сүз тәртибен үзгәртү, структур яктан үзгәрешләр әле булырга мөмкин. Студентлар берьюлы ишетү һәм сөйләү күнекмәләрен үзләштерүгә төп игътибарны юнәлтәләр. *Күнегү төрләре:* студентларга ораторларның оригинал чыгышлары тәкъдим ителә. Баштарак мондый текстлар параллель төзелмәләрне куллануга җайлаштырылган була, соңга таба исә катлаулырак чыгышларны тәрҗемә итү күнегүләре бирелә.

*6. **Синхрон тәрҗемәнең төрле төрләренә өйрәтү.***

Максат – төрле шартларда эшләгәндә очрый торган үзенчәлекле кыенлыкларны хәл итү күнекмәләрен үстерү.

"Текст белән" синхрон тәрҗемә итү:

- әзерләнергә вакыт биреп тәрҗемә итү;
- алдан әзерләнмичә тәрҗемә итү;
- алдан кыскача әзерлек белән тәрҗемә итү.

"Пилот" ярдәмендә синхрон тәрҗемә итү: тәрҗемәче ораторның телен белми һәм өченче телдә эшли торган берәр хезмәттәшенең тәрҗемәсе аша тәрҗемә итәргә мәҗбүр була.

Күнегү төре: студентларны чыганак текстлары белән тәэмин итү һәм танышу өчен бирелгән вакытны төрлечә үзгәртү. Оратор үз текстыннан читләшкән вакытта тәрҗемәче алдында туган кыенлыклар белән таныштыру. Уку-укыту шартларында "пилот" ярдәмендә тәрҗемә итү күнегүләре башкару.

Алда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, телдән тәрҗемә күнекмәләрен үстерү шактый гына укыту вакытын бүлү һәм эшне дөрес итеп оештыру, кирәкле материалларны әзерләү өчен укытучыдан күп көч таләп итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Дөньяда күпсанлы тәрҗемәчеләргә ихтыяҗ кайчан туа?
2. Тәрҗемәгә өйрәтү мөмкинме?
3. Тәрҗемәгә ни өчен өйрәтергә?
4. Тәрҗемәгә өйрәтү барышында нәрсәгә өйрәтергә?
5. Тәрҗемәгә өйрәтү методлары һәм алымнары нәрсәгә нигезләнә?
6. Аралашучыларның тел компетенциясе нидән гыйбарәт?
7. Аралашу компетенциясе нинди булырга тиеш?

8. Аралашучыларның текст оештыру компетенциясенәниләр кирә?

9. Икетелле аралашуның төп үзенчәлекләрен әйтеп бирегез.

10. Тәрҗемә эшчәнлегенең күптөрлелеген исбатлагыз.

11. Тәрҗемәче компетенциясе нинди сыйфатларны берләштерә?

12. Тәрҗемәгә өйрәтү методикасы фәненең эчтәлеге нидән гыйбарәт?

13. Тәрҗемәче нинди күнекмәләргә ия булырга тиеш?

14. Тәрҗемәгә өйрәтү күнегүләренең нинди төрләре бар? Аларны чагыштырып сурәтләгез.

15. Бәйләнешле текст белән эш ничек оештырыла?

16. Телдән тәрҗемәнең төрләре һәм аларның үзенчәлекләре.

17. Телдән тәрҗемәгә өйрәтү күнегүләренең төрләре.

18. Телдән тәрҗемә төрләренә өйрәтүнең эзлеклелеге (схемасы).

Бүлек буенча өстәмә әдәбият

Алексеева И.С. Профессиональный тренинг переводчика: Учебное пособие по устному и письменному переводу для переводчиков и преподавателей. – СПб: Изд-во “Союз”, 2003.

Комиссаров В.Н. Современное переводоведение. – М.: ЭТС, 2002.

Латышев Л.К. Технология перевода. – М.: Издат.центр “Академия”, 2005.

Низамов И. Тәрҗемә нигә татарча түгел? – Казан, 1989.

Сибәгатов Р.Г. Тәрҗемә методикасының нигезләре. – Уфа, 1979.

Федоров А.В. Основы общей теории перевода. – М.: ООО “Издательский дом “ФИЛОЛОГИЯ ТРИ”; СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2002.

Ширяев А. Ф. Синхронный перевод: Деятельность синхронного переводчика и методика преподавания синхронного перевода. – М.: Воениздат, 1979.

Юсупов Р.А. Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.